# Без бер тамырдан

Керәшен татарларының этногенезын һәм этнографиясен өйрәнү буенча урта гомуми белем мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге

*Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы рөхсәте белән басыла*


КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2002
УДК 373.167.1:809.2/.3Тат
ББК 81.2 Тат я7
Б35


Рецензентлар:

*Д. М. Исхаков* — Татарстан Фәннәр академиясе Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре докторы;

*А. С. Филиппов* — Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.


*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*



**Без** бер тамырдан: Керәшен татарларының этногенезын һәм этнографиясен өйрәнү буенча урта гомуми белем мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге /Төзүчесе Н. В. Максимов.— Казан: Мәгариф, 2002.— 223 б.
ISBN 5-7761-1255-9

ISBN 5-7761-1255-9


© «Мәгариф» нәшрияты, 2002


*«…Телдә, музыкада, гамәли сәнгатьтә ата-бабаларыбызның борынгы гореф-гадәтләрен саклап калган өчен, без күп яктан керәшеннәр алдында бурычлы…»*

Татарстан Республикасы Президенты
*М. Ш. Шәймиевнең* II Бөтендөнья татар
конгрессында ясаган чыгышыннан

Әй керәшен, карендәшем минем —
Халкымның бер асыл бизәге.
Синең көйне бер тыңлаганнарның
Гомерлеккә өзелә үзәге.
Күңелең саф, тыйнак, рухың чиста
Һич тутыкмас көмеш тәңкәдәй.
Һәрбер кызың миңа сеңлем сыман,
Һәр әбекәй — туган әнкәдәй.

*(Гәрәй Рәхим)*
КЕРЕШ

Без — татарлар:
Болгар татарлары,
Себер татарлары,
Нугай татарлары,
Мишәр татарлары,
Типтәр татарлары,
Керәшен татарлары,
Тагын бик күп, бик күп татарлар.
Төрле-төрле исем йөртсәк тә без,
Төрле-төрле җирдә яшәсәк тә,
Тик бер генә туган телебез.

*(Гәрәй Рәхим)*

Татар халкы төрле этник һәм этнографик төркемнәрдән тора: Казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, Нократ, Касыйм, Әстерхан, Себер, Пермь татарлары. Шулар арасында керәшеннәр этноконфессиональ төркемне тәшкил итә. Бу төркемнәрнең формалашу тарихы һәркайсының үзенчәлекле. Шул сәбәпле аларның сөйләмендә һәм гореф-гадәт-йолаларында җирле үзенчәлекләр, аермалыклар бүгенге көндә дә сакланып килә.

2002 нче елның апрель аенда Татарстан Республикасының Президенты М. Ш. Шәймиев керәшен лидерлары белән очрашты. Очрашу вакытында әле үзебезнең татар халкы арасында да күп кенә проблемалар барлыгы ачыкланды. Шулай ук керәшен татарларының этногенезын һәм этнография-сен өйрәнү буенча факультатив курс өчен программа эшләү мәсьәләсе дә күтәрелде. Президентыбыз Мәгариф министрлыгына 2002/2003 нче уку елына, беренче тәҗрибә буларак, әлеге программа нигезендә факультатив дәресләрдә файдалану өчен уку ярдәмлеге әзерләргә дигән күрсәтмә бирде. Мәгариф министрлыгы әлеге карарны гамәлгә ашыру максатыннан, 34 сәгатькә исәпләнгән шушы китапны тәкъдим итә.

Китапның киләчәктә дөнья күрәчәк яңа басмасы, укытучылардан, киң җәмәгатьчелектән кергән фикерләр һәм тәкъдимнәрне искә алып, тагын да тулыландырылачак.

Керәшен татарларының үзенә генә хас гореф-гадәт-йолалары, тел үзенчәлекләре, кием-салымы, бизәнү әйберләре генә түгел, бик билгеле шәхесләре дә бар. Шуларны мәктәпләребездә укучы балаларыбыз белергә, алар үрнәгендә дә тәрбияләнергә тиеш.

Китап өч өлештән тора: башлангыч сыйныфлар, 5—9 нчы һәм 10—11 нче сыйныфлар өчен. Балаларның яшь үзенчәлекләрен, материалны аңлау дәрәҗәләрен исәпкә алып, китапка төрле буын язучылары, шагыйрьләре тарафыннан язылган шигырьләр, хикәяләр, башка төр әсәрләрдән өзекләр кертелде; тарихчы-галимнәр, журналистлар тарафыннан язылган тарихи язмалар тәкъдим ителде.

Әлеге уку ярдәмлегендә бирелгән материаллар мәктәп укытучысы өчен эшендә өстәмә материал буларак тәкъдим ителә. Материалны төрле фән — тарих, география, татар теле һәм әдәбияты, җәмгыять белеме укытучысы һәм башкалар дәреснең билгеле бер өлешендә темага һәм максатка яраклы рәвештә файдалана ала. Китаптагы материалга нигезләнеп, сыйныф сәгате, туган якны өйрәнү, үз ягыңның танылган кешеләрен барлау кебек сыйныфтан тыш чаралар, кичәләр үткәрергә мөмкин. Ягъни укытучы материалны, үзенең эшенә, тәрбияви процесска файдалы дип таба икән, дәреснең теләсә кайсы өлешендә файдалана ала.

Мәктәп яшендәге бала татар халкының нинди этник төркемнәрдән торуын, ләкин аларның шул ук вакытта барысының да бер милләт — татар милләте булуын белеп үссен. Без бер-беребезне күпме яхшырак белсәк, рухи байлыгыбыздан тулырак файдалана алсак, диннәребезне хөрмәт итсәк, уртак яшәешебез тагын да матуррак, тынычрак, киләчәгебез яктырак булыр.

## Керәшен татарлары турында кыскача белешмә

Керәшеннәр барысы да бер төрле түгел, алар үз эчләрендә дә бер-берсеннән шактый нык аерылалар. Тел-сөйләм үзенчәлекләре, шулай ук икътисади һәм рухи мәдәнияткә караган үзенчәлекләрне чагыштырып караганда, шактый ерак араларга сибелеп утырган керәшеннәрнең биш зур төркеме бүленеп чыга.

**Казан арты керәшеннәре.** Бу төбәктәге керәшен авылларының күпчелеге элекке Казан губернасының Мамадыш, Лаеш һәм Казан өязләренә, шулай ук Вятка губернасының Малмыж өязенә караганнар. Казан арты керәшеннәре төркеме чагыштырмача борынгырак булып исәпләнелә һәм, тарихчылар фикеренчә, алар элек-электән шушы урыннарда яшәгән җирле халык булган. Е. Малов мәгълүматларына караганда, Казан епархиясенә буйсына торган өязләрдә 1862—1863 нче елларда иске һәм яңа керәшеннәрнең саны 45 347 кеше булган.

**Түбән Кама тирәсендә яшәүче керәшеннәр.** Татарстанның Алабуга, Тукай (элек Чаллы), Минзәлә, Әлмәт, Зәй, Түбән Кама районнары һәм Башкортстанның Бакалы районында 100 гә якын авылда керәшеннәр яши. Фәнни әдәбиятта, архив документларында һәм Уфа губернасына караган язмаларда бу якларда яшәүче керәшеннәрне XVI—XVII гасырларда элекке Казан ханлыгы территориясенең үзәк өлешеннән күчеп утырганнар дип күрсәтәләр. Аерым чыганаклар буенча Тукай, Минзәлә, Зәй, Алабуга районнарындагы керәшен авылларының бик күптәннән яшәп килгәнлеге күренә. Югарыда күрсәтелгән төбәкләрдә яшәүче керәшеннәр Уфа епархиясенә караган язмаларда һәм архив документларында «иске» керәшеннәр дип теркәлеп калдырылганнар.

**Чистай керәшеннәре.** Татарстанның Чистай шәһәрендә һәм районында, Алексеевск районында ун авылда, Лениногорск районының Аланлык (Федотовка) авылында, Самара өлкәсенең Келәүле районы Урдалы авылында яшәүче керәшеннәр, татар-мишәрләр, чуваш, мордва һәм руслар арасында озак вакытлар янәшә яшәп, үзенчәлекле бер төркем булып формалашканнар. Кайбер авылларда, мәсәлән, Керәшен Ялтаны, Чуваш Ялтаны, Ишәле, Югары Кондрата авылларында керәшеннәр дә, чувашлар да яши. Өлкән буын кешеләренең сөйләүләренә караганда, биредәге авылларга нигез салучылар Тамбов, Саратов, Куйбышев өлкәләреннән күчерелгән татар-мишәрләр булганнар.

**Тау ягы (Мәлки) керәшеннәре.** Бу төркемгә сигез авыл керә: Мәлки, Иске Кырбаш, Куясан, Орым Тәрбите, Зур Тәрбит, Байморза, Иске Буа, Соравыл. Әлеге авыллар Татарстанның Кайбыч районына керәләр.

Зур булмаган бер төркем булып формалашкан Тау ягы керәшеннәре турында фәндә төрле фикерләр әйтелгән. Кайберәүләр аларны чувашлардан татарлашкан керәшеннәр, икенчеләре бу якның керәшеннәрен мишәр-татарлар дип карыйлар.

**Нагайбәк керәшеннәре.** Нагайбәкләр дип йөртелә торган керәшен татарлары Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы Кассель, Остроленко, Париж, Фершампенуаз, Астафьевка, Требия авылларында һәм Чибәркүл районы Варлам, Попово, Болотово, Краснокаменка, Ключевская авылларында яшиләр.

Нагайбәкләрнең килеп чыгышлары, кем булулары белән галимнәр күптәннән кызыксына. Нагайбәкләрне Казан ханлыгы җимерелгәч үк чукындырылган Арча ягы татарлары дип исәплиләр, аларны чукындырылган нугайлар дип карыйлар. Алар үзләрен «иске ил керәшеннәре» дип атыйлар. Нагайбәкләрнең һәм элекке Казан, Уфа губерналарында яшәгән керәшеннәрнең теле бер-берсеннән бик аз аерыла.

*Флера Баязитова,*
филология фәннәре докторы

## БАШЛАНГЫЧ СЫЙНЫФЛАР ӨЧЕН

### Җырчы Җәкәү

Керәшеннәр арасында Яков Емельяновның иҗаты инде XIX гасырда ук шактый популяр булган. Аны олылап, «Җырчы Җәкәү» дип йөрткәннәр. Әлбәттә, халыкның шагыйрьне шулай үз итүе юкка гына булмаган. Я.Емельянов әсәрләрендә халык үзенең иң тирән хисләре: авыр тормышка, социаль

тигезсезлеккә нәфрәте һәм киләчәк якты көннәргә ышанычы сурәтләнүен тойган. Шагыйрьнең поэзиядә биләгән урынын билгеләп, әдәбият галиме Хатип ага Госманов бик хаклы рәвештә болай дип яза: «Аның әсәрләрендә халыкның социаль тигезсезлеккә каршы күтәрелгән стихияле ачу тойгысы гәүдәләнде. Емельянов борынгыдан килә торган халык авыз иҗатыннан, телдән әйтелә торган поэзиясеннән, тирәнрәк чумырып, бай традиция алды, башка шагыйрьләр күрә белмәгән мөмкинлекләрне ачты...»

...Яков Емельянов 1848 нче елда хәзерге Балык Бистәсе районының Алан авылында туа. Хөр күңелле, җор табигатьле Алан кешеләре, кара кәзәкиләрен, пима-эшләпәләрен, ак тулаларын киеп, кичләрен җыенга чыга торган булган. Яшьләре түгәрәк уеннар оештырган. Шундый җәйге җыеннарда көйгә салып бәетләр җырланган, сүз осталары әкиятләр сөйләгән, мир картлары риваятьләр искә төшереп, аларны яшьрәк буынның хәтеренә сеңдереп калырга тырышкан.

Яшь Яков шулай халык җыруларын, авылдашлары арасында таралган әкият, легендаларны ишетеп үсә, шул чакта ук аның йөрәгенә соңыннан туачак ялкынлы шигырьләренең орлыклары салына башлый. Ләкин усал язмыш бу орлыкларга шытып чыгарга юл куймый. Тугыз яше тулар-тулмас, Яковны, көчләп, удельное училищега бирәләр.

— Елама, тиле, менә күрерсең, Җәкәүеңнән болыч (волость) писаре ясап кайтарырлар,— дип «юата» Яковның әнисен авыл старостасы. Мамадыш өязенең Җүкәче авылындагы волость писарьләре әзерли торган бу училищега Яковның үзенең артык исе китми. Училищены тәмамлагач, бер авылдашы аннан:

— Я, Җәкәү, хәзер кем булырга уйлыйсың? — дип сорый.

— Авылыма кайтам, укытучы булырга телим,— ди Емельянов.

Мондый җавапка теге хәйран кала: ничек инде укытучы? Әлифбасын онытып бетергән Алан кешеләрен ничек укытмак кирәк?!

— Әйе,— дип дөресли Яков.— Үзем ише авыл малайларын укытырга телим.

Ләкин аның бу изге нияте тормышка ашмый кала. Зур эшне юлга салырга ярдәм итәрдәй кешеләр табылмый. Алай гына да түгел: «Укытырга документың юк»,— дип, аның үзенә дә адым саен каршы төшәләр. Ләкин, үзе мәктәп ача алмаса да, Яков Емельянов ул чагында инде халыкка белем бирү өчен тырышучыларның барлыгын белә. Яковны, барыннан да бигрәк, керәшеннәр өчен укытучылар әзерли торган Василий Тимофеев мәктәбе үзенә тарта. Чөнки аңа укыту өчен документ кирәк. Шундый максат белән 1864 нче елда Яков Емельянов, Казанга килеп, Тимофеев мәктәбендә укый башлый. Биредә ул ана телендә язарга өйрәнә, үз телендә керәшен графикасы белән чыккан китапларны күрә.

Тора-бара ул үзе дә шигырьләр язгалаган һәм русча китаплар чыгарган Тимофеев белән дуслашып китә. Емельянов аның аркылы заманның күренекле кешеләре: казакъ мәгърифәтчесе Алтынсарин һәм татар галимнәре Фәезханов, Хәлфин, Насыйриларның хезмәтләре белән таныша. Алар яшь шагыйрьнең дөньяга карашын киңәйтә, аны иҗат эшенә рухландыра.

Тимофеев мәктәбе бер Яков өчен генә түгел, анда укучы башка бик күпләргә дә заманның алдынгы карашлы кешесе булып формалашырга булыша. Яков Емельяновның сабакташлары арасыннан удмурт әлифбасын төзүче Борис Гаврилов, казакъ далаларында беренче мәктәп ачучы Игнатий Тимофеев кебек мәгърифәтчеләр чыгуы бер дә гаҗәп түгел.

Ниһаять, Яков Емельянов морадына ирешкән кебек була. 1869 нчы елда ул укытучы булып туган ягына — Үри Чаллысы авылына кайта. Ләкин биредә дә Емельянов иркенләп эшләп китә алмый. 1874 нче елда аны, Казанга чакырып алып, Духовная академиягә керергә кыстыйлар. Емельянов бу академиягә керә һәм аннан дьякон булып чыга. Ә 1880 нче елда ул инде протопоп була.

70 нче елларда ул Вятка губернасының керәшен авылларында эшләсә, соңга таба Мамадыш өязендәге Чура авылына (Хәзерге Кукмара районының Село Чура авылы) күчә. Озакламый Тәңкәгә (Танькино), аннары Шеморбашка килә. Ә үләр алдыннан, яңадан Үри Чаллысына укытучы булып кайта. Бу елларда шагыйрь күңелендә кайнаган хисләр турында «Ярлы тормыш», «Әләк», «Олысымаклык» һәм «Саран бай» шигырьләре бик ачык сөйли.

Татарстан Үзәк архивының Ильминский фондындагы доносларданкүренгәнчә, Яков Емельянов «каһәрләнгән поплар» исемлегенә кертелгән була. Менә бу шигырен шагыйрь шундый доносларны күздә тотып язган, күрәсең:

Тор гадел,
Йөр шиксез,
Бул изге,
Кыл яхшы,
Уйла туры,
Сөйләш чын —

Буяр әләк!

Ләкин шундый гыйбрәтле сүзләрне әйтә алган шагыйрь үзе мондый каршылыклы атмосферадан котылу юлларын таба алмый. 1893 нче елның 2 нче февралендә, әле 45 кә дә җитмәгән килеш, Үри Чаллысында үлеп китә. Аны җирләргә, табут янында баш ияргә ерак-ерак авыллардан бик күп кеше килә.

Хәзер безне шундый сорау кызыксындыра: ә аның шигырьләренең язмышы ничек соң? Алар Яков Емельянов үзе исән чакта халыкка барып җитә алганмы?

Яков Емельяновның беренче шигырьләр җыентыгы 1867 нче елда оештырылган «Братство св. Гурия» җәмгыяте тарафыннан кириллица нигезендә төзелгән керәшен алфавитында басылып чыга. Шуңа күрә гарәп шрифтында укучы татарлар бу китап белән үз вакытында таныша алмый.
Ә чиркәү җыентыкның татарларны дин рухында тәрбияләүгә бернинди файдасы булмаганлыгын тиз аңлый.

Яков Емельяновның 1884 нче елда икенче җыентык чыгару теләге тормышка ашмый — китап тулысынча конфискацияләнә.

Тормышының соңгы елларында Яков Емельянов, дин юлын ташлап, чын мәгънәсендә, халыкка хезмәт итә башлый. Шул елларда ул халыкның ныклыгына, аның якты киләчәгенә ышанып, «егылмас инде сыналган җан» дип яза.

Емельяновның «сыналган җанлы» халкына әле шагыйрь үлгәннән соң да күп кыенлыклар кичерергә туры килә. Роман Даулей кебек, керәшеннәр арасыннан чыккан укымышлыларның ана телендә газета яки журнал оештырырга тырышулары хәтта беренче рус революциясе елларында да уңышлы тәгәлләнмәде. Клерикаль уй-хисләр белән сугарылган миссионерлар керәшеннәрне ничек кенә булса да үз тәэсирләре астында калдырырга, аларның аңын томалап тотуга бөтен көчләрен куйганнар. Ләкин яңа революцион күтәрелеш еллары керәшеннәргә дә вакытлы матбугат бирә. Аның битләрендә Емельянов традициясен дәвам итүче халык улларының әсәрләре басыла, талантлы шагыйрьләр күренә башлый. Шулардан иң күренеклесе — Яков Емельяновның шигъри эстафетасын турыдан-туры кабул итүче — Давид Григорьев. Безгә аның «Театр пьесалары», «Сандугач», «Пролетариат куәте» һ. б. китаплары билгеле. Болардан тыш, ул күп кенә коллектив җыентыкларда катнашкан, газеталарның иң актив хәбәрчеләреннән булган.

Күргәнебезчә, халык Яков Емельянов традицияләрен дәвам иттерүчеләрне, үз халкының рухы белән яшәүчеләрне, аның бәхете өчен Емельяновча көрәшүчеләрне тудырып торган. Ә алар Емельянов кебекләрнең үлемсезлеген раслый.

*Максим Глухов,*
тарих фәннәре кандидаты

## Әләк*

Тор гадел,
Жцр шиксез,
Бул изге,
Кыл җакшы,
Уйла туры,
Сцйлдш чын —
Буйар длдк!
Кайгыр, кцйцн,
Интек, индл,
Җыла, тилмер,
Уйла, шдйлд,
Уйыңны ждймд,
Телеңне бдйлд —
Җабышыр длдк!
Чыкма, жцрмд,
Барма, кермд,
Бердяне белмд,
Шиклдн, биклдн,
Җаклан, саклан,
Башыңнан каблан —

Сиздр длдк!
Каладан илгд,
Җирддн суга,
Суыктан утка,
Тцшлектдн тцнгд,
Таудан атауга
Кяч, кач —
Табар длдк!
Шуннан җаман
Тинтдк башлы,
Иң акылсыз
Чак каргадан,
Бик тизенндн
Котолмасак —
Итдр каряб!
Тор гадел,
Йөр шиксез,
Бул изге,
Кыл яхшы,
Уйла туры,
Сөйләш чын —
Буяр әләк!
Кайгыр, көен,
Интек, инәл,
Ела, тилмер,
Уйла, шәйлә,
Уеңны җәймә,
Телеңне бәйлә —
Ябышыр әләк!
Чыкма, йөрмә,
Барма, кермә,
Берәүне белмә,
Шиклән, биклән,
Яклан, саклан,
Башыңны каплан —
Сизәр әләк!
Каладан илгә,
Җирдән суга,
Суыктан утка,
Төшлектән төнгә,
Таудан атауга
Күч, кач —
Табар әләк!
Шуннан яман
Тинтәк башлы,
Иң акылсыз
Чак каргадан,
Бик тизеннән
Котылмасак —
Итәр харап!

## Улым

Мна җитте бдйрдм,
Безгд килер кунаклар;
Аларга сый дзерлд,

Тейешлечд кадерлд:
Жумартны утырт жугары,
Саранны утырт сдкегд,
Жыуашны утырт жанга,
Гаделне утырт алга,
Жакшыны утырт уңга,
Жаманны утырт сулга,
Усалны утырт ушага,
Оятсызга жарар бусага;
— Сыйлаганда сак бул:
Жумартны жянндб сыйла,
Саранны сак сыйла,
Жыуашны жыуаныб сыйла,
Гаделне кыуаныб сыйла,
Жаманны жайлаб сыйла,
Усалны уйлаб сыйла,
Бусагадагыңар булса жарар,
Булмаса алдына карар.
Менә җитте бәйрәм,
Безгә килер кунаклар;
Аларга сый әзерлә,
Тиешлечә кадерлә:
Юмартны утырт югары,
Саранны утырт сәкегә,
Юашны утырт янга,
Гаделне утырт алга,
Яхшыны утырт уңга,
Яманны утырт сулга,
Усалны утырт ушага,
Оятсызга ярар бусага;
Сыйлаганда сак бул:
Юмартны юньләп сыйла,
Саранны сак сыйла,
Юашны юанып сыйла,
Гаделне куанып сыйла,
Яманны җайлап сыйла,
Усалны уйлап сыйла,
Бусагадагыңар булса ярар,
Булмаса алдына карар.

*Яков Емельянов*

## Көзгедәге күзләр

Бүген күзләрем мине тагын алдады.

Көзге каршына килеп бастым да шактый олыгайган уйчан йөземә текәлдем һәм кылт итеп исемә бала чагым килеп төште. Ул чакта болай идемени соң минем күзләрем?.. Ул чакта...

— Әнкәй, кара әле минем күзләремә! — дия идем мин, кулымны көзгегә таба сузып.

Әнием көзге каршына килеп баса да күзләремнең көзгедәге шәүләсенә текәлә иде.

— Әнкәй, болар бит минем чын күзләрем,— дим мин пышылдап кына һәм бармакларым белән көзгедәге күзләремә кагылам.— Әнием, мин аларны бик яратам. Мин бит сине дә, әтиемне дә шулар аша гына күрәм!

Әнкәй мине күкрәгенә кыса... Минем кесәмдә дә кечкенә генә көзге кисәге бар иде. Кечкенә булса да, ул минем зур күзләремне күрсәтә ала.

Мин, ялгызым гына бакчадагы карт алмагач төбенә чыгып, әлегә кешеләр ишетеп белмәгән гаҗәп могҗизалар күрәчәк күзләремә текәләм. Әйе, әйе, мин, зур үскәч, бик күп серләр беләчәкмен. Чөнки минем күзләрем, хәтта көзгедә дә шулай якты булып күренә ала торган күзләрем, барысын да күрергә тиеш.

Кайчакта мин алмагач төбенә килеп утырам да куе яфраклар арасындагы кояш нурларын көзге китеге белән күзләремә төшерәм. Күзләремә төбәлгән нурларда мин әллә ниткән якты кристаллар; кызыл, яшел, зәңгәр һәм шәмәхә ут шарлары күреп алам. Көчле кояш нурларында чагылудан, минем күзләрем яшьләнеп китә; керфекләремне чылаткан яшь бөртекләре аша алма яфраклары тоныкланып һәм зураеп күренә башлый. Күзләремдә яшь булса да, шатлыгым эчемә сыймый, чөнки мин кояшның да кайбер серләрен күрә башладым бугай инде.

Бервакыт мин күзләремнең көзгедәге шәүләсен генә түгел, ә чын, тере күзләремне күрергә теләдем. Ләкин кинәт аптырап калдым: кешеләр үз күзенең шәүләсен генә күрә ала икән ләбаса, ә күзнең үзен беркайчан да күреп булмый икән. Кулларны, аякларны, хәтта, авызны чөмкәйтеп булса да, иренне дә күрергә була. Ә күзләреңне, тере, чын күзләрне күрергә мөмкин түгел.

Әткәй миңа: «Синең күзләрең әниеңнең күзләренә охшаган»,— ди. Мин һәрвакыт әниемнең күзләренә җентекләп карыйм. Андый чакларда үземнең чын, тере күзләремне күргәндәй булам.

Әнкәй эштән үз вакытында кайтып җитмәсә, әткәй мине кош оясы кебек җылы кочагына ала да, нәрсәгәдер тынычсызланып, күзләремә текәлә. Шул чакта әткәйдән:

— Әтием, син минем күзләрем аша нәрсәләр уйлаганымны күрә аласыңмы? — дип сорыйм.— Яхшылабрак кара, мин бит нәкъ менә-менә шушы төшем белән генә уйлыйм,— дип, маңгаена төртеп күрсәтәм.

— Күрәм, улым, күрәм. Әнкәй нигә һаман кайтмый икән дип борчыласың,— ди әтием.

Бервакыт кичтән тәрәзәне ачып куйдым да Айны күзәттем. Айның өсте шыксыз, җыерчыклы-җыерчыклы иде. Нигәдер, анда бик тә, бик тә салкындыр кебек тоелды. Суыктан калтырана-калтырана, тәрәзә яңагына сыендым. Юк, юк, Айда яшисем килми минем. Анда җирдәге кебек җылы тәрәзә яңаклары да, менә бу бакчадагы кебек, алма чәчәкләре дә юктыр. Айда яраткан күзләремә салкын тидерермен, ялангач кыялар арасында адашып бетәрмен. Юк, юк, һич кенә дә Айда яшисем килми. Минем җирдә каласым килә. Үз күзләремә охшаган әнием күзләре янында, күзләремә карап уйларымны күрә ала торган әтием янында каласым килә.

Без әнкәй белән көзгегә, күзләремнең шәүләсенә текәлеп торабыз.

— Әнкәй, җирдәге бөтен нәрсәне дә шушы күзләрем аша гына күрәм бит,— дим, пышылдап кына. Әнкәй мине кочагына кыса.

— Әнкәй, мин үскәч йолдызлар арасыннан очып үтәрменме? Шунда Кояшны да, Киек Каз Юлына түшәлгән асылташларны да, иң кечкенә йолдызларны да шушы зур күзләрем аша җентекләп күзәтермен һәм, очыштан әйләнеп кайткач, аларның барысын да сөйләрмен. Яме, әнкәем.

* * *

Сөйли алмадым. Ялангач Айның, Кояшның, Киек Каз Юлларының, иң кечкенә йолдызларның серләренә төшенергә теләп, фәнни эшләр артыннан йөри-йөри, хәтта әниемә җир тормышының матур киләчәге турында да сөйли алмый калдым. Кара уйларымны күрә ала торган әтиемә бүгенге иң бөек хыялларымны күрсәтә алмый калдым. Алар икесе дә күптән вафат. Ә мин бүген, көзге каршына басып, тагын күзләремә текәлдем һәм аларда кадерле әтием һәм әнием карашын күргәндәй булдым.

*Гәрәй Рәхим*

## Ике песи баласы

Дусларымның яңасы —
Ике песи баласы.
Берсе — Мияу матур,
Ә берсе — Мияу батыр.
Көне буе уйныйлар,
Уйнап бер дә туймыйлар:
Арт аякка басалар,
Сабан туе ачалар,
Көрәшәләр идәндә
Ни бирербез җиңгәнгә?
Кайчагында, юләрләр
Диванга да менәләр.
Җибәрәләр уздырып —
Җәймәләрне туздырып.

Яратсам да шелтәлим:
— Узынмагыз, җитәр! — дим,
Кирәк бераз аңларга,
Өлкәннәрне тыңларга!

### Ике көянтә

Апама да, миңа да
Бүләкнең иң тәтиен —
Менә дигән көянтәләр
Алып кайтты әтием.
Минекендә — алтын башак,
Исең китәр төсенә!
Күгәрченнәр төшерелгән
Апам көянтәсенә.
Апамның күгәрченнәре
Торалар күк гөрләшеп.
Кичләрен су китергәндә,
Куям аннан көнләшеп.
Апам көянтәсендә, һәй,
Гөрләп туярлар әле.
Бөртек эзләп, минекенә
Килеп кунарлар әле.

### Тыңлаусыз чүкеч

Абый белән икебез
Гөл әрҗәсе эшлибез.
Кулга чүкеч алабыз,
Шалт-шолт кадак кагабыз.
Абый эшли туктаусыз,
Минем чүкеч — тыңлаусыз.
Һич кенә туры сукмый,
Һаман бармакны тукмый.
Күпме мөмкин кыйнарга?
Кирәк нидер уйларга:
Күрмәгәндә, абыйныкын
Алыштырып куярга!

### Күк тавыкның шатлыгы

Таралып чебиләр,
Тырманып йөриләр.
Яшь әнкә — күк тавык
Эндәшә җим табып:
— Кыт-кыт-кыт, кыт-кыт-кыт,
Монда җим, кабып йот.
Тыңлады чебиләр,
Йөгереп килделәр.
Шушыннан тәм табып,
Шатланды күк тавык.
...Шулвакыт бер тилгән
Омтылды бик түбән.
Ә әнкә: «Кыр-кыр-кыр,
Кыр-кыр-кур, кача күр!»

Аңлады чебиләр,
Саклана белделәр:
Постылар тиз генә
Әрекмән төбенә.
Шуннан да ямь табып,
Сөенде күк тавык.

*Павел Апушев*

## Клара Булатова

Шагыйрә Клара Булатова керәшеннәр өчен аеруча кадерле, якын. Чөнки ул,— олуг язучы Аяз Гыйләҗев кебек үк, керәшен авылында — Ләкедә үсеп, канат ярган кыз. Аның бу авыл халкына багышлап язган «Ләкеләргә ел да кайтыр идем», «Печән өсте», «Питрау үтте — җәйләр бетте», «Син исәнме, Санук түти?» дигән һәм башка шигырьләре, күңел җылысы салынган мәкаләләре хакында белмәгән керәшен сирәктер. Әйе, керәшен үзен олылаганны ярата, үзенә игелек кылганга аеруча кадер күрсәтә белә.

Әнә шуңа күрә керәшен авылына килсә, шагыйрәнең урыны түрдә. Ул — иң затлы кунак.

## Син исәнме, Санук түти?

Ләке хоры. Керәшен халык җыры
Фестивальдә, телеэкранда.
— Әйдә, әйдә!
— Кайда, кайда? — диләр,—
— Әйдә, барыйк,— диләр,— урманга.
— Әйдә, әйдә!
— Кайда, кайда? — диләр...
— Әйдә барыйк,— диләр,— чатларга.
Әйдә, әйдә...
Мин дә кайтып киләм
Шушы җырлар туган якларга.
Әйдә, әйдә!
Мин дә ияреп барам
Ләкеләргә, Сарман ягына.
Каран елга буйларында калган
Ялан тәпи сабый чагыма.
…Күз алдыма килә шул картина
Балачагым искә төшкәндә.
Лаксандра апа — Санук түти
Камыр баса гөлбәч өстәлдә.
Лепер-лепер арыш оны или
Эре иләктән җилпуч-тактага.
Халык әле ипи салмый иде.
Бәйрәм ашы — камыр катлама.
Үзләре күп. Ире, балалары,
(Ялгышмасам, тула дистәгә.)
Пешергәндә бәйрәм катламасын,
Минем өлеш килеп өстәлә.
Мин аларда бик еш куна идем,
Белмим, ничек шулай булгандыр.
Кысан гына өйдә тар сәкегә
Тугыз бала ничек сыйгандыр.
Тезелешеп ята идек шунда

Кыз, малайлар, туган иптәшләр,
Салам ястык иде баш астында,
Өстебездә иске бишмәтләр.
Көндез шуны киеп йөрибез дә
Кич ябынып шуны ятабыз.
Мич башында чабаталар кибә,
Тезеп куя Санук апабыз.
Без ятабыз. Ә ул канат алып
Сөртеп йөри почмак тузанын.
Иңнәренә кайры тунын салып,
Чабып керә ишек бозларын.
Утын яра, мал-туарын карый
Шул чатнама кышкы суыкта.
Пауал дәдәй чыгып йөри алмый —
Аяклары калган сугышта.
Урыныннан тормас гарип ире,
Сигез бала, олы-кечесе.
Өстәвенә мине ияртеп кайта
Ахирәтем — Куян Лүскесе.
(Кызык гадәт Ләке авылында,
Кушаматсыз бер дә йөрмиләр.
Авыл тулы инде «Чукый», «Бакрач»,
«Абай», «Җапай», «Куян», «Бүре»ләр.)
Минсез дә бит чыр-чу, бала-чага
Тулы иде алар өендә.
Күренмәде ризасызлык төсе
Лаксандра апа йөзендә.
...Әллә кайчан юкса үткән инде
Катламага кытлык замана.
Катламасы белән Санук түти
Күз алдымда минә һаман да.
Хәзер генә шуны ачык аңлыйм:
Как сәкеле ярлы өйгә мин
Зур табында бүлешеп ашый торган
Шул катлама өчен йөргәнмен.
Син ялдадыр, олыгайгандыр инде
Тынгы белмәс хезмәт кешесе.
Балаларың кайсы кайда икән,
Дустым кайда — Куян Лүскесе?
Үләннәрне, яшел чирәмнәрне,
Чебиләрне сөя иде ул.
«Үскәч зоотехник, я агроном
Булам әле»,— дия иде ул.
Кем булды ул хәзер? Кайда эшли?
Яныңдамы? Синнән читтәме?
Калын-калын сары толымнарын
Әле һаман үреп йөртәме?
Син исәнме, Лаксандра апа?
Дустым кайда — Куян Лүскесе?
Ялан тәпи сабый чакларымның
Чагылышы — үзем төслесе.
— Әйдә, әйдә!
— Кайда, кайда? — диләр,
— Әйдә барыйк,— диләр,— урманга...
Ләке хоры. Керәшен халык җыры
Фестивальдә, телеэкранда.

*Клара Булатова*

## Ананий Нестерович Малов

*(Ямаш Игәнәй)*

Ямаш Игәнәй (Малов Ананий Нестерович) 1938 нче елда Сарман районы Ләке авылында дөньяга килә. 1955 нче елда Сарман урта мәктәбен, 1958 нче елда Лубян урман техникумын тәмамлаган, Башкортстанда урман хуҗалыгында эшләгән. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайткач, Сарман районының Рантамак һәм Азалак авылларында балалар укыткан, читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген тәмамлаган. Укуын бетергәч, Баулы һәм Мамадыш район газеталары редакцияләрендә эшләгән.

1978 нче елдан алып Я. Игәнәй Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итә. Дистәгә якын китап чыгара. Иҗат эше белән бергә зур җәмәгать эше алып бара. «Керәшен сүзе» газетасына нигез сала.

Ул сибелгән, таралган керәшеннәрне «Керәшен сүзе» газетасы аша җыйнау, рухи хәзинәләрен барлап, алдагы көннәргә илтү максаты белән янган — үтә дә тыйнак, сабыр, олы җанлы кеше иде.

1997 нче елның 1 нче мартында 60 нчы яшендә кинәт авырудан соң, зур шагыйрь, прозаик һәм публицист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Керәшен сүзе» газетасы редакторы, «Аргамак» журналының бүлек мөдире Ямаш Игәнәйнең гомере өзелде. Безнең арадан тыйнак, талантлы, керәшеннәргә тугрылыклы, аларның иҗатын, культурасын үстерүгә, йолаларын, динен кайтаруга үзеннән бәяләп бетергесез өлеш керткән кеше китеп барды.

## Без биш бала үстек...

Без биш бала үстек. Ананий иң кечебез иде. 1941 нче елда әти сугышка китеп, шул ук елны һәлак булды. Шуңа күрә Ананий әтине хәтерләми. Әтиебез райком хезмәткәре, авыл советы председателе һәм секретаре, колхоз председателе, умартачы, халык судьясы да булып эшләде. Һәлак булганда, өлкән лейтенант дәрәҗәсендә булган. Тик Ананий үзенең биографиясендә, ни өчендер, әтине колхозчы буларак кына күрсәтте.

...Бала чагы сугыш һәм сугыштан соңгы авыр елларга туры килде. Ачлы-туклы һәм ялангач тормыш. Башкаларыбыздан ул басынкы характеры белән аерылып тора иде. Бәләкәй чактан ук, китаплар укырга яратты. Озын кичләрдә әнигә дә кычкырып укый, ә әни җылый-җылый тыңлый торган иде.

Җиде сыйныфтан соң урта мәктәпне Сарманда (12 километр йөреп укып) тәмамлады. Аннан соң Лубян урман техникумына укырга керде. Балачагы һәм яшьлек елларының ничек үткәнен күрми дә, сизми дә калдык...

Өйгә, авылга барыбызны да сагынып кайта иде. Һәм гомере буе туган җанлы булып калды. Киң күңелле, һәркем белән уртак сүз таба, туган якны, табигатьне яратты. Урман техникумын сайлавы да очраклы гына булмагандыр. Җәй, көз көннәрендә кыска гына ялга кайткан арада да җиләккә, гөмбәгә йөрде. Бер белмәгән урман юлы, урман сукмагы юк иде.

Үзенең тормышын сынаулар аша кичерсә дә зарланмады. Әзгә риза булып, барына шөкер итеп яшәде. Кешеләргә кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырышты. Хуҗалыкта барлык эшләрне дә, үзенчә ашыкмыйча, җентекләп башкарыр иде. Кече күңелле иде энебез. Инде олыгайгач та, урманга барганда, безнең балаларны да ияртеп барыр, алар белән уртак сүз табар, урман белән таныштырып йөрер иде. Үзләренә барып керсәң, нишләргә белмәс, балаларча сөенер иде.

*Александра, Лидия, Василий Маловлар*

* * *

Җир йөзендә күпме керәшен бар,
Илдә-көндә күпме исәбе?
Кем әйтәлә, нәсел-нәсәбенең
Сау-тазамы тамыры, үзәге?

Карлы-бозлы яңгыр, заман җиле

Бәгыреңне өтеп исәме?
Яман телләр җанга салган яра
Үзәгеңне әрнеп өзәме?

Иркә ачып бер утырыйк әле,
Эчең бушар, зарың сөйләрсең.
Синдәй эчкерсез зат бүтән юк бит,
Карендәшем, асыл керәшен.

Инде ару гына яшә берүк,
Келәүләрең кирләп китмәсен.
Имәндәй нык, таза нәсәбеңнең
Бөреләрен кырау өтмәсен...

## Әтәч

Әй йөри Әтәч,
Киереп түшен.
Кая куярга
Белмичә көчен.
Койма тактасын
Сындырды тибеп.
Сулы чиләкне
Яньчеде изеп.
Кешеләр белән
Алды «булышып».
Күрше малайга
Кунды ул очып!
Йөри торгачтын
Кирәген алды:
Су тулы мичкә
Өстенә ауды…

## Чебиләр

Ишегалдында иртән
Сап-сары күлмәк кигән
Нәни генә бер чеби
Аптырап елап йөри.
Корт эзләп бара-бара
Ераккарак киткән ул.
Иптәшләрен югалткан
Һәм адашкан икән ул.
Бик җәлләдем мин аны,
Аннан, тотып сак кына
Илтеп куйдым чебине
Башкалары янына.
Иптәшләре табылгач,
Бар да бик сөенделәр
Һәм чебиләр телендә:
«Рәхмәт сиңа!»— диделәр.

*Ямаш Игәнәй*

## Александр Филиппов

Александр Сергеевич Филиппов Татарстанның Зәй районы Зичәбаш авылында 1937 нче елның 20 нче январенда Аграфена Андреевна һәм Сергей Филиппович Филипповлар гаиләсендә тугызынчы — төпчек бала булып дөньяга килә. Башлангыч белемне Зичәбашта, җидееллыкны Кабан-Бастырыкта, урта белемне Түбән Биш мәктәбендә ала. Избач, мәктәп лаборанты булып эшли. Чиләбе өлкәсе һәм Красноярск краенда армия хезмәтен үти. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген, Ленинград Югары политология мәктәбенең журналистика факультетын тәмамлый. «Кызыл Зәй» (дәвамчысы «Зәй офыклары») газетасында, Татарстан радиосында, «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» (дәвамчысы «Сабантуй») газеталарында, партиянең Арча райкомында эшли, Апас районының «Йолдыз» газетасында баш редактор була. 1983 нче елдан Татарстанның Идел-Зөя төбәге районнарында «Ватаным Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе вазифасын башкара.

А. С. Филиппов — «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә, Татарстан Республикасының Мактау грамотасына лаек булган журналист.

Ул гомере буе керәшеннәргә кагылышлы барлык истәлекләрне бөртекләп җыйган.

## Беренче Спас

Икенче төрле аны баллы яки юеш Спас дип тә йөртәләр. Спасларның өчесе дә авыл хуҗалыгы эшләре, урып-җыю, чәчү, җиләк-җимеш җыю һ. б.лар белән бәйләнгән. Әйтик, беренче Спаста кура җиләге өлгерә. Күп еллык тәҗрибә һәм сынамышлардан чыгып, әгәр дә беренче өлгергән җиләкләр эре булса, арышны иртә чәчү отышлы саналган. Әгәр дә инде вак булса, урта срокта яки соң чәчү ягын караганнар. Игенче, җиләккә карап, туфрактагы дым запасын чамалаган.

Беренче Спас ел саен 14 нче августта билгеләп үтелә. Бу чорда авыл хатыннары, бала-чагаларын ияртеп, урманга кура җиләге җыярга йөри. Төрле авыруларга им-дәва буларак, аның җимешен генә түгел, чәчәген һәм яфрагын да җыялар, шулай итеп, кышка запас туплыйлар. Беренче Спаста шомырт та өлгерә. Ул да күп төрле авырулардан дәва булып тора.

*Бал кортлары кәрәзләрне бал белән тутыра. Шуңа күрә ул баллы Спас дип атала да.*

*Беренче Спастан соңгы — өченче Спаска кадәр — Успенье уразасы башлана.*

*Беренче Спаста карлыгачлар җылы якка күченеп китә башлый.*

*Беренче Спаста салкын чык төшә. Шуңа күрә аны юеш Спас дип тә атыйлар.*

*Беренче Спаста атларны һәм башка хайваннарны елгада соңгы тапкыр коендыралар.*

## Урта Спас

Урта Спас ел саен 19 нчы августтан башлана. Башкача аны алма Спасы дип тә атыйлар. Чөнки бу көнне алмага хуш исле тәм керә дип саныйлар. Урта Спаста алманы агачыннан өзеп ашарга ярый. Алманы икенче Спаска кадәр ашау зур гөнаһ кылу булып исәпләнгән. Кыярдан башка нинди дә булса җиләк-җимеш ашау тыелган булган.

*Урта Спастан соң төннәрен салкын була.*

*Урта Спаста сабан ашлыгы өлгерә.*

*Урта Спаста торналар җылы якка китә башлый.*

*Әгәр һава килсә, җил төньяктан исеп торса, урта Спаста чәчелгән арыш ньк һәм эре бөртекле була, диләр халык телендә.*

## Өченче — соңгы Спас

Соңгы Спас, элгәресеннән соң ун көн узгач, 29 нчы августта билгеләп үтелә. Аны чикләвек Спасы да диләр. Чөнки бу вакытка чикләвек өлгерә. Арыш уңган елны чикләвек тә күп була. Бу чыннан да шулай.

*Соңгы Спаста карлыгачлар, ярдагы һәм өй кыекларындагы ояларын калдырып, җылы якларга китүләрен дәвам итә.*

*Әгәр торналар соңгы Спаста китсә, Покрауда (11 нче октябрьдә) салкын була.*

*Өченче Спас икмәкле дә була. Кышка запас туплап куела.*

*Александр Филиппов*

## Авыл иртәсе

Уянып китсәм иртән —<br>
Ай-яй, эссе бөркелә

Мич алдыннан, күмердән.
Мич каршысында әни
Коймак пешерә икән.
Аның көләч йөзенә,
Беләгенә, кулына
Алсу нурлар йөгергән.
Уф, исе лә, исе лә
Тула юрган эченә,
Керә борын эченә.
Шунда ук сырпаланып
Йөри әнә песи дә.
Түзәрлек кенә мени
Тәмле коймак исенә!
Анда бөтенесе дә:
Арыш, бодай исе дә,
Болын, кырлар исе дә,
Мәтрүшкә исе дә,
Бөтнек, әрем исе дә
Һәм яңгырлар исе дә —
Ишегалдында әнә...
Сыер мөгерәп куя.
Арткы капкадан чыгып,
Казлар төшә инешкә.
Биген элә капканың
Әти керә-керешкә.
Кәҗә, сарык, бәрәннәр,
Тавык, күркә, үрдәкләр
Әллә кайчан торганнар,
Тамак та туйдырганнар.
Тәмле искә кинәнеп,
Бар да йөри ирәеп.
Коймак исеннән хәтта
Киткәннәр күк көрәеп.
Әни коймак пешерә.
Коймак исе табадан
Бар урамга таралган.
Дөнья күмелгән тәмам
Ис симфониясенә,
Төс симфониясенә,
Көч симфониясенә!
Коймаклап чәй эчәргә,
Каймаклап чәй эчәргә,
Торыйм әле тиз генә.
Кунак күк иркәләнеп
Ятыйм мени мин генә!..

*Ямаш Игәнәй*

## Булсын гына файдасы

Тегүче минем әни —
Уйнап тора кайчысы.
Ул тегеп биргән күлмәкнең
Бик матур һәркайсысы.

Үскәч, мин дә әни сыман
Кешеләр киендерәм.

Матур күлмәкләр кидереп,
Һәркемне сөендерәм.

Апамның да эше әйбәт —
Кибеттә товар сата.
Аның җитез эшләвенә
Бөтен кеше шакката.

Анда күпме уенчыклар!
Аюлар бар, песиләр.
Песидән куркалардыр —
Һич күренми күселәр.
Анда эшләсәм, уйнар идем
Шул уенчыклар белән.
Сатмыйча да тормас идем —
Акча да саный беләм.

Моңая беләдер сыман
Ул матур курчаклар да...
Елап җибәрмиләрме икән
Аерылган чакларында?

Аларга да алмаш күлмәк
Кирәк бит ул, билгеле.
Кибеттә күлмәк тә тексәм,
Әни бирер өлгене.

...Ярый инде, үсим генә!
Эшләсәм дә мин кайда,
Әйбәт булыр... Кешеләргә
Китерим генә файда.

### Куяннарның туннары

Әти әйтә: «Яз җитте,— ди,—
Карлар да эреп бетәр.
Куяннарның да туннарын
Алыштырыр чак җитәр…»
Ул сөйли, мин уйлап ятам:
Бай икән бу куяннар.
Җәйгә — күк тун,
Кышка — ак тун…
Алдан алып куйганнар.
Ә минем тун бер генә,
Ул да туздЫ чамасыз.
Былтыр кидем, быел кидем —
Алучы юк яңасын.
Шул турыда әйткән идем,
И көлде әти, әни!
Син, балакай, дәресең бел,
Уйлап ятма әллә ни.
Куяннарның акчасы юк,
Бер атнада җиде көн,
— Алай булгач, нигә Ходай
Алыштырмый минекен?
Аңлаттылар бик әйбәтләп

Икесе дә шул чакта:
— Син куяннан өстенрәк
Бәхетлерәк, ул яктан.
Ходай сиңа акыл биргән
Көчләр биргән, көч биргән.
Әйбәт укы, тәртипле бул —
Ир булырсың бер дигән.
Эш яратсаң, ул туннарны,
Кирәк икән, унны ки!
Иң әйбәте: намус белән
Эшләп алган тунны ки.

*Ирина Минеева*

## Җиләкле як

Халык кая ашыга, дисәм —
«Әчелек» тау ягына.
«Әчелек»тә җиләк пешкән —
Кып-кызыл, ди, бал гына.

«Төбәк»тә дә җиләк уңган —
Чиләгең тиз тула, ди.
Бик тә уңган кызлар гына
Бу яклардан җыя, ди.
Ә «Таштау»дагы җиләкләр
Каптыңмы — эреп тора.
Матур чиләк эчләренә
Үзләре кереп тора.

Әй җиләге, җиләге,
Бик тиз тула чиләге.
Җитез, өлгер булсаң гына
Пешеп торыр җиләге.

## Елмаюда бары яктылык

Елмаюга мохтаҗ кеше җаны —
Елмаю ул — шатлык яңгыры.
Бер елмайсаң — дөнья нурга чума,
Күңелләргә күчә таң нуры.

Моңайма син, елмаерга тырыш,
Якты йөзең һәрчак күрсеннәр.
Авырлыклар иңгә басканда да
Бәхетле ул, диеп белсеннәр.

Сөенечләреңне һәрчак уртаклашсаң —
Җавап булып килер яхшылык.
Елмаю ул — бәхет башлангычы,
Елмаюда бары яктылык.

*Людмила Степанова*

## Бөре тышчасы

Урман. Кояш куе ботаклар арасыннан озын нур-кылычларын сузган. Күзләрне чагылдырып ялтыраган ул кылычлар талгын җилдә тирбәлә, чайкалалар. Менә-менә алар, ялгыш, бер ботакка килеп тиярләр дә «эһ» иткәнче кисеп тә төшерерләр кебек. Әнә җеп кебек нечкә бер кылыч соргылт бөрегә китереп чапты да

инде. Сагызлы бөре тышчасы, көнбагыш кабыгыдай «черт» итеп ярылып китүгә, эчтән каз бәбкәсе кебек яшькелт сары нәфис яфракчык килеп чыкты. Бөре тышчасы яфракчыкка:

— Ярый, хуш! Мин үз вазифамны үтәдем. Хәзер үзең үс инде! — дигән кебек, бөтерелә-бөтерелә, былтыргы яфраклар өстенә очып төште.

Соргылт бөре тышчасы!

Ул, үзе туңа-туңа булса да, яфракларны январь зыкыларыннан, февраль, март бураннарыннан, салкын апрель төннәреннән саклап килә дә, табигать әле яңа гына уяна башлаган иң җылы, иң матур вакытлар җиткәч, яфракларны үз иркенә калдырып һәлак була.

Яшел яфраклар, кояш нурларында иркәләнә-иркәләнә, җәйге җылы яңгырларда коена-коена шау-гөр килеп яшәгән вакытта, ул инде аларга ашлама булып җирдә ята.

Җәй көне урман һавасы сулап та, сагызлы бөре тышчасының әчкелтем-татлы исен тоя алмаган, миллионлаган яфраклар шавы арасында язын «черт» итеп ярылып киткән бөре тышчасының кайтавазын ишетә алмаган илтифатсыз кешеләргә күңелемдә зур үпкә бар.

*Гәрәй Рәхим*

## Йолалар һәм йолаларга караган сүзләр

Керәшен татарларында борынгыдан килгән традицион йолалар нык сакланган дип әйтсәк тә, аларның күбесе инде бүгенге көндә күзәтелми, әмма өлкән буын кешеләре аларны хәтерлиләр һәм сөйләп күрсәтәләр. Шуның өчен без бүгенге көндә күбрәк халык хәтерендә сакланган, аларның сөйләме аша безгә килеп җиткән мәгълүматларга нык таянабыз. Традицион йолалар, ягъни борынгыдан килгән халык йолалары, фәндә икегә бүлеп йөртелә: гаилә йолалары һәм календарь йолалары, ягъни елның төрле фасыллары белән бәйле йолалар, бәйрәмнәр. Гаилә йолалары арасында иң катлаулысы һәм үзенчәлеклесе — туй йолалары.

* * *

Һәртөрле ышануларга, җырларга бай булган туй йолаларында халыкның күп еллар буе үстерелеп килгән катлаулы иҗаты, үзенчәлекле культура тарихы чагыла. Керәшеннәрнең сөйләшләре бер төрле булмаган кебек, гореф-гадәт-йолаларында берникадәр аерымлыклар бар.

* * *

Борынгыдан калган йола буенча, кияүгә китәсе кыз туй вакытында елап җырларга тиеш булган. Үзе теләмәгән кешегә бирелгән очракта, ул үпкәләү, рәнҗү сүзләрен башлап әти-әнисенә җиткерә, туганнары, дуслары белән саубуллаша. Туган йортыннан аерылып, чит-ят кешеләр арасында яшәүнең читенлеген күз алдына китереп, моңлы көй белән җырлый-җырлый елый торган булган.

* * *

Татар халкының башка төркемнәрендәге кебек, керәшеннәрдә дә борынгыдан килгән матур йолаларның берсе — **яшь киленгә су юлы күрсәтү** — әле бүгенге көндә дә сакланып килә.

*Флера Баязитова*

## Песиле тал ботагы

*(Хикәя)*

Зичә инеше тау итәге буйлап боргалана-сыргалана ага. Аның өсте әле хәзергә калын боз һәм кар белән капланган. Ә инеш ярларында нинди генә агачлар үсми! Апрель урталары җиттеме, таллар көмеш «чәчәк» ата. Бу вакытта малай-шалайны инеш буена табигатьнең әнә шул гүзәллеге тартып төшерә дә инде. Шундый матур көнне Сандыр белән Мандыр да өйдә утыра алмый. Алар, икесенә бер чәнәшкә тартып, инеш буена тау шуарга төшеп китте. Аяк астына карасаң, ап-ак кар, җем-җем итеп, күз явын ала. Күзеңә кадәр төшкән бүрегеңне күтәребрәк куйсаң, каршыңда гүзәл бер дөнья ачыла. Күп белүче Сандыр, энесе алдында ачыш ясагандай, әйтеп сала:

— Кояш шулай үстергән ул бәрмәнчекләрне...

— Ә син аны кай-йан беләсең?

— Үзем беләм! — дип мактана Сандыр, тамак кырган рәвешен китереп.
— Дәдәй, нигә бүтән агачларның да шундый песиләре юк соң?
— Бәрмәнчек талда гына була ул...
Әле бер, әле икенче агач янында туктый-туктый, калын олтан салынган киез итекләре манма су булганчы, шактый озак йөрделәр алар. Уч тутырып, бәрмәнчекле ботаклар җыйдылар. Әниләре, әй, мактар инде үзләрен. Бүген бәрмәнчек атнасы башлана, дигән иде бит.
Кинәт салкын булып китте. Агалы-энеле ике дус, тал песиләре белән мавыгып, көн кичкә авышкач, җиз табакка әйләнгән кояшның Татый түтиләрнең җиргә иңгән мунчасы артына төшеп яшеренгәнен сизми дә калды. Сандыр белән Мандыр, артларыннан аю кугандай, йөгерә-йөгерә, өйләренә кайтып китте.
— Дәдәй, дәдәй, карале! — дип шаран ярды Мандыр.— Өй кыегына нәрсәләр элеп куйганнар?
Алар чыгып киткәндә, тып-тып тамып калган тамчылар, яңадан әйләнеп кайтканда, боз сөңгеләренә әверелеп өлгергәннәр иде. Бер тамчы су, сөңге очыннан аерылып, Мандырның кипкән иреннәрен чылатты. Рәхәт, кызык булып китте аңа. Менә ничек була икән ул бәрмәнчек атнасы!

*Александр Филиппов*

## Димәк

Якын булса үз илең —
Илдә булсын үз гөлең.
Әгәр булса үз өең —
Үзеңчә күр үз көнең.
Җырлар булсаң үз көең —
Көйгә килсен үз телең.
Табалмасаң үз гөлең,
Коралмасаң үз өең,
Күралмасаң үз көнең,
Табылмаса үз көең,
Аңламасаң үз телең —
Аптырап йөрмә, гөлем,
Юк, димәк, синең илең.

*Гәрәй Рәхим*

## Карендәшләр җыры

*(Керәшен гимны)*

*Марс Макаров* сүзләре һәм көе

Алмагачның багалмасын коеп,
Җапракларын җилләр тараткан.
Әйтмиек җаман сүз башкаларга,
Ходай барын тигез җараткан.

Җапраклардай очып таралсак та,
Инде менә тагын кавыштык.
Чиләбедә, Ижау, Бакалыда
Моңнарыбыз аша табыштык.
Төркемнәре таркалмасын өчен,
Кошлар да бит күмәк очалар.
Тормыш үрләренә менү җиңел
Карендәшләр бергә булсалар.

Җөгереп лә суларга төшәрбез,
Колачларны җәеп җөзәрбез.
Кулны кулга, иңне иңгә куеп,

Тормыш дәрьяларын кичәрбез.

Керәшеннәрдә туганлык мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр: *үз әби, җырак бабай, җырак әби, дәдәй, түти, ак дәдәй, ак түти, җырак дәдәй, җырак җиңги, печкәчә, җанагай, урсата, урсай.*

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

## Элҗен

Элҗен — керәшеннәрдә иң зур һәм абруйлы бәйрәмнәрнең берсе. Ул ел саен 2 нче августта (иске стиль белән 20 нче июль дә) билгеләп үтелә. Без бу очракта да мәҗүсилек ырымнары белән очрашабыз. Ул табигать көчләренә табынуга кайтып кала. Әйтик, христиан динендәге пәйгамбәр Илья яки ислам динендәге Ильяс пәйгамбәр, яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп, көчле яңгыр яудыручы, җирдәге кешеләр белән күктәге Алла арадашчысы булуы белән мәгълүм.

Халыкта Илья пәйгамбәр усал, кырыс, изге, дошманнарын җәзага тартучы, шул ук вакытта юмарт, үзенекен мохтаҗ адәмнәргә бүлеп бирүче итеп күз алдына китерелә. Үзен эзәрлекләгән мәҗүсиләр патшасы Ахав, аның хатыны Йезавель, аларның патша булып калган уллары Охозийга үлем карарын да ул чыгара. Ул табигатьнең иң куркыныч һәм мәрхәмәтле көчләре белән идарә итә, яңгырлар, яшенле күк күкрәүләр аның карамагына керә. Ул Җиргә уңыш та җибәрә. Элҗендә табигатьнең барлык хәшәрәт көчләре, утлы камчыдан куркып, куян, төлке, мәче, эт, бүре һ. б. ларга әверелеп бетә, имеш. Бу көнне, яшен камчысы сукмасын өчен, эт һәм мәчеләрне өйгә кертергә ярамый.

Элҗен көнне кырга барып, борчактан авыз итеп карарга ярый. Беренче тапкыр яңа бәрәңге пешереп ашыйлар. Элҗен җиттеме, авыл халкы, куркынып, күк йөзен күзәтә башлый. Чөнки бу вакытта игеннәр өлгергән була. Аны көчле яңгырлар юк итәргә мөмкин. Илья пәйгамбәрнең күңелен күрү йөзеннән, ул бәла-казалар китермәсен өчен, бу көнне кырда эшләмиләр, печән чапмыйлар, чабылганын җыймыйлар, кырга мал-туар чыгармыйлар.

Элҗен җәйне тәмамлый.

Элҗендә көн ике сәгатькә кыскара.

Элҗендә сары яфраклар күбрәк күренә башлый.

Элҗендә көн ничек булса, 27 нче сентябрьдә дә шулай була.

Элҗеннән башлап төшкә кадәр җәй, төштән соң көзгә тарта.

Элҗеннән соң яңгырлар еш ява.

Элҗендә туган балаларга Илҗә исеме кушалар.

***Җәйге Микулы*** *(9 нчы август).* Икенче төрле аны кәбестә Микулысы дип тә атыйлар. Микулыда кәбестә баш төрә башлый.

***Август***

Август сынамышларының күбесендә кыр эшләрен үз вакытында үткәрү, кышка ныклап әзерләнү буенча күп төрле киңәшләр бирелә.

Икенче Спас — бияләй ал кулыңа запас.

Өченче Спас — кыяр тозла кышка запас.

Мәгълүм булганча, август безнең климат зонасында җәйге кызу айларның берсе булып исәпләнә. Халык календаренда аны, июль шикелле үк, «чиллә ае» дип тә атыйлар. Телебездәге «уттай кызу урак өсте» дигән гыйбарәдә дә эшнең кызулыгы гына түгел, бәлки кояшның нык кыздыруы да күздә тотыла. Августны тагын «казларның сусыз ае» дип сыйфатлау да очрый. Монда кызулыктан елга-күлләрнең, буаларның кибеп-саегып калуына ишарә барлыгын аңлау читен түгел.

Әмма җәй күп кенә яклары белән үз көчендә калса да, август инде якынлашып килүче көзнең кайбер галәмәтләрен дә сиздерә башлый. Халык календаренда яңача 2 нче августтан ук инде җәйдән көзгә күчә башлау көне итеп санала. Бездә аны Элҗен көне диләр.

Сынамышлар «Элҗен көне төшкә чаклы җәй, төштән соң көз» яки «Элҗен көне өйләдән соң көз» дип раслыйлар.

Халык телендә «Кояш баю алдыннан ак болытлар йөрсә, төнлә бал явар» дигән сынамыш бар. Чык балы — яфраклар, кыяклар өстенә җыела торган ялтыравыклы, баллы сыекча. Ул күбрәк август аенда күзәтелә, һәм шулай ук җәй ахыры җитүнең бер билгесе булып санала.

Шушы көнне умартачылар арасында кәрәз ватып бал алу йоласы бар.

Көз сулышы ныграк сизелгән саен, игенче күңеле киләчәккә карарга омтыла. Бу көз ничек килер: корымы — явымлымы, җылымы — салкынмы, иртәме — соңмы? Кыр эшләрен вакытында төгәлләү, киләсе ел уңышына нигез салу өчен, һава шартлары уңай булырмы? Табигать күренешләрен, агач-үсемлекләрне, кош-кортларны җентекләп күзәтү аша ул шушы мөһим сорауларга җавап эзли, халыкның күп гасырлык бай тәҗрибәсен беркеткән сынамышлар арасыннан һәр очракка туры килердәй мисалларны сайлап хәтеренә төшерә. Август аеның андый сынамышлары бик күп:

Элҗен көн яңгыр яуса, илле көн яңгыр явар.

Август аенда аяз булса, көз пычрак килер.

Спастан соң пәрәвез күп булса, киләсе ел ашлык күп булыр.

Августта кара әрем тамырының тармаклары юан булса, киләсе ел арыш уңар.

*Александр Филиппов*

## Көзге көндә җәйге моң

Көзге болыт — кургаш, диләр,
Соры, диләр, яңгырларын.
Ә мин менә сары көздә
Бик тә сәер җыр тыңладым:
Җәйнең төпсез зәңгәр күге,
Каплап чиксез офыкларын,
Яңгыр, сафлык вәгъдә иткән
Күрдем җәйнең болытларын.
Мин күзәттем ялт-йолт иткән
Җитез яшен тамчыларын.
Иркәләдем учларымда
Көмеш яңгыр тамчыларын.
Күрдем шушы гүзәллеккә
Якты кояш сокланганын,
Күрдем көмеш тамчыларга
Якты нурлар уралганын.
…Сагыш хуҗа сары көздә
Мин бер якты җыр тыңладым.
Алып килде ул күңелгә
Инде үткән җәй моңнарын.

## Гүзәллек

*(Авыл кызы)*

Өчтән үргән ике толым,
Ак буранар уралган.
Озын кара керфегеңә
Көмештәй ак бәс сарган.
Ике битең алсу алма:
Күңелеңдә ут икән.
Иренеңә кичке шәфәкъ
Кызыллыгын мул сипкән.
Иңнәреңә, кире кайтып,
Җәйге болын уралган.
Чиләкләрең сайрар кошлы,
Чишмәләрдән җыр алган.

Атлауларың — бер гүзәллек:
Җырлап кала ак карлар.
Сокланалар, ут яналар
Күргәч тә гашыйк ярлар.

*Николай Александров*

## Әй торналар, торналарым...

*(Җыр)*

Торналарны озатып калдым,
Ак каенга сөялеп.
Тагын бер ел китеп бара,
Торналарга ияреп.

Кушымта:

Әй торналар, торналарым,
Китмәгез, борылыгыз,
Җәйләрне алып китәсез,
Яшьлекне калдырыгыз.

Торналар оча, кагынып,
Еллар — канат какмыйча.
Көз җиткәнгә ышанмадым,
Торналарны озатмыйча.

Кушымта.

Торналар китте, җырлашып,
Киек Каз Юлы белән.
Яшьлегемне озатып калдым
Торналар җыры белән.

Кушымта.

Әй торналар, ник дәшмисез,
Мине ишетәсезме?
Әллә сез дә яшьлегем күк
Кайтмаска китәсезме?

Кушымта.

*Никифор Тукмачев*

### *Сентябрь*

Көз фасылын башлап җибәрә торган ай буларак, сентябрь халык календаренда еш телгә алына. Бигрәк тә искечә берен-
че сентябрь мөһим аграр дата булып саналган. Аны Симән
(Семен) көне дип тә йөртәләр. Петр I тарафыннан христиан
ел исәбе кертелгәнгә кадәр, бу көн Россиядә яңа ел башы булып йөргән. Гадәттә, шушы срокка көзге чәчүне һәм башка күп кенә кыр эшләрен тәмамларга тырышканнар. Тик бәрәңге һәм кайбер яшелчәләрне алу гына бераз соңгарак калдырылган.

Арышны Симән көнне төшкә тикле чәч, төштән соң чәчмә.

Симән көне үткәч, биш-алты көннән бәрәңге казырга ярый.

Халыкта бу көн әбиләр чуагы башлана торган вакыт буларак та киң билгеле. Ә керәшеннәр арасында элегрәк Симән көнендә умартадан бал алу һәм өйдән чебен куу йоласы да яшәп килгән. Чебеннәрне куганда: «Чыгыгыз, чык, Симән бабай килгән, бал ашарга чакыра»,— дип әйтә торган булганнар.

Табигый ки, халык календаренда искечә беренче сентябрьгә багышланган сынамышлар байтак. Менә тагын кайберләре:

Беренче сентябрьдә җылы булса, бөтен көз җылы булыр.

Беренче сентябрьдә күк күкрәсә, киләсе ел ашлык уңар, ләкин көз озак килер.

Симән көнне яңгыр яуса, көз пычрак килә.

Сентябрь дәвамында табигатьнең эзлекле төстә көзгә күчеше күп төрле билгеләрдә чагылыш таба. Көннәр һаман кыскара барып, 23 нче сентябрьдә көн белән төн яңадан тигезләшә (астрономнар көз башлануын шушы датадан алып исәпли). Гәрчә әбиләр чуагында җылы коры көннәр торса да, кояшның җылысы инде күзгә күренеп кими бара. Әле 5—10 нчы сентябрьләрдә үк туфракта беренче кыраулар күренә башлый.

«Көзге көннең көлүе, көлүе дә елавы» дигәндәй, сентябрь ахырларына таба, бигрәк тә көзге көн-төн тигезлеге узгач, җил-яңгырлар ешая. Агачлар, яфракларын коя-коя, җир өстенә сары юрган түши. Беренчеләрдән булып җәйге киемнәрен каеннар, чаганнар, юкәләр, усаклар сала башлый. Көчле, мәһабәт имәннәрдә яфраклар бераз озаграк саклана. Ә менә чияләр кар ныклап ятар алдыннан гына яфрак коеп бетерә.

Көзге табигатьнең шушындый күп төрле күренеш-галәмәтләре халык сынамышларында да теркәлеп бара һәм киләчәккә прогноз ясау, хуҗалык итүдә киңәшләр бирү өчен файдаланыла:

Сентябрь башларында тавыклар каурыйларын коя башласа, ел суык була.

Ундүртендә чикмән төшә, тун менә. (Димәк, тун киярлек салкыннар булырга мөмкин.)

Унбишендә каз оча кышларга.

Унсигезенче сентябрьдә кыр казлары китсә, Покрауда кар ятар.

Егерме сигезенче сентябрь. Бүген бал кара. Умартаны базга төшер.

*Александр Филиппов*

## Борынгы китаптан

*(Библиядән)*

Кешегә җаманнык иткән кешенең җаманныгы үзенә кайтыр, кайдан килгәнен дә белми калыр. Усал кешеләр бүтәннәрне мыскыл итсә, үз усаллыклары үзләренә зыян китерер. Җакшы кешеләрнең бәлаләренә сөенгән кеше үзе бәла күрә.

Җакшылык иткән кешегә Ходай кайтарыр, җакшылык илдә калмас. Җакыныңны рәнҗетеп теләк теләсәң, синең җазыгыңны Ходай кичәр. Үз күңелендә кешегә үпкә тоткан кеше: «Җазыгымны кич!» — дип, Ходайдан ничек итеп теләсен?

Үзе җир тупрагы була торып, кешегә үпкә тоткач, аның җазыкларын кем тазартсын? Үләсеңне уйла да үпкә тотуыңны ташла, үлеп черәсеңне исеңә ал да Алла бойрыкларын тот. Алла бойрыкларын исәпләдә — кешегә үпкәләмә. Ходайның кушканын исеңә төшер дә азгынчылыгыңны ташла.

Ызгыш чыгарудан тыйыл, тыйылсаң — җазыгыңны киметерсең. Ачучан кеше ызгыш чыгара, усал кеше дусларны болгата, тату торганнар арасына дошманнык сала. Җанар нәстә күбәйгән сайын, ут көчәйә, ызгышкан сайын, ачу калынайа, кешенең ачуы көчәйгән сайын, җаманныгы күбәйә.

Көтәсеңә бир, аңар булышкан кеше Ходай бойрыгын кыла. Кешегә нужа чагында бир, аннан үзең көтәргә алсаң — вакытында кайтар. Биргән вәгъдәңне җиренә җиткер, әйткән сүзеңне бозма; шулай итсәң, үзеңә кирәк булган нәстәне тапмый калмассың.

Күп кешеләр көтәргә алган акчаны, тапкан акча күк күреп — кайтармыйлар, биргән кешене үкендерәләр. Кешедән акчаны сорап алганчы — җалына, җалбара, алган акчаны кайтарасы чагында — озаклата, каршы әйтеп рәнҗетә, тиз аласың дип, җаратмаган була. Түләргә көче җитеп, акчаны китерсә дә җартысын гына китерә, шунда да, акчаның иясен табышландырам дип, бик мактана, йә түли алмаса, аны үз акчасыннан коры калдыра, аны дошман итә. Йә алай итмәсә алган акчасы өчен рәхмәт урынына аны шелтәли, хөрмәт итү урынына — хурлый. Күп кеше шундый усаллыктан көтәргә дә бирми, үз акчамны югалтырмын дип курка. Син, ничек булса да, кешене кызганучан бул. Хәер сораган кешене заркытма, бир. Алла хакына җарлыга булыш, нужасыннан сораса, аның кулын буш җибәрмә. Ходай кушкан буенча сәдака биреп, үзеңә үзең күктә мал әзерлә. Ул сиңа алтыннан артык файда китерер. Акчаны сандыкка салып җаткызганчы йук җаланга сәдака бир, сине әр төрле бәладән коткарыр, дошманнан, кылыч белән сөңгедән саклар.

Җакшы кеше җакыны өчен җөкче була, ояты җук кеше җөкче булганныгыннан тана. Җөкчең булган кешенең кадерен белеб тор: ул синең өчен үз җанын биргән. Усал кеше үз җөкчесенә күңелдән тау итү түгел, малын бетерә, бәла китерә. Җөкче булу күп бай кешене бөлдергән. Кешегә булышыйм дисәң, җитешүеңә караб булыш, үзеңә-үзең зыян китерерлек итмә, чамалаб кылын.

Кешегә торырына иң элек ипи белән су кирәк, аннары киyренә кием кирәк, кереб торырына өйе кирәк. Кеше өйенә барыб, тәмле ашлар ашаб җөрүдән үзе салам түбәле өйе эчендә җарлы, ару торганы җакшы, күп булса да, аз булса да үзеңнекеңәр тук бул. Әйе, җукның өйдән өйгә җөрүе читен, кая кереб торса да аузы бер сүз әйтергә дә кыймый. Кеше өйендә сине ашатсалар да, эчертсәләр дә — чын күңелдән туйдырмыйлар. Үзеңнән көтәләр, аннары тагы әче сүз эшетерсең.

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

## Покрау

Ул үзе «покров» сүзеннән алынган, ягъни татар телендәге «каплам», «япма» мәгънәләренә туры килә. Покрау керәшеннәр билгеләп үтә торган 12 бәйрәм рәтендә йөрмәсә дә, зур бәйрәмнәрдән санала. Аның 11 нче октябрьдә билгеләп үтелә торганы Кече Покрау дип атала. Ул үзенә күрә көзне озату, кышны каршылау булып тора. Бу көнне керәшен өйләрендә җимеш пироглары пешерелә. Аларның эчлекләре көзге табигать хәзинәләреннән — алма, балан, миләш, гөмбә һ. б.лардан әзерләнә. Бу көнне яшь әтәч ите белән аш-су өлгертәләр.

14 нче октябрьдә бәйрәм ителә торганы Олы Покрау дип атала. Ул безгә христиан дине белән бергә Константинопольдән килеп кергән. Әмма ул элекке заманнарда ел фасылының бер чорында табигать үзгәрешләренә туры китереп үткәрелә торган бәйрәм булган. Ул бары тик 910 нчы елда гына, Византия императоры әмере нигезендә, дини бәйрәм итеп үткәрелә башлый, Константинополь шәһәрендә 910 нчы елда, безнең бабаларыбызның күпчелеге әле христиан диненең нәрсә икәнлеген дә белмәгән вакытта, Византия халкына Влахера храмында Изге Кыз Мария рухы иңә. Бу гаҗәеп күренеш шаһитлары сөйләвенә караганда, ул табынучылар өстенә ак җәймәсен (омофор) җәеп җибәргән һәм дөньяны кайгы-хәсрәт һәм газап чигүләрдән коткару турында дога укыган.

Хәзер Изге Кыз Мария җәймәсе көнен (Покрау—Покров) христиан дине тотучылар, шул исәптән керәшеннәр дә, көзге кыр эшләре төгәлләнгән һәм көтү кергән көн буларак билгеләп үтә. Гомумән, авыл халкы бу көнгә кыр белән бәйләнгән барлык эшләрен төгәлләп куярга тырыша, чөнки Покрау көнне төшкә кадәр көз булса, төштән соң кыш башлана. Шуңа күрә Покрау үтте — кыш җитте, ди халык. Бу сүзләрдә зур хаклык бар.

Бу чорда көзге эшләр тәмамланган, ә язга хәзерлек әле башланмаган була. Шунлыктан халык бераз бушанып, ял итеп ала. Авыл халкы өчен ул бер үк вакытта туйлар чоры башлануны да аңлата. Дөрес, бу принцип хәзер төгәл сакланмый инде. Олы Покраудан башлап кунаклар чакыралар. Бу йортка кунак булып җыелган гаиләләрнең һәммәсе дә үзләрен чакыручы хуҗаларны, чиратлашып, өйдән өйгә кунак итеп йөртә. Шулай итеп, авылда кунакка йөрешүче берничә төркем барлыкка килә. Туганлык җепләре буенча, бер төркемдәге гаилә икенче төркемгә дә чыгып алырга мөмкин. Чөнки алар бер-берсе белән дошманлыкта булмый. Кайбер авылларда Ми-кайла бәйрәме (21 нче октябрь — олы фәрештә Михаил көне) дә, шушы кунакка йөрешүләр эченә кереп, 27 нче ноябрьдә
6 атналык ураза башланганчы дәвам итәргә мөмкин. Әмма бу авыл халкы алты атна буена гел кунактан кунакка гына йөри дигән сүз түгел әле.

Покрау көнне төштән соң борыныңны җилгә каршы тотсаң, нинди кыш киләчәген дә сиземләп була икән. Күп белүче агайларның сүзенә караганда, Покрау көнне җил көнчыгыштан иссә, кышның салкын килүен көт тә тор.

Әмма кыш никадәр генә салкын килмәсен, бу көнне өйләнешүчеләр өчен кыш өшеткеч булып тоелмый. Нәкъ менә Покрау көнне — 14 нче октябрьдә үткәрелгән туй да иң бәхетле санала, чөнки Покрау өйләнешүчеләр юлына ак җәймә түшәүче булып тора. 1880 нче елда чыккан гореф-гадәтләр, риваятьләр һәм төрле ышануларга багышланган бер китапта язылганча, бу көнне кызлар йокларга ятканда Алладан яхшы кияү сорый торган булганнар. Ә инде бу көнне чиркәүдә иң беренче шәм куйган кызга башкаларга караганда алданрак кияүгә чыгу бәхете татый икән.

*Покрауда өйне, бүрәнә җекләрен мүкләп, җылыта башлыйлар, икенче кат тәрәзәләрне куялар, аның ярыкларына кәгазь ябыштыралар.*

*Покрауда соңгы тапкыр гөмбә җыялар.*

*Покраудан терлекләрне абзарда асрый башлыйлар.*
*Покраудан Кач мануга кадәр авыл егетләре читкә китеп эшләп кайта.*
*Бу айда туйлар була.*
*Покраудан көзге ярминкәләр, аулак өйләр башлана.*

*Александр Филиппов*

* * *

Табигатькә нәрсә булды икән,
Чәчәк атты балан көзен дә?
Тик җимшәнен генә өтеп алды
Кара суык Покрау төнендә.
Нигә инде чәчәк аттырырга
Өшетерлек булгач тәлгәшен.
Ашыктыңмы әллә күрсәтергә
Алтын көзнең яшел кәлшәсен.
Кызыл балан янында ак тәлгәш
Кояш җылысыннан коела.
Яхшы да бит көтү үз нәүбәтең
Ашыкмыйча гына кая да.
Ничек кенә матур күренмәсен,
Көзге чәчәк туа җимешсез.
Аңламаслар сине тыңлаучылар,
Әйткән сүзең булса килешсез.

## Ел фасыллары белән бәйле йолалар, бәйрәмнәр, борынгы ышанулар

Керәшеннәрдә ел фасылларына караган, табигать күренешләренә бәйле рәвештә үткәрелә торган төрле йолалар, гореф-гадәтләр шулай ук бик кызыклы. Борынгыдан килгән ышануларга нигезләнгән йолалар, күмәкләп, бөтен авыл халкы катнашында үткәрелә торган булган.

Шунысын да әйтергә кирәк: чиркәүләргә якын булган авылларда христиан дине өстенлек иткән, борынгы ышанулар, йолалар аз сакланган. Чиркәүләрдән һәм олы шәһәрләрдән читтә булган авылларда борынгы ышанулар, йолалар, һәртөрле келәү итүләр күбрәк сакланып калган.

Элекке гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, мәсәлән, нардуган уеннары, бәрмәнчек, тройсын яки каен башы бәйләү («яфрак бәйрәме» дип тә әйтелә), питрау һәм башка бәйрәмнәр үзенчәлекле җырлар, такмаклар белән уздырыла торган булган. Христиан бәйрәмнәре итеп чиркәү календаре буенча уздырылса да, аларда динилек бөтенләй диярлек чагылмый, күбрәк борынгыдан килгән халык йолалары өстенлек алган. Кызганычка каршы, ул борынгы йолалар һәм йола җырлары хәзерге вакытта онытылып баралар, аларның иң матурларын яңартып, авылларга ямь өсти торган итеп, халыкка кире кайтару зарурлыгы нык сизелә хәзер.

*Флера Баязитова*

## Милли аң уянып килә

Матур табигатьле Башкортстанның Сөн буйларында Яңа Балыклы дигән керәшен авылы бар. Картларның сөйләвенә караганда, христиан диненә үзләре теләп күчкән аның халкы.

Безнең авылда танылган драматург Нәҗип Асанбаев укыган, йөгерү буенча дөнья чемпионы Светлана Викторовна Ульмасова шушы авылда туып үскән.

Күп еллар буена туган телдән аеру, руслаштыру — бу авылга да хас күренеш. Хәтта керәшен балалары укыган мәктәптә татар телендә сөйләшергә рөхсәт ителмәгән вакытлар да булды.

Хәзер халыкның милли аңы уянып килә, борынгы йолаларны саклап калу теләге көчәйгәннән-көчәя. Шул максат белән, безнең мәктәптә дә керәшен фольклор ансамбле оештыру теләге туды. Тырыша торгач, оештырып, исемен «Алинур» дип куйдык. Максатыбыз — авылның үткәнен, милли гореф-гадәтләрен, асыл йолаларын өйрәнү, керәшеннәрнең кабатланмас рухи хәзинәләрен халыкка кайтару. Болар барысы да

балаларда, укытучыларда зур кызыксыну уятты. Хәзер ансамбль оешуына 5 ел булды. Үзебезгә махсус кием-салым тектердек. Авыл тарихын язу буенча эш алып барабыз, мәктәптә музей ачтык.

«Йөзек салу» йоласын сәхнәләштереп, Учалыда үткәрелгән балалар фестивалендә катнаштык. 1990 нчы елда Яркәйдә үткәрелгән этнографларның беренче слетында чыгыш ясадык.

Районда үткәрелгән бәйрәмнәрдә безнең чыгышларны бик яратып карыйлар. Үмер, Божыр, Илек кебек керәшен авыллары укучылары белән дә дуслык җепләрен ныгытабыз. Керәшеннәрнең үзенчәлекле бәйрәмнәрен, йолаларын өйрәнәбез, авылыбызның җырчыларын, такмакчыларын магнитофон тасмасына яздырабыз.

«Алинур» ансамбле үзеген нигездә 4—9 нчы сыйныфта укучы балалар тәшкил итә. Егермедән артык укучы йөри. Бер буын укучылар, мәктәпне тәмамлап чыгып китсә дә, безнең белән араны өзми.

Хәзерге вакытта авыл клубында да ансамбль оешып, эшебез тагын да җанландырылды. Үзебезнең авыл картларының «Шаулы оркестр»ында да йөрибез. Шулай ук Ахман, Мостафа, Михайловка, Божыр авылларында да чыгыш ясадык. Дусларны яратабыз, ләкин районда керәшен фольклор ансамбле юк, шуның өчен балалар фольклор ансамбльләре белән дуслык элемтәсе урнаштырасы килә. Казан телевидениесен карый алмыйбыз. Безне Татарстандагы керәшеннәр тормышы кызыксындыра, милли йолалары, сәнгате, җырлары белән танышасы килә. Бәлки, безгә кунакка килергә, үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклашырга теләүче ансамбльләр булыр?

*Р. Шәйдуллина*

## Сыргаларың сырлы-сырлы…

XIX гасырның икенче яртысында керәшеннәрнең күпчелеге өйдә җитештерелгән тукымалардан тегелгән кием кигәннәр. Эчке киемне бөтенләе белән киндер һәм алачадан теккәннәр. Тора-бара керәшен авылына фабрикада эшләнгән тукымалар үтеп керә башлый. Ләкин алачадан тегелгән киемнәр коллективлаштыру чорына кадәр яшәп килгән. Бары тик ял һәм бәйрәм киемнәрен генә фабрика тукымаларыннан теккәннәр. Ә ярлылар фабрика тукымаларын ешрак, алача белән катнаштыру өчен кулланганнар. Урта тормышлы, бигрәк тә байлар, ял һәм бәйрәм киемнәрен тегәр өчен, сатин, шивиот һәм башка тукымалар сатып алганнар. Бу киемнәр көмеш, мәрҗән, укалы тасмалардан торган бик күп төрле бизәкле булулары белән аерылып торганнар.

Өс киемнәренең төп өлеше күлмәк һәм ыштан булган. Ирләрнең дә күлмәге фасоны буенча хатын-кызларныкыннан аерылмаган. Ирләр күлмәкне, ыштан эченә тыкмыйча, эчке эзәр белән бәйләп йөргәннәр.

Ирләрнең дә, хатын-кызларның да ыштаннары, гомумән, бер төрле тегелгән. Ул дүрт өлештән торган: ике өлеше —балак, балаклар арасына бер өлештән — күселек, тагын бер өлешен яртылай ярып, чабулар теккәннәр. Күбесенчә ыштанны ак алачадан тегеп зәңгәргә яисә кара төскә манып кигәннәр.

XX гасырның башында ирләр арасында ыштанның икенче төре — чалбар — киң тарала. Ыштаннан аермалы буларак, чалбар караңгы төстәге фабрика тукымасыннан шәһәрчә формада тегелгән. Ирләрнең дә, хатын-кызларның да костюмының аерылмас өлеше булып алъяпкыч саналган. Күлмәк һәм алъяпкыч өстеннән җиңсез камзол кигәннәр. Чабу санына карап, камзоллар өч, биш һәм җиде биллегә бүленгән. Җилән — җәйге җиңел өс киеме. Аны караңгы төстәге фабрика тукымаларыннан теккәннәр. Ирләрнең җиләне өч билле булса, хатын-кызларның биш һәм җиде билле булган. Чикмән — соры, кара, көрән төстәге өй сукносыннан тегелгән, язгы-көзге сезонда киелә торган өс киеме булган. Чикмән, юлга чыкканда, тун яисә бишмәт өстеннән киелеп, билбау, эзәр белән бәйләнеп куела торган булган.

Керәшеннәрнең кышкы киемнәре булып бишмәт, тун һәм толып саналган. Бишмәтне караңгы төстәге фабрика тукымаларыннан теккәннәр. Хатын-кызлар — бөрмәле, чигешле, көймәнле туннар, ә ирләр сары тун, постау тун киеп йөргәннәр. Ат белән олы юлга чыкканда, кышкы кием өстеннән тире яки чикмән толып кигәннәр... Керәшеннәрнең өс киемнәре төрле тукымалар, мехлар, челтәрләр белән эшләнгән булуы игътибарны үзләренә тартып торалар.

Аяк киемнәреннән, төп аяк киеме итеп, чабата саналган. Чабатаны өйдә сугылган сукнодан тегелгән оеклар белән кигәннәр. Шулай ук киндер яисә йон ыштырлар, тула чөлкәләр, бәйләнгән оеклар һәм аякчулар белән дә кигәннәр. Кыш көне яхшы тормышлылар киез итек, йон ката киеп йөргәннәр. Яхшы тормыштагы хатын-кызлар җәй көннәрендә чәрек башмак (туфли) һәм чәнчүр (кыска кунычлы күн итек) кигәннәр.

Ирләр кыш көне башларына сарык тиресеннән тегелгән бүрек, колакчын бүрек, рус малахае (ушанка), ә җәй көне киез эшләпә, картуз киеп йөргәннәр. Кызлар исә, Идел буендагы башка халыклар кебек үк,

яланбаш яисә бөтенләй үк ябып бетерми торган ак калфактан йөргәннәр. Кияүгә чыкканга кадәр кызлар чәчләрен бер толымга үреп, җилкә буенча асылындырып йөргән булсалар, кияүгә чыккан көннән бирле ике толымга үреп, баш тирәли урап, баш киеме киеп йөргәннәр (чәчләре күренмәскә тиеш булган). Кызлар өчен генә характерлы баш киемнәреннән ак калфак, калфак чачак булган. Кияүдәге хатын-кызларның баш киемнәре комплексы мәләнчек, сүрәкә, җилкәлек һәм яулык сыман бөркәнчектән торган. Сүрәкә өч өлештән тора: маңгай, койрык һәм канатлар. Аннан тыш бәйләвечләре бар. Олырак хатыннар сүрәкәне ак яулык белән бәйләп йөргәннәр. Бәйрәмнәрдә төрле рәсемнәр төшерелгән атлас һәм ефәк яулыклар бәйләгәннәр: атлас яулык, ефәк яулык, кашемир яулык, француз яулык. Туйларда түгәрәк яулык һәм бөркәнчек бәйләп йөргәннәр, кыш көннәрендә яулык өстеннән байка һәм йон шәл бәйләгәннәр.

Керәшен хатыннары мәрҗән төймәләр һәм асыл ташлар кулланып эшләнгән көмеш тәңкәләр, ювелирдан ясалган бизәнү әйберләрен тагып йөргәннәр. Бизәнү әйберләре кул, баш, муен һәм күкрәк бизәкләренә бүленәләр. Кул бизәкләреннән балдак, тәңкәле йөзек, тәңкәле беләзекләрне кулланганнар. Баш бизәкләренә түбәндәгеләр керә: чачак, ука чачак, маңгай укасы, маңгай тәңкәсе, башъяулык, чәч тәңкә, толым тәңкә, чулпы, чәч сапма, чәч кабы, чәч арты, алкалар һәм сыргалар. Муен бизәкләре: тамакса, яка чылбыры. Күкрәк бизәкләре: түшлек, изү һәм җилкәгә асу тастымалы (хәсилә, дәвәт, муйтомар).

Тарихыбызга кагылышлы бер генә әйберне, бер генә бизәкне дә онытырга һәм югалтырга хакыбыз юк безнең. Болар — безнең әби-бабаларыбызның үзләреннән соң килгән буыннарга, безгә генә түгел, балаларыбызга һәм балаларыбызның балаларына да мирас итеп калдырган байлыгы. Әгәр боларның берәрсен хәтеребездән җуйсак, моның өчен безне йөз, мең елдан соң да гафу итмәячәкләр.

*Петр Ибаев*

***Октябрь***

Үзенең ачы җилләре, салкыннары белән, шулар өстенә беренче карын да күрсәтеп, октябрь безгә гүя тиздән ак тунлы кыш килеп җитәчәген искәртә. Ихтимал, шуңа күрәдер, бу айдагы сынамышларның күбесе кышның ничек килерен билгеләүгә багышланган. Табигать календаренда бигрәк тә искечә беренче октябрь (Покрау көне) һавасы нинди булуга әһәмият бирелә.

Беренче октябрьдә җил көн буена төньяктан булса, кыш салкын килер. Әмма җил көньяктан булса, кыш җылы булыр һәм киләсе елга ашлык яхшы уңар. Әгәр шул көнне җил көнбатыштан булса, киләсе елга ашлык уртача булыр.

Октябрьдә шөпшә һәм төклетуралар күренсә, кыш суык булыр.

Беренче октябрьдә кар күренсә, кырык көннән кар ятар.

Беренче октябрьдә җил көнчыгыштан булса, кышка суык китерер.

Покрауга кадәр кар төшсә, көз озын булыр.

Покраууда кар күренер.

Покрау үтте — кыш җитте.

Кар беренче октябрьгәчә күренсә, чана юлы тиз булмас.

Икенче октябрьгә кар яумаса, декабрьгә чаклы яумас.

Октябрь япмаса, декабрь япмас. (Яки «раштуа япмас» дип тә әйтәләр. Әгәр октябрьдә кар явып җир өстен капламаса, раштуага (искечә 25 нче декабрьгә) чаклы кар яумас дип көтелә.)

Җирле календарьда октябрь озак вакытлар «чек ае» дигән исем йөрткән. Соңрак аны «келәү ае» дип атый башлаганнар. (Элекке болгар телендәге «чек» шул ук келәүне аңлаткан.) Чөнки бу ай борынгы бабаларыбызның мәҗүси аллаларга дога-теләкләр багышлау, корбаннар китерү вакыты булган.

Көзге келәүләр арасында да күпчелекне җиргә багышланганнары алып тора. Мәсәлән, уңышны җыеп алганнан соң, уракчы хатын-кызлар арасында җир өстенә ятып аунау (җиргә орынып, аннан көч-куәт алу) йоласы озак вакытлар сакланып килгән. Бу вакытта алар түбәндәгегә охшаш теләкләр әйткән:

Җир! Җир! Көчем бир,
Ябага тайның көчен бир,
Алтын алма төсен бир,
Алты атның куәтен бир,
Алтмыш арба арыш бир,
Алтмыш арба бодай бир,
Алтмыш арба тары бир,
Бир, бир, барын бир!

Җир! Җир!

«Уҗым тавыгы» дигән икенче бер йолада крестьян, көзен үзенең уҗым басуына барып, шунда корбанга тавык суя һәм аның башын җиргә күмә торган булган.

*Александр Филиппов*

## 5—9 НЧЫ СЫЙНЫФЛАР ӨЧЕН

### Аллабыз бергә яраткан…

Шушы мәкаләне язарга дип кулыма каләм алганга, бер айлап вакыт узгандыр. Ләкин бер-ике җөмлә дә төзи алмадым. Туган якларына кеше күңелен күтәреп кайта, ә мин бөтенләй үк төшенкелеккә бирелеп кайткан идем шул...

...Әйе, киселгән икмәк кире ябышмый, дигәннәр. Бик дөрес әйткәннәр. Кеше шундый инде: эзләнә. Аның киселгәннәрне дә очын очка бәйлисе килә. Нишлисең бит...

«И, бу калхузлар турында ишетмәсәмие»,— дип, йөрәкләре белән әрнегән әтием. Утызынчы еллар урталарында ул туган авылына, карак сыман, төнлә генә кайткалаган. Кеше күзенә күренмичә, бер-ике кич өебездә кунганнан соң, тагын чыгып китәргә мәҗбүр булган. Бусаганы атлап чыкканда юатырлык сүзләр табалмыйча: «Ничава, Кәтернә, елама!» — дия торган булган.

«Чтапаның кая? Нигә калхузга кермисез?!» — дип йөдәткәннәр әнине. Башта маңгаена ак төшкән җирән атыбызны алып киткәннәр, аннары ике сыерыбызны... Инде ишегалдында сарык, казлар да калмагач, бер караңгы төнне, күрше Бирдебәктән атлы татарны яллап, кышкы салкында биш баласын чанага утыртып, Казанга юл тоткан әтиебез. Тапкан — тәки урнашырлык җир...

«Булмады бугай монда торулар...» — дигән ул Үри авылыннан чыгып киткәндә. Елап җибәргән әнигә тагын шул үзенең әйтә торган сүзләрен кабатлаган: «Ничава, Кәтернә...» һәм бу юлы: «Бу калхузлар озакка бармас. Исән булсак, бер кайтырбыз әле»,— дип өстәгән.

Кайталмады шул. Башта Халхин-Гол тирәсенә җибәрелде, аннары Финляндия сугышына алынды. Аннан исән-сау кайткач, Ленинград янында 1941 нче елда газиз башын югалтты. И әти...

Ә мин үзем Казанда туып үскән малай. Үри авылына беренче мәртәбә сугыш бетеп, ике-өч ел узгач кайткан идем. Ул чагында әле өебез дә исән, мине чукындырган Богородское чиркәве дә үз урынында тора иде. Авылда безнең нәселне — Уңайларны белүчеләр дә шактый иде. Әни белән өйдән өйгә йөрдек. Зиратка да кердек. Шагыйрь Яков Емельянов кабере белән янәшәдәге бабай кабере өстенә кыр чәчәкләре салдык.

Бу юлы инде бер эш тә эшләп булмады. Бабай каберен дә таба алмадым. Яков Емельянов чардуганы да юкка чыккан. Белүче-күрсәтүче юк. Уңайларның (ягъни безнең) нигезе кайда булганын, аларның зираттагы урыннарын белгән кешеләр Үридә калмаган. Хет кычкырып ела... Кемне гаеп итәсең инде! Без, зур калада атасыз үскән балалар, иман укый белмәдек. Олыгайгач та мул тормышны күрә алмадык. Авылдагы бабай каберен түгел, каладагы әни каберен дә рәтләп карарга җүн булмады. Менә хәзер юллар ачылды кебек, ләкин без утырасы поездлар еракка киткән шул.

Үридән Котлы Бөкәш автобусына чыкканда, Бирдебәк авылы аркылы узасың. Моңсуланып шул авылның иске зиратына кагылырга булдым. Монда тирә-якларда мәгълүм булган Хафиз әүлия каберташы саклангән. Бу изге урын дип санала. Биредә мөселман һәм христиан динендәгеләр дә, җае туры килгәндә, үзенчә бер келәү ясап китә иде. Әни мәрхүмнең болай дип әйткәне барые: «Бу Кәлпә бабай (аның хәтерендә Хафиз әүлия Хәлфә бабай булып калган) безне, керәшеннәрне, бу тирәләргә Агиделнең (әнием Кама елгасын шулай атый иде) аръягыннан алып килгән». Имештер, шул Хәлфә бабайның гыйбрәтле таягы булган. Бик борынгы заманда шул изге бабабыз таягын: «Тирә-якта яу булса, Чаллы җире сау булыр,— дип, күккә чөйгән дә: Әйдәгез, оланнар, шул таякның кая төшкәнен эзләп китик»,— дигән. Имештер, Хәлфә бабай таягы монда, Чаллы җирендә (хәзерге Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш төбәгендә) табылган.

Башта мин әни сөйләгәннәрне әкият дип кенә кабул иткән идем. Менә хәзер Хәлфә бабайның чын кеше буларак дөньяда торганын беләм. Ул әле чагыштырмача бик борынгы заманда түгел, XVII гасыр ахырларында яшәгән икән. Шуны белү мине үзенә күрә бер ачыш юлына бастырды.

Иң элек шуны әйтеп китәргә кирәк: ата-бабаларым авылының тулы исеме — Үри-Чаллы. Үри — югары дигән сүз. Минем нигә Югары Чаллы бер үзе генә Түбән Чаллысыз тора, дип уйлаганым бар иде. Тирә-якта Бирдебәк-Чаллы, Котлы Бөкәш-Чаллы, Тәбердино-Чаллы, Казан-Чаллы һәм башка «Чаллы» кушымталы (элегрәк алар барысы 24 булган) авыллар бар.

Ә Түбән Чаллы дигәне булмаган. Ә бит булырга тиеш!

Чынлап та, Түбән Чаллы хәзер дә бар икән. Ләкин ул Каманың аръягында, хәзерге Әлки районында урнашкан. Күренекле филолог һәм тарихчы, шәҗәрәләр белгече М. И. Әхмәтҗанов күрсәтүе буенча, шул Түбән Чаллы авылы — Хәлфә бабайның туган иле. Менә сиңа мә! Шулай булгач, Үри-Чаллы кешеләре чыгышы ягыннан түбән чаллылар (алар Чистай мишәрләре) булып чыгалар түгелме? Менә каян килә икән Үри авылы тулы Мещеряковлар! Ә бит әле моңарчы, Марсель Әхмәтҗанов фикеренчә, без үзебезне саф Казан татарлары дип йөрттек. Әгәр дә бүген түбән чаллылар арасында миндәге кебек сорау туса, «Чаллының Югарысы кайда?» дисәләр, белеп торсыннар: аның Котлы Бөкәш төбәгендәгесе — Үри-Чаллы авылы. Әлки районындагы Түбән Чаллы кешеләре чыгышы белән Сергач мишәрләре. Үземнең эзләнүләрем шуны күрсәтә: алар Кама аръягына 1682 нче елдан соң гына килгәннәр. Ә инде «Сергач мишәрләре» дигәннәребез үзләре, минемчә (кара: «Судьба гвардейцев Сеюмбеки» китабын), элеккеге Казан татарлары. Алар 1552—1556 нчы елларда хәрби әсир буларак эләккәннәр. Сергач мишәрләренең шактый озын буйлы, күбесе зәңгәр күзле, сары чәчле булулары күзгә ташлана. Мондый күренеш Үри-Чаллы һәм Түбән Чаллы кешеләрендә дә күзәтелә. Әйтерсең лә алар элеккеге замандагы полоняниклар (руслар) яки Төньяк Кавказ ягыннан килгән половецлар инде (руслар аларны да сары чәчле, зәңгәр күзле булганнар дип белгәннәр). Тарихи эзләнүләр шуны күрсәтә: половецларның бер төркеме — каз-ногайлар Казан каласының нигезен салганы, ә инде полоняникларның Казан ханлыгында озак еллар торып, шактые татарлашып бетеп, 1552 нче елда Казанны яклаучылар арасында булганлыгы мәгълүм. Менә йөр хәзер «син — рус», «мин — татар» дип!

Шушыларны исемә төшереп, Хафиз әүлия каберташы янында бераз тукталып тордым. Үземчә, эти-әни өйрәткәнчә, тийәберсен иттем. Саф ниятләрем элеккеге мөселман бабаларымның да хәтерен калдыр-мас. Бу уйларымны әле генә яңадан эшли башлаган Казанның Тихвин чиркәвендә, керәшенчә келәү иткәндә ныгыттым. 23 нче декабрьдә анда безнең туган телебездә тулы литургия башкарылды. Литургияне алып барган Казан һәм Татарстан архиепископы Анастасий төп дини кануннарны татар телендә җырлады. Чиркәүдә владыка руслардан берүзе генә булмады. Келәү итүче руслар, владыкага ияреп, барысы да татарча: «И Ходай, безне ярлыка! И Ходай, безне ярлыка! И Ходай, безне ярлыка!» — дип, бердәм Алла-бызга табындылар.

Чиркәү эче халык белән шыгрым тулы иде. Татар телендә алып барылган келәү белән кызыксынып, Тихвин чиркәвенә миңа таныш булган берничә мөселман татары да кергән иде. Минем бераз сәерсенеп китүемә, алар: «Аллабыз безне бергә яраткан бит»,— дип җавап кайтардылар. Әйе шул, туганнарым!

*Максим Глухов*

## Шигъри телебез

...Безнең шигъри телебез Һади Такташ, Фатих Кәрим һәм Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»ндәге шигырьләре белән ачылды. «Без» дип әйтүем, минем яшьтәшләрем, ягъни татар шагыйрьләренең Бөек Ватан сугышы белән яшьтәш булган тулы бер буыны турында түгел, ә Татарстанның элеккеге Шөгер районындагы Федотовка авылында үзем белән бергә уйнап үскән керәшен малайлары турында гына. Үркәй Бәчкәсе, Кируш Питере, Унтый Микайласы, Элүп Темәпейләр Җәгүре, Курый Сандыры, Шөрәй Әндрие, Җәмәк Сандыры, Марук Симуны һәм башка авылдаш чордашларым турында. Безнең шигъри телебез ни өчен нәкъ менә Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре», Һади Такташ һәм Фатих Кәрим шигырьләре белән ачылды соң, ни өчен бөек Тукай белән түгел? Чөнки борынибыз шигырь исен тоя башлаган 14—15 яшьлек үсмер чагыбызда безнең, тумышыбыздан бернинди гарәп һәм фарсы сүзләре дә кушылмаган саф төркичә татар телендә тәрбияләнгән керәшен малай-кызларының, Тукай поэзиясенә тешебез үтми иде. Ә менә Такташның соңгы чор, Фатих Кәримнең сугыш чоры, Муса Җәлилнең Моабит чоры поэзияләре нәкъ менә безнең авылдагыча саф татар телендә язылган.

Халкы христиан динендә булу сәбәпле, гарәп алфавитындагы татар язма культурасы бөтенләй кереп тә карамаган безнең авылда тирә-як төбәктә бердәнбер булган унъеллык мәктәп эшли иде. Кайчандыр Риза

Фәхретдинов үзе мөгаллим булган Чыршылы, Кол Галинең Утыз Имәни тарафыннан фәнни эшкәртелеп, аның улы үз кулы белән күчереп язган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының фәндә өченче нөсхә дип йөртелгән кульязмасы мәчет түбәсеннән табылган Сарабиккол, татар халкы тормышында мәгълүм эз калдырган шәхесләр биргән Елховой, шулай ук уку-язу культурасы борынгыдан югары булган Куакбаш, Кирлегәч, Ормышлы кебек атаклы мөселман татар авылларының кыз-малайлары, үзләрендә җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң, безнең керәшен авылына килеп, өч ел укый, урта белем ала иде.

Һичшиксез, туган авылларында, туган өйләрендә гарәп
һәм фарсы алынмалары киң кулланылган, азмы-күпме элекке китаплардан, властьлардан яшереп кенә, укылган дини «Кисекбаш», «Кыйссаи Йосыф» һәм башка ярым дини, ярым дөньяви әсәрләрдән «авыз иткән» ул малайлар һәм кызлар, инде безнең авылга килгәнче үк, Тукайга соклану дәрәҗәсенә менеп җиткән булганнардыр. Шулайдыр, югыйсә безнең авылга алар килеп укымаса, 1954—1957 нче еллар тирәсендә безнең Федотовка рус мәктәбендә «Яшь иҗатчы» дигән кульязма әдәби журнал чыга алган булыр иде микән? Табигый, журнал нибары бер данә тираж белән чыгарыла иде. Хәтерем ялгышмаса, ул берничә дистә сан чыкты бугай. Аның бер саны әле бүген дә минем архивта сакланып калган. Мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мөлекова Сажидә апаның бик дәртле редакторлыгы астында бу журналның эчтәлеге, бизәлеше һәм әсәрләре шул чорда дәүләт тарафыннан басылган журналлардан ким түгел иде. Журнал чыгуга, мәктәп китапханәсенә куела, укытучылар һәм укучылар тарафыннан бик яратып укыла. Шул ук вакытта журналда мәктәптә укучылардан байтак автор катнаша иде. «Яшь иҗатчы» журналында безнең авыл мәктәбендә укыган, Казан телевидениесенең «Татарстан» программасы корреспонденты Мөкаддәс Юсупов күп кенә шигырьләрен бастырды.

Миңа иң беренче шигырь җене әнә шул журналдан кагылмады микән?.. Такташлар, Кәримнәр, Җәлилләр белән бергә... Ул журналда мин үзем дә берничә шигырь бастырдым, кызганычка каршы, хәзер миндә үз шигырем урнашкан бер сан да сакланмаган.

Әйе, бу чакта да әле минем бөек Тукайга тешем үтми иде. Тукайга мин бары тик 1963—1964 нче елларда, Казан дәүләт университетының икенче-өченче курсларында гына төшенә башладым. Минем алда бөтенләй икенче шигъри дөнья ачылды.

*Гәрәй Рәхим*

## Олы көн истәлекләре

Гомер узган саен, күңелдә әлеге бәйрәм белән бәйле истәлекләр яңара. Балачак хатирәләре беркайчан да онытылмый, күңелдән юылмый икән ул. Туган авылым Зичәбашны мин күп вакыт менә шушы Олы көннәре аша искә төшерәм. Бу көнне бөтен авыл халкы сандыгында саклана торган иң затлы әйберләрен алып кия. Олы көнгә каршы төндә йокларга ярамый инде. Башка вакытта кәрәчинне бик сак тотучы хуҗалар да унлы лампаны ялт итеп кабызып куя. Хуҗабикәләр иртәнгә кадәр тәм-том өлгертә, әче һәм төчегә басылган камырлардан күмәч, крендель, пилмән, шишәрә, тагын әллә ниләр пешерә.

Пасха йомыркасы пешерү — иң изге йолаларның берсе. Тәүрат язмаларына караганда, ул кызыл төстә булырга тиеш. Ни өчен йомырка? Ни өчен кызыл? Бу турыда соңрак. Мич, казан тирәсендә гаиләдәге бөтен кешегә дә эш табыла. Тик утырасың икән, күзне йокы баса. Йоклап китсәң, изге зат төннең бер мизгелендә бәхет өләшкәндә коры калуың ихтимал. Ә кемнең бәхетле буласы килми?

Имеш, бәхетне эңгер-меңгер вакытта өләшеп йөриләр икән. Әнием шулай ди торган иде. Нәкъ менә шул вакытта, тып-тын урамнарга җан керә торган иде. Бала-чага берәмләп тә, парлап та өйгә килеп керә дә: «Коткаручы яңадан туган!» («Христос воскрес!») — диләр. Йорт хуҗасы да аңа: «Чыннан да, яңадан туган!» — дип җавап кайтара, аңа кызыл йомырка һәм башка бүләкләр бирә. Өлгеррәкләр өйләренә киндер букчаларын төрле төскә буялган күкәйләр белән таң атканчы ук тутырып кайта.

Кызыл йомырка бүләк итү йоласы кайдан башланган? Архимандрит Никифор тарафыннан төзелеп, 1891 нче елда Мәскәүдә басылган «Библия энциклопедиясе» китабында язылганча, кызыл йомырка бүләк итү гадәте Мария Магдалинадан башлана. Ул, Римга барып, император Тиверий каршына килеп, аңа: «Коткаручы яңадан туды!» — дигән сүзләр белән кызыл йомырка бирә һәм вәгазь укый. Биредә йомырка — тормыш символы, ә кызыл төс — Коткаручы каны. Бу — мәңгелек тормыш дигән сүз. Авылда, әлбәттә, бу символны бик үк аңлап та бетермәгәннәрдер. Шуңа күрә йомыркаларда да салават күперендәге барлык төсләр дә чагыла иде.

Пасха көне истә калган.

Пасха, дини бәйрәм булудан бигрәк, безнең күңелләргә яз бәйрәме, күңел ачу көне буларак кереп калган. Безнең авыл текә тау итәгенә урнашкан. Тау итәгенең буеннан-буена мул сулы чишмәләр бәреп

тора, һәр чишмә чыккан җиргә имән агачыннан юнып ясалган кәшәне (часовня) куелган. Дингә ышанучылар, чир-сырхаудан арынырга теләп адарынучылар аның уеп эшләнгән куышлыгына вак акчалар куеп калдыра.

*Александр Филиппов*

## Татарлар кемнәр алар?

«Төрки» төшенчәсе өч мәгънәгә ия. VI—VIII гасырларда ул — Бөек далада гаять зур берләшмәне җитәкләгән һәм VIII гасыр уртасында һәлак булган бәләкәй этнос. Бу төркиләр — монгол кыяфәтле халык. Алардан хазарлар династиясе барлыкка килә, ләкин соңгылары дагыстанлы рәвешендәге европалылар була. IX—XII гасырларда «төрки» сүзе сугышчан төньяк халыкларын, шул исәптән маҗарларны, русларны һәм славяннарны аңлаткан. Бүгенге Шәрык белгечләре өчен «төрки» — чыгышлары белән төрле этностан булган халыклар сөйләшә торган телләр төркеме.

...IV гасырда Бөек төрки каганлыгы. Җиңүләрнең җимешләрен бүлү нияте белән, яулап алучыларга ярдәм итүне кулай күргән кавемнәр рәтенә хазарлар һәм Кубань белән Дон арасында яшәгән кутригур болгар кабиләләре дә керә. Ләкин Көнбатыш Төрки каганлыгында ике кабилә союзы, көчсез ханны үз йогынтыларына буйсындыру өчен, көрәшүче ике партия оештыра. Кутригурлар — аларның берсенә, ә хазарлар, табигый инде, икенчесенә кушыла, ә ул җиңелгәннән соң качкан ханзадәне үзләренә хан итеп кабул итәләр. Сигез елдан соң Көнбатыш Төрки каганлыгы Тан империясе гаскәрләре тарафыннан яулап алына. Бу — элек җиңелгән ханзадәне яклаган хазарлар өчен файдалы була, ә олы ханның ярдәменнән коры калган кутригур болгарларга зур зыян китерә. Шуның нәтиҗәсендә хазарлар 670 нче еллар тирәсендә болгарларны тар-мар итә, тегеләре кайсы-кая: берәүләре — Камага, икенчеләре — Дунайга, өченчеләре — Венгриягә, ә кайберәүләре исә хәтта Италиягә үк кача.

...Болгарлар бердәм дәүләт төземи: Кубань буйларында яшәүче көнчыгыш кутригурлар һәм Дунайның түбән өлешендә Дон арасында көн итүче көнбатыш кутригурлары үзара дошманлашып тора һәм көнчыгыштан килгән яңа баскыннарның табышына әйләнә. Кутригурларны аварлар (дөресрәге, жевдоаварлар яки вархонилар), утургурларны төркиләр буйсындыра.

...922 нче елда Кама болгарлары башлыгы Алмыш ислам динен кабул итә һәм, Багдад хәлифенең ярдәменә исәп тотып, үзенең дәүләтен Хазарстаннан (төрки каганлыгы җиңелгәннән соң, ул аңа буйсынган) аера. Ул, хәлиф мөселман гаскәрләрен диндәшләренә каршы сугышудан тыяр, дип өметләнә. Моннан тыш, ул хәлифтән «үзен буйсындырган яһүдләргә» каршы кала торгызу өчен акча сорый. Хәлиф җәзалап үтерелгән вәзиренең тартып алынган утарын сатарга һәм аннан кергән акчаны илче Ибне-Фазланга тапшырырга әмер бирә. Ләкин сатып алучы илчеләр кәрванын куып җитә алмый һәм Болгарда кальга төзелми кала. Ә X гасырда хәраземлеләр тәмам көчсезләнгән Багдад хәлифенең боерыкларына игътибар бирми башлый...

Диннән баш тарту Бөек Болгарны ныгытмый, ә йомшарта гына. Өч болгар кабиләсенең берсе суваз (чувашларның ата-бабалары) исламны кабул итүдән баш тарта һәм Идел аръягындагы урманнарга урнаша. Таркала барган Болгар державасы яһүди Хазария белән ярыша алмый башлый.

...985 нче елда Киев кенәзе Владимир Кама болгарлары һәм хазарлар белән зур сугыш ача. Беренчеләре, ягъни Кама болгарлары белән сугыш уңышлы булмый. Шуннан соң походка җитәкчелек иткән Владимирның әнисе ягыннан туган абыйсы Добрыня, итек киеп йөри торган болгарлар йолым түләмәячәкләр, шуңа күрә чабаталыларны эзләргә кирәк, дигән сәер фикергә килә. Болгар белән мәңгелеккә солых төзелә, ягъни Владимирның хөкүмәте Кама Болгарстанының мөстәкыйльлеген таный.

...971 нче елда Владимир Кама болгарларына каршы тагын яу чаба.

...XII гасырда Идел болгарлары Суздаль һәм Муром белән барган бетмәс-төкәнмәс сугышларны, әсирлеккә кызлар урлап кайту өчен, үзара талау гамәлләренә кайтарып калдыралар. Болгарлар үзләренең гаремнарын тулыландыра, ә русичлар зыянны төрки кызларын урлап кире кайтара. Иң кызыгы шул: катнаш никахлардан туган балалар законлы дип санала, ләкин генофонд алмашу күрше ике этносның берләшүенә китерми. Генетик кушылуга, икътисади һәм социаль охшашлыкка, географик җирлекнең бердәм булуына, Болгардагы һәм славяннардагы күпчелек халыкның ике бөек диннең кануннарын өстәнөстән белүенә дә карамастан, православие һәм ислам русичларны һәм болгарларны аерып тора.

...Монголиянең төньяк-көнчыгыш өлешен һәм аңа чиктәш далалы Байкал арты өлкәләрен болгарлар һәм монголлар үзара бүлешә.

...Монголлар белән татарлар арасында әледән-әле сугышлар чыгып торган. Без «монголоидлар» дип атап йөргән антропологик тип үзе дә, теле белән дә нәкъ менә татарларга охшаш була. Елъязмачыларның әйтүенә һәм табылдык таш сурәтләргә караганда, борынгы монголлар озын буйлы, сакаллы, аксыл чәчле һәм зәңгәр күзле булганнар. Аларның токымнары бүгенге кыяфәтләрен күршеләрендә яшәүче кыска бу-

лы, кара чәчле һәм кара күзле кабиләләр белән күп санлы никахларга кереп алганнар. Соңгыларын тирәякта яшәүче кавемнәр җыеп кына «татарлар» дип йөргәннәр... Елъязмачы Рәшит-Дин: «Үзләрен татар дип атап һәм шул исем астында танылып күп кенә ырулар олпатлыкка һәм дәрәҗәләргә ия булдылар»,— дип язып калдырган...

«Татар» төшенчәсенең җыелма мәгънәсеннән чыгып, урта гасыр тарихчылары монголларны татарларның бер өлеше дип караган, чөнки XII гасырга кадәр Көнчыгыш Монголия кабиләләре арасында нәкъ менә соңгылары өстенлек иткән. XIII гасырда татарларны, шушындый ук киң мәгънәсендә, монголларның бер өлеше дип йөрткәннәр. Инде «татар» атамасы Азиядә юкка чыкса да, Алтын Урдада яшәгән Идел буе төркиләре үзләрен шул исем белән атый башлыйлар. XIII гасыр башында «татар» һәм «монгол» атамалары синонимнар рәвешендә була. Моның үз сәбәпләре бар. Беренчедән, «татар» атамасы гадәти һәм күпләргә мәгълүм, ә «монгол» исеме бөтенләй яңа төшенчә була. Икенчедән, байтак татарлар (тар мәгънәсендә) монгол гаскәрләренең алдынгы отрядларын тәшкил иткән. Чөнки аларны кызганып тормаганнар һәм иң хәвефле урыннарга куйганнар. Урта гасыр тарихчылары көнчыгыштагы күчмә халыкларны «ак», «кара» һәм «кыргый» татарларга бүлгән.

...Монголлар өч фронтта, шул исәптән Кама болгарларына каршы сугыш алып барган. Аларның сан буенча да, техникада да өстенлек алырга мөмкинлекләре булмый, ләкин шулай да 1260 нчы елга кадәр һәр җирдә җиңүгә ирешәләр.

...Сугышларның иң дәвамлысы һәм кискене Бөек дала эчендә бара... Фәкать 1206 нчы елда гына гомуммонгол дәүләте туа.

...80 меңгә якын сугышчыдан торган рус-кыпчак гаскәрләре чигенеп баручы монголларны Калка елгасына кадәр эзәрлекләп баргач һәм анда тәмам тар-мар ителгәч, монголлар Көнчыгышка юл тота, ләкин, Идел аша кичкәндә, болгарлар тарафыннан җиңелә. Камаудан бик азлары гына исән-сау чыгып, өйләренә әйләнеп кайта ала.

...1236 нчы елның көзендә монгол гаскәрләре Бөек Болгарны ала, ә 1237 нче елның көзендә аланнарга һәм кыпчакларга һөҗүм итә.

...Мөселман солтанлыгы булгач, Алтын Урдада «бөек фетнә» чыга, шуннан соң дәүләтнең таркалуы, Казан, Кырым, Себер, Әстерхан татарларына һәм казакъларга этник бүленеш башлана. Монгол яулары XIII гасырга кадәр яшәп килгән гаять тотрыклы һәм бөтен булып тоелган барлык этник берлекләрне тәмам бутап, кушып бетерә. Кайберләреннән фәкать исемнәре генә кала, ә башкалары, татар дигән җыелма төшенчә белән алыштырылып, атамаларын да югалта.

Кырым татарлары исә бөтенләй башка этностан...

*Лев Гумилевтан*

## Түгәрәк уен

Җәй көне, инде язгы кыр эшләре тәмамланып, җәйгә күчкән бер мәлдә, әле печәнгә, уракка төшәргә вакыт килеп җитмәгән чагында, авыл кызлары һәм егетләре бергәләшеп тә, төркем-төркем булып та, төрле түгәрәк уеннар оештыра. Шуннан авылның ничек яшәвен аңлыйсың инде. Уен бер генә урында узса, димәк, бу авыл тату яши. Уеннар төрле урыннарда булса, димәк ки, теге яки бу оч яки урам яшьләре бәхәстә тора. Түгәрәк уен авыл яшьләрен һәм кызларын берләштерүче, дуслаштыручы чара булып тора.

Керәшен авылларында мондый уеннар, гадәттә, шәһит киткән туганнарны искә ала торган Симек бәйрәменнән башлана һәм Питрауга кадәр дәвам итә. Кызлар, әлбәттә, бу кичке уеннарга үзләренең иң яхшы киемнәрен киеп, тәңкә-хәситәләрен тагып чыга. Егетләр дә кызлар алдында сынатмаска — фырт киенергә тырыша. Крестьян тормышы шактый авыр булса да, елга буйлары яшьләрнең түгәрәк уеннарыннан, үзәк өзгеч озын җырлардан, күңелләрне җилкендереп типтереп биюләрдән шау-гөр килеп торган. Бу уеннар таң сызылып атканчыга кадәр дәвам иткән.

Җыр запасы саегып киткәндә, берәрсе шунда ук үз сүзләренә яңа такмак башлап җибәрә.

Җырларның һәркайсы ике вариантта — кыска һәм озын итеп башкарылырга мөмкин. Урамнан барганда, башкаларны уенга чакыру рәвешендә, кыска көйгә салып җырлана. Ә инде түгәрәккә кергәч, салмак адым көенә, озын итеп башкарыла. Уенда никах яшенә җитмәгән яшь кызлар да катнаша. Уенның башлап җырлаучысы була. Түгәрәккә үсмерләргә дә керергә ярый. Әмма алар җырда катнашмый. Уенның иң кызган вакыты Тройсын һәм Питрау көннәрендә була. Питраудан соң, барлык кошлар сайраудан туктаган кебек, мондый уеннар да оештырылмый.

*Александр Филиппов*

**Керәшеннәр**

Татар халкының үзенчәлекле бер төркеме, субконфессиональ (дини) берлек буларак, керәшеннәр ике этапта формалашкан. XVI йөзнең икенче яртысында — XVII йөзләрдә «иске керәшеннәр» дип билгеле булган төркем оеша, ә XVIII гасырның беренче яртысында «яңа керәшеннәр» барлыкка килә. XVIII—XX йөз башларында керәшеннәрнең төп өлешен «иске керәшеннәр» тәшкил иткән.

XIX йөз башларыннан көчләп чукындырылган татарлар арасында яңадан мөселман диненә әйләнеп кайту башлана.

XIX гасырның беренче чирегендә Казан губернасындагы 31,1 мең керәшеннең 13,4 меңе «иске дингә кире кайтырга» әзер була. Мөселманлыкка кире кайту хәрәкәте керәшеннәр арасында 1860 нчы елларда массакүләм төс ала. Гомумән алганда, 1866—1868 нче елларда керәшеннәрдән мөселман динен тотуга 12 мең ир кеше күчә (Казан губернасы буенча). Бу губернаның кайбер өязләрендә 1883 нче елга керәшеннәр бөтенләй калмый (Тәтеш, Зәй өязләре күз алдында тотыла). «Мөселманга» күчүдә төп рольне «яңа керәшеннәр» уйный.

Мәсьәләнең асылында төп бер проблема яткан: керәшеннәрне мөстәкыйль халык дип санаргамы, әллә юкмы? Билгеле булганча, 1917—1920 нче елларда керәшеннәрнең төрле берләшмәләре барлыкка килә. 1920 нче елны Казанда керәшеннәрнең Бөтенроссия съезды булып уза. Анда капма-каршы ике агым формалаша: берсе — «Мәдәни политик автономия» яклылар, икенчесе — татарлар (мөселманнар) белән якынаюны яклаучылар. Съезд вакытында ике агым вәкилләре килешә алмый.

1921 нче елның 19 нчы мартында булган коммунист керәшеннәрнең Өлкә конференциясендә керәшеннәрнең «Милли-мәдәни автономиясенә» каршы карар кабул ителә. Бу карарны нигезләгәндә, шундый кызык дәлил китерелә: «...Милли-мәдәни автономия... РКП(б) программасына каршы килә». Ләкин керәшен коллегиясе (ул Казан губерна милләтләр бүлегенең керәшен бүлекчәсе урынына төзелгән була) 1922 нче елга кадәр «Милли-мәдәни автономия» линиясе буенча бара. Ә менә 1922 елны шул ук орган керәшеннәрне татарлар белән механик рәвештә кушуны яклый башлый (мәктәпләрне, газеталарны берләштереп). Шушы нигездә керәшеннәр ягыннан каршылыклар килеп чыга. Юкка гына 1922 нче елда керәшен проблемасы буенча махсус комиссия төзелмәгәндер.

Бу комиссия ясаган нәтиҗәләр шактый тирән мәгънәле, аларны тулырак китерик. Иң беренчесе: керәшеннәрнең татарлар (ягъни, мөселман татарлар) белән кушылуы принципиаль рәвештә мөмкин. Ләкин моның өчен, бигрәк тә кушылу «зыянсыз» барсын өчен, керәшеннәрне моңа хәзерләргә кирәк, шул исәптән «хезмәт интеллигенциясендә психологик үзгәреш тудыру» әһәмиятле. Китерелгән фикерләрдән яхшы күренә: керәшен мәсьәләсенең гади чишелеше булмаган һәм аның шулай икәнлеген Татарстан җитәкчеләре 20 нче еллар башында тиз төшенгән. Өч ел үткәч, комиссия материалларында мондый юлларны укырга була: «Керәшеннәрне татар массалары белән якынайту һәм кушу эше «ялган милләтчеләрне фаш итү, миссионерлар һәм клерикаль элементлар йогынтысыннан арындыру» аркылы алып барылган. Шулай ук керәшеннәрнең «барлыкка килүләре» киң яктыртылган, ә мәктәпләрдә уку татар язуына (гарәп графикасына) күчерелгән. 1920 нче еллардагы большевистик алымнарны күз алдына китергәндә, төшенергә була — бу «якынаю» һич тә демократик була алмаган («ялган милләтчеләрне» фаш итү генә нәрсә тора!). Шуңа күрә комиссиянең 1925 нче елны ясаган нәтиҗәсен тәнкыйть күзлегеннән карарга кирәктер. Ә нәтиҗә мондый: «Керәшен укытучыларының күпчелеге үзләренең элекке карашларыннан баш тартты, керәшен массаларының психологиясендә... татар массалары белән якынаюда билгеле бер үзгәреш булдырылды». Фактлар исә икенчерәк нәрсәне күрсәтә. Әйтик, 1926 нчы елгы халыкны исәпкә алу вакытында Идел-Урал регионында 120 мең кеше үзен милләте буенча «керәшен халкыннан» дип яздыра. (Шушы төбәктәге татарларның 4,8 проц.)

Һичшиксез, XX йөзнең беренче чирегендә керәшеннәрнең татар милләте белән кушылуы әле төгәлләнмәгән була. Якынаюның акрын баруы дини аерымлыкларның бу чорда зур әһәмияткә ия булуы белән аңлатыла. Бер яктан, ислам Идел-Урал буе татарларының милли аңы формалашуда әһәмиятле урын тота, милләтне консолидацияләүнең бер этәргече була. Ләкин нәкъ менә шушы мәсьәлә буенча керәшеннәр мөселманнардан башка позициядә тора. Дөрес, алдагы елларда ике арада якынаю арта, шул исәптән диннең йогынтысы кимү сәбәпле дә. Әмма керәшеннәрнең мөстәкыйль рәвештә үсү потенциалы бөтенләй үк бетми. Әгәр дә соңгы вакытларда татарлар арасында милли аңның үсүе күзәтелә икән, бу хәл керәшеннәрдә башкачарак юллар белән бармый булдыра алмый. Тарихи алшартлар шуңа китерә. Моны һәркем истә тотарга тиеш. Безнең фикеребезчә, керәшеннәргә карата мөнәсәбәт буенча иң уңышлы формула ТИҮ платформасында язылган. Анда болай диелә: «...безнең хәрәкәт тарихи сәбәпләр аркасында башка конфессиядә (диндә) булган татарларга (керәшеннәргә) хөрмәт белән карый, үзләренең киләчәктәге рухи үсеш юлларын алар үзләре билгеләргә тиеш дип саный».

*Дамир Исхаков*

## Керәшеннәр каян килеп чыккан?

*(Төрки христианлык турында)*

Тарихи мәгълүматларга караганда, төркиләрнең бер өлеше IV—V гасырларда ук христианлыкка күчкән булган. Бу түбәндәгеләрдән нәтиҗәләнә: беренчедән, Византия императорларының төрле һун-болгар кабиләләренә миссионер җибәргәнлеге һәм хәтта Библияне болгар теленә тәрҗемә иткәнлеге Рум (Византия) чыганакларында әйтелә; икенчедән, V—XII гасырларда хәзерге Казакъстан һәм Кыргызстан җирләрендә шактый күп санлы христиан каберлекләре һәм алардагы төрки телдә язылган башбаталар сакланган. Бу соңгыларын шунда яшәгән несториан общинасы язып калдырган. Несториан христианнар бүтәннәрдән гадирәк һәм мантыйклырак фәлсәфә белән аерылып торган (мәсәлән, алар Алла-Мәрьям-Гайсә өчлеген бердәй «троица») дип тәсаувыр итүне берничек аңлый алмаганнар.

Кайбер гарәпчә чыганакларда IX—X гасырларда Идел болгарларының бер өлеше (бер кабиләсе) христиан булуы хәбәр ителә. Алар, мөгаен, несторианнар булганнар, күрәсең, чөнки ул вакытта кайбер төрки кабиләләр, Болгар җирләрендә җәйләп, көньяк Казакъстан (Жиде-су) өлкәсендә кышлап, күчмәчелектә көн иткән.

Тел материаллары бу тарихи чыганакларның дөреслеген дәлилли. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, христианлыкка караган кайбер төшенчәләр һәм сүзләр әвәлдән бирле яшәп килүе хак: «чукыну» сүзе үзе, Олы көн (Олысның Олы көне), «пасха», «кулугур», «монах» һәм «тәре» сүзләре шундыйлардан. Бу мәкаләдә сүз шулар турында барачак.

*Чукыну* сүзе барлык Идел-Урал телләрендә (керәшеннәрдән тыш тагын чувашларда, мариларда һәм удмуртларда) бар. Чыгышы вә таралышы буенча ул гомумтөрки сүз: *Чокунмак* фигыле борынгы төрки ядкарьлекләрендә дә бар. Аның рефлекслары барлык кыпчак төркиләрендә һәм Урта Азия халыкларында да очрый.

*Чукынуның* төп мәгънәсе үзеңнең маңгаеңа, иңнәреңә һәм күкрәгеңә төртеп, хач символын сурәтләүдер. Киңрәк мәгънәдә бу сүз христианлыкка күчүне белдерә.

Безнең карашка *чукынмак, чокынмак* алтай төркиләрендәге *чогын-чокын* — «утка табыну, утка корбан китерү» сүзе белән бер. Ә бу нигез исә, Алтай-Саян төркиләрендәге *чок, чог*, кыпчак халыкларындагы *чок, чөк,* татар һәм чувашлардагы *чүк* — «җәйге (кайбер урыннарда көзге) корбан чалу», баштарак «утка корбан чалу» сүзе белән тамырдаш. «Чүк» сүзе һәм йоласы бигрәк тә керәшеннәрдә яхшы сакланган. Себер төркиләрендә *чүк* бәйрәменең төп элементларының берсе — учак ягып, шул учакка сөт сибү һәм ритуаль биюләр башкару булган.

Этимологлар чуваш һәм марилардагы «чүк» сүзен татар теленнән, татар мәҗүсилегеннән алынган, диләр. Ахыр чиктә ул борынгы төрки *чог* (хәзерге монголча *цог*) «ут, утлы күмер» сүзенә кайтып кала (шуннан ук *чуак* — утка кызыну һәм чуал), «туры мержәле мич» сүзләре дә ясалган.

Хуш, утның, утка табынуның чукынуга нинди мөнәсәбәте бар соң? Хикмәт шунда: борынгы төркиләр утка табынучы иран халкы *сугъдиләр* белән бик нык аралашып яшәгән (хәтта төркиләр шул сугъдиләрдән килеп чыккан дигән фикер дә бар). Утка табыну рәвеше дә чукынуга охшаш булган. Аннары христиан динендә дә утка табыну элементлары бик көчле: икона янына шәм кую, чиркәү шәмнәре (лампадалар), Иерусалимнан Изге ут алып кайту йоласы һ. б.

Борынгы төрки христианлыктан тагы Пасханы бәйрәм итү дә калган. Пасха христиан дөньясында Олы көн мәгънәсендә-ге сүзләр белән аталган кебек, төркиләрдә (бигрәк тә кыпчакларда) да Олы көн дип атала. Бу сүз безнең Урта Идел регионындагы барлык телләрдә дә охшаш кәлимәләр белән белдерелә: чувашча *мын кун,* марича *кугу кеге* (күгүгече), удмуртта *бажҗым нунал* «Пасха» — барысы да «*зур*» (олы) дигән сүз. Мөселманлыкта кырдагы тикшеренүләр — эзләнүләребез нәтиҗәсендә шул мәгълүм булды: Тау ягы мишәрләре эндәшми-сөйләшми торган кешеләрне *клугур, кулугур* дип атыйлар икән. (Хәер, хәзер бу сүз сирәк очрый инде.) Мишәрләр Казан тирәсендәге татарларны эчкерле һәм дәшмәки дип беләләр һәм шуңа күрә аларны да *клугур, лугур, нугур* дип атыйлар. Бәлки бу сүздә төрлечә сүзләрнең кушылышуы-буталышуы бардыр. Тик шунысы хак: «кулугур» сүзе аралашмаучан, кире кеше мәгънәсендә Алтай-Саян төркиләрендә еш очрый һәм Идел буе русларында да кулланыла. Асылда, бу сүз грекча *кулагер, кулогер* «христиан монахы» сүзенә кайтып кала. Мәгълүм ки, христианлыкны уйлап чыгаручылар булмаса да, кужытып-көчәйтеп җибәрүчеләр — греклар. Несторианнарның дин телләре һәм дини терминологиясе дә

грекча булган, һәм әгәр «кулыер» сүзе үзәк Азиягә барып җиткән икән, бу хәл тик несториан христианнар арадашчылыгы нәтиҗәсендә генә була ала.

Инде «тәре» сүзенә килик. Татар телендә (тик бу телдә генә!) бу сүз хачны да, иконаны да белдерә. *Тәре баганасы* дип элек руслар юл чатларына кузырлап (өстән кыяклап) куйган икона беркетелгән баганаларны атый. Ләкин, асылда, бу сүз Алланың синонимы булган *Тәңренең* үе бит! Мишәр диалектының каратай сөйләшендәге Тэйри һәм карачай-балкар телендәге Тойри — Алла, Тәңре: күк (күкрәү) Алласы гомумтөрки «тәңре» сүзеннән килеп чыкканлыгы күренеп тора. Тәңре — күк һәм яшен Алласы — барча төркиләргә дә, монголларга, тунгус-маньчжурларга һәм бүтән Себер халыкларына яхшы таныш бирдәнбер Алла.

Мәгълүм ки, католик руханилары XI гасырдан башлап көнбатыш төркиләр, бигрәк тә кыпчак-куманнар арасында миссионерлык эшен җәелдергән. Һәм, күрәсең, христиан Алласы идеясен халыкка җиткерер өчен, Алланы Тәңрегә тиңләгәннәр. Христиан миссионерлары, гарәпләрдән үзгә буларак, мәҗүсиләрнең телен, фольклорын тырышып өйрәнгәннәр һәм үз максатларында файдалана белгәннәр. Борынгы куман теле һәм авыз иҗаты турында ачык мәгълүмат бирә торган атаклы «Куман мәҗмугасы» («Кодекс куманикус») католик миссионерларының һиммәте нәтиҗәсендә пәйда булган бит! Ул миссионерлык Алтын Урда чорында да дәвам иткән, һәм, һичшиксез, күп кенә кыпчаклар христиан диненә күчкәннәр дип уйларга нигез бар.

Болгар һәм Казан дәүләтләре чорында Урта Иделдә төрле-төрле христианнар, мәсәлән, әрмәннәр яшәп килгән. Татар телендәге «хәчтерүш» сүзе, чувашларда *качикруш батыр* атамасы, әрмәнчә хачикруш «христиан», «тәре такмыш» сүзенә кайтып калса кирәк («хач» сүзе үзе дә бездә әрмән теле ядкаре).

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: бүгенге керәшеннәр, һичшиксез, XVI—XVIII гасырларда көчләп чукындырылган татарлардан гына тормый. Алар арасында бабалары инде мең елдан артык христиан булганнары да бар.

*Рифкать Әхмәтьянов*

## Керәшеннәрнең сөйләшү үзенчәлекләре

Казан артында — Лаеш, Балык Бистәсе, Питрәч, Саба, Теләче, Мамадыш, Кукмара районнарында яшәүче керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре ягыннан караганда, Казан арты керәшеннәре сөйләше берничә урынчылыкка бүленә: Мишә елгасы буенда яшәүче керәшеннәрнең сөйләше; Ташкирмән авылында яшәүче керәшеннәрнең сөйләше; Пакшин авылы керәшеннәре сөйләше; Вятка елгасы буенда яшәүче керәшеннәрнең сөйләше; Кама елгасы буенда яшәүче керәшеннәрнең сөйләше; Шушма елгасы буенда яшәүче керәшеннәрнең сөйләше; Кукмара районында яшәүче керәшеннәрнең сөйләше.

## Кәвәл авылы көе

Суда балык җөзәдер лә,
Су салкынын сизәдер шул, сизәдер;
Аулыгызда бер матур бар,
Үзәгемне өзәдер шул, өзәдер.

Әкрен кирәк, иплəп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Шомырт кара чәчләре лә
Шомарадыр тараса, ай, тараса;
Күңелемә җал буладыр
Бер җылмаеп караса, ай, караса.

Әкрен кирәк, иплəп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Башыңа җапкан җаулыгың
Җаңа җауган кар кебек, ай, кар кебек;
Җөзләрең тулган ай кебек,

Акылың сары май кебек, ай, май кебек.

Әкрен кирәк, иплəп кирәк,
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Түбән Кама шәһәрендә һәм Түбән Кама шәһәре тирәсендәге — Алабуга, Минзәлә, Әлмәт, Зәй шәһәрләрендә һәм районнарында, Тукай районында һәм Башкортстанның Бакалы районында яшәүче керәшеннәр.

## Безнең ил

Башларыма кигән эшләпәмнең
Сиксән сигез икән өлгесе.
Килгәннәрдән бирле карап торам,
Сез икәнсез дөнҗа көзгесе.

Кушымта:

Безнең ил — сандугач сайрар җир лә,
Безнең ил — уйнап-көлер җир.

Алма бакчасына, ай, керәем,
Матур кызлар алма җыядыр.
Җөзләрегез якты, сүзегез татлы,
Күңелләрем сезне сөядер.

Кушымта.

Салкын чишмәләргә чиләк куйдым,
Мөлдер генә мөлдер тулсын дип.
Сезләр моңайганга без җырлыйбыз,
Күңелкәйләрегез булсын дип.

Кушымта.

## Баграж сулары ла борма-борма...

*Баграж суларына басма салдым,*
*Узган — барганнарда керергә...*

*(Баграж керәшеннәре җырыннан)*

Баграж суларының буйларында
Тал чыбыклар үсә йөз генә.
Бик сагындым сезне, туганнарым,
Иң якыннарым бит сез генә.

Баграж буйларының тирәкләрен
Кайтканнар ла саен саныймын.
Сандугачлар кебек сайрашасыз —
Җырларыгыздан ук таныймын.

Баграж сулары ла борма-борма,
Бормалары саен бер алан.
Һәрчак яныгызда булыр идем
Аланнарда булсам бер балан.
Баграж буйларында болыннарда
Печәннәрен чаптым каерылып.
Печәннәрем кипте, үзем киттем,
Туган-үскән җирдән аерылып.

Баграж суларының буйларында
Бөтнекләрен җыйдым бер бәйләм.
Сез туганнар белән бер күрешү,
Бер сөйләшү — үзе бер бәйрәм.

Баграж суларының тар җиренә
Каеннардан басма салганнар.
Каеннары юан, сулар тирән,
Гомер генә кыска, туганнар.

Бер күрегез кайтып су буйларын,
Баграж якларына юл такыр.
Сагышыгыз булса — арындырыр,
Кайгылардан сезне юатыр.

*Никофор Тукмачев*

Чистай шәһәрендә һәм Чистай шәһәре тирәсендәге — Алексеевск районында, Лениногорск районында һәм шәһәрендә, Самара өлкәсендәге авылларда яшәүче керәшеннәр.

### Әйдә, әйдә

Чакырым саен телеграф,
Чакырым саен багана.
Безнең үскән чорыбызга
Килде рәхәт замана.

Кушымта:

Әйдә, әйдә, кайда, кайда?
Әйдә барыйк урманга.
Урман буйлары абага,
Урман суы шәп ага,
Урман суы шәп ага.
Авылыбызда бер матур бар —
Әйдә салыйк шобага.
Алма, дисәм, алма түгел,
Кыяр, дисәм түгәрәк.
Көн дә бергә булыр идек,
Әгәр булсак күбәләк.

Кушымта.

Уйсу җиргә утыргансыз,
Күренмидер утыгыз.
Сезнең белән бергә булган
Кадерле минутыбыз.

Кушымта.

Тау ягы районнарында — Апас һәм Кайбыч районнарында яшәүче керәшеннәр.
Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк һәм Чибәркүл районнарында яшәүче керәшеннәр.

### Чибәр кызга

Карлыгандай кара, ай, күзләрең,
Бөрлегәндәй йөзләрең.
Шикәрләрдән тәмле, ай, балдан татлы
Сөям дигән сүзләрең.

Кушымта:

Алма бакчасының җулы
Тәрәзәләргә туры.
Әллә сиңа бирелгәнме
Бөтен дөньяның нуры?!
Кашың кара, буең зифа,
Күзең дә кара синең.
Кара күзеңә карасам,
Җөрәгем җана минем.

Бишмәтеңдә синең, ай, биш төймә,
Нигә төймәләмисең?
Аралар да безнең, ай, җырак түгел,
Нигә килгәләмисең?

Кушымта.

## Кәтүк түти

Кәтүк түти иртүк торып
Суга киткән.
Кайтып җиткәч
Җыгылган да суын түккән.

Кушымта:

Кәтүк түти, ник җылыйсың,
Авызың җәеп,
Синдә түгел, кызларда да
Була гаеп.

— Кәтүк түти, тәҗел-тәҗел
Кая бардың?
— Марҗый тутаң туйга киткән,
Сыерын саудым.

Кушымта.

Кәтүк түти судан кайтып
Пичкә җаккан.
Утыны чи булганмы,
Җанмый җаткан.

Кушымта.

Кәтүк түти җөри торгач,
Алҗып беткән.
Әл алырга утырган да,
Җоклап киткән.

Кушымта.

## Ул — чәчәкле капкадан

Григорий Родионов (хәзер ул Гәрәй Рәхим) белән беренче тапкыр Лениногорск шәһәрендә уздырылган семинарда очраштык. Башта, билгеле, шигырьләре белән, аннан үзе белән. Хәсән Туфан, гадәттә, үзенә ошамаган шигырьләрне кешегә күрсәтеп тормый, ошаганнарын, җир астыннан нефтьле керн алган шикелле, аерым кызыксыну белән җентекләп карый, аннан күршесенә төртә, мә, кара, кызык.

Григорий Родионов... Исеме дә, шигырьләре дә безнең өчен яңа иде. Исеме хәтта бераз чит тә иде. Татар поэзиясенә килгән берничә яшь буынны беләм, ләкин арада Родионовлар юк иде. Яңа исем, яңа шигырьләр. Дөресен әйтәм, минем өчен әдәбиятта шатлыклы нәрсә кабатланмаган яңа әсәрне уку, яңа исемне табу булды. Яшем җитмешкә чykkaннан соң, бу кызыксыну миндә тагын да артты. Моннан соң тагын нииндирәк кешеләр килер икән? Кабатланмауның чиге бармы? Юктыр. Чөнки тормыш үзе кабатланмый.

Гәрәй Рәхим... Без аңа шунда, атаклы Ромашкино хәзинәсе ачылган төштә, беренче скважина эшен башлаган урыннарда, борынгы шагыйрь Кол Галинең 1212 нче елда ук татар телендә язылган поэмасы «Йосыф китабы»ның өченче нөсхәсе табылган изге урыннарда хәерле юл теләдек. Гәрәй Рәхим үзе безнең өчен беренче нөсхә иде...

Гәрәй Рәхим Татарстанның Лениногорск районы Федотовка авылында 1941 нче елны, әтисе сугышка китеп, ике көн узгач туган. Бу биографиясе аның 1970 нче елда «Советская литература» журналында инглиз, немец, поляк телләрендә басылган «Әниләр зары» исемле шигырендә чагылган. Аналар, самавыр куеп, сугыштан ирләрен көтә. Алар самавыр кайнап чыкканчы кайтып җитәрләр шикелле. Аналар, самавыр куеп, космонавт улларының галәмнән кайтып төшүләрен көтә. Алар, самавыр өлгергәндә, һичшиксез, кайтып керерләр шикелле... Көнкүрешнең гади бер детале аша Бөек Ватан сугышы трагедиясе һәм бүгенге көннең яңа биеклеге бирелә, сюжеты гади, формасы традицион...

Керәшеннәрнең моңнары башка, моңнары аерылып тора. Басынкы, сагышлы. Гореф-гадәтләре башка, бәйрәмнәре үзенчә. Элеккерәк елларда бу якларда яшь киленнәрне котлау бәйрәмнәре үткәрелә торган булган. Яз җитә, каеннар яфрак яра. Авыл халкы каен урманына агыла. Ике яшь каенны кисеп, очын очка бәйлиләр, яулыклар эләләр. Урам буйлап җырлар җырлап үтәләр. Кешеләр һаман иярә, кешеләр су буена төшә, яулыкларны суга манчып алалар да киленнәргә бирәләр.
Ә каеннар, яшь каеннар суда агып китә. Күзәтәләр: каеннар кайда да булса эләксә, димәк, бәхетсезлек көтә... Эләкмәсеннәр иде, елга буйлап аксыннар да аксыннар.

«Чәчәк бәйрәме» дә — борынгы, күптәнге бәйрәм. Халык аны июнь башларында бәйрәм иткән. Таң беленгәнче үк халык урманга сибелгән. Таң ату белән, бөтен төштә чәчәк: капкада, коймада, тәрәзә рамнарында... Яхшы кешегә — чәчәк, матур чәчәк; начар кешегә — кычыткан... Гәрәй Рәхимнәрнең — Родионовларның — капкасына мин чәчәкләрнең әйбәтләре эләккәндер дип уйлыйм. Яшь шагыйрь шул капкадан — чәчәкле капкадан чыккан.

Традиция... Шагыйрьгә бай традиция, матди һәм рухи бай җир кирәк. Ул поэзиягә тыныч килеп керде. Шул тынычлыкта ышаныч. Тормыштан туган нык форма. Шагыйрь фәкать тормыш турында сөйләргә килгән. Аны шул кызыксындыра. Шул юллар артында мин баягы яшь каеннар — яшь киленнәрне, койма ярыкларына чәчәк кыстырып йөрүче керәшен кызларын, егетләрен күрәм, аларның шаян җырларын, такмакларын ишетәм, йөзләрен күрәм, кыскасы, халыкны таный башлыйм.

*Сибгат Хәким*

## Чор белән бергә

Шагыйрь үзенең китабын кыю рәвештә «Моңнарым» дип атаган. Моң — шагыйрьнең кыйбласы, иманы, туган җире, теле, күңел күзәнәкләрендә туган уй-фикерләре, мәхәббәте, нәфрәте, кыскасы, моң — шагыйрьнең үзе!..

Үзеңә генә хас моңны табу җиңел түгел, әмма ул моңны түкми-чәчми чордашларыңа җиткерү, аны халкың белән уртак итү — тагын да авыррак.

Башта ук шулай булды: аның исеме күзгә бәрелеп тормады, шигырьләре тәнкыйтьчеләр телендә кирәккә-кирәкмәскә әрсезләнеп чыңламады. Шагыйрьнең моң чишмәсе
тып-тын гына агып чыкты да тора-бара саф сулы чишмәгә әверелде, мул сулы, ярсу дулкыннарын уйнаткан елгага әйләнде...

Туган җир... Гәрәй Рәхимнең байтак шигырьләре туган җиргә багышланган. Шагыйрь ул җирдә җил-кенеп яши, төзи, яна, сөя, кирәк чагында, яшертен генә елый да белә, ирләрчә моңсулана, мәхәббәтен таба. Ул җирдә аның ата-бабалары яшәгән. Бу җирдә аның дәвамы — балалары яшәячәк. Шагыйрь буыннарның

ныклыгын, аерылмаслыгын кат-кат искәртә, бу теманы заманыбызның иң мөһим мәсьәләсе итеп саный. Аның «бабасы буразнага ятып җан биргән», атасы, фашистларга каршы сугышып, «танк астына кергән».

Чор алдында җаваплылык хисе тою — шагыйрьнең мөһим фикерләреннән берсе. Автор бу турыда әледән-әле безгә дә, үзенә дә искәртеп куя һәм, тапкыр рәвештә, «ә бүгенгә — аз да, күп тә түгел — без җаваплы бугай дөньяга!» дип җырлый. Менә шушы зур җаваплылык хисе аның беренче карашка гади генә күренгән лирик геройларының адымын эреләтә, колачын киңәйтә, аның кешеләре гади булудан туктап, планетаның, илнең, елга-суларның хуҗаларына, җаваплы кешеләренә әйләнә.

Шагыйрь авылын, «камылаякларга баскан башаклар»ны, Сандыр дәдәйләрне, имәннәрне, Иделен, Болгарын күңелләргә үтеп керерлек итеп җырлый.

Гәрәй Рәхимнең бөек рус шагыйре Сергей Есенинга багышланган шигъри юлларында да сафлык, олылау хисләре бөркелеп тора.

Син булмасаң, колачыма кырлар, Кояш сыймас иде.
Ә алардан башка минем җырлар Җырлар булмас иде! —

ди шагыйрь үз остазына мөрәҗәгать итеп. Остаз — теге яки бу шагыйрьнең гашыйкларча яраткан заты гына түгел, ул — юлыңның дөреслеген тикшергәндә маяк та, арганда таянып ял итә торган талың да, өметсезлеккә бирелгән чакларда күңелеңне яктыртучы нур көлтәсе дә... «Мин еллардан гомер дигән бер челтәр үреп барам, матур һәм ямьсез үрелгән төшләрен күреп барам» дигән юлларны язганда, шагыйрь, әлбәттә, остазларына үрелеп карамый калмагандыр!

«Юк! Шигырьдә йокы симертергә рөхсәт итми безгә бу замана»,— дип башланган шигырь — Гәрәй Рәхимнең иң җитди шигырьләреннән берсе.

Мәхәббәтне инде Мәҗнүн кебек
Эзләмибез таулар арасыннан.
Без эзлибез аны җен шикелле
Машиналар, шаулар арасыннан.

Әйе, заман тиз үзгәрә, кайчагында үзгәрешләрне тоеп-сизеп калу да кыен, әмма кеше һәрчак, һәркайда да Җир баласы булып калырга тиеш. Чөнки аның мәңгелеге һаман үзгәрешсез кала — җире-суы, туган җире, ана теле. Гәрәй Рәхим үзе турында хаклы рәвештә болай әйтә ала:

Бу нинди бетмәс мәхәббәт
Минем күңелдә генә?!
Сүз башласам, телләремнән
Җыр булып, моң түгелә!

*Аяз Гыйләҗев*

## Буыннар елъязмасы

*1939 нчы ел*

Алар — кырык бер егет,
Җырлап яши.
Бәхетләрен бер-берсенә
Чорнап яши.

*1941 нче ел*

Алар — кырык ир инде
һәм бер егет.
Онытылмас дәһшәт белән
Бер көн килеп,
Кырык хатын карап калды
Кырык иргә.
Кырык малай туып калдык

Кырык бердә.

*1944 нче ел*

Ерак кырда кырык ир иде
Һәм бер егет.
Барысы да ил өчен
Калды үлеп.

*1958 нче ел*

Бер авылда кырык егет
Җырлап үстек.
Беребезнең җитмәвенә
Сыкрап үстек.
Бәхетләрне бер-беребезгә
Чорнап үстек.

*1961 нче ел*

Кырык берәү кырык өчен
Үлгән җиңеп.
Утыз тугыз ир инде без
Һәм бер егет.

*1964 нче ел*

Утыз тугыз малай туды
Бүген генә.
Утыз тугыз малай карый
Безнең күзгә:
— Тагын шулай дәһшәт белән
Бер көн килеп,
Сез, әтиләр, калмассызмы
Кырда үлеп?
Утыз тугыз малай карый
Гел чәчәккә.
Алар кырык булсын өчен
Киләчәктә,
Узган буын нәфрәтләрен
Бергә җигеп,
Дәһшәт көнен булдырмаска
Мең мәртәбә бурычлы без —
Кырык егет.

## Неон яктысында уйлану

Иң соңыннан кем калыр бу җирдә?..
Берәү?.. Икәү?.. Меңнәр?..
Миллионнар?..
Иң соңгысы булып Син калырсың
Һәм нәкъ сиңа тиңнәр —
миллионнар!

Син калырсың, чөнки синдә генә
Камиллеге бөтен дөньяның.
Дүрт гүзәлен биргән сиңа Галәм —
Чыгыш, Батыш, Төн һәм Көн ягын.

Һәм тагын да биргән дүрт гүзәлен —
Җирен, Күген, Утын һәм Суын.
Йорт төзергә ташлар биргән тагын,
Иген чәчә торган басуын.

Ә бомбаны бирмәгәндер сиңа,
Бу тик ялгышыдыр дөньяның.
Куян ясыйм диеп, бомба чыкса?!
Зыяны юк, янә, куянның?..

Сизеп торам, куян дигәч, синдә
Потенциаль аучы уяна.
Нәсле корсын, халыкара бер ау
Игълан итик бомба — куянга.

Чын куяннар калсын,
калсын ташлар,
Чыгыш, батыш, төн һәм көн ягы.
Җиреңң, күгең, утың,
суың калсын,
Бизәп торсын алар дөньяны.

Күр, урамда неон яктылары,
Ал нурында коена ак каен.
Юк, кайгырма,
шулар белән Җирдә
Син калырсың, Кеше дускаем!

### Туган як имәннәренә

Ә алар бит һаман мине көткән,
Иңнәренә көзне ябынып.
Сагынуларын сары яфрак иткән
Имәннәргә йөрим табынып.

Берәм-берәм башым иеп узам:
— Исән-саумы, әй имән агай?
Таныйсызмы, мин бит сезнең белән
Бергә балигъ булган җор малай.

Сезнең хәлне белер өчен монда
Минем яшьтәшләрем кайтамы?
Тазамы сез, әле тамырларда
Тагын йөз яшәрлек хут бармы?

Һаман әле безнең керәшеннәр
Балта тотып килгәч бирегә:
«Ай-һай шәп үсәләр, кызганыч», — дип,
Кисми китәләрме кирегә?

Ә көегез һаман шул ук икән —
Гүелдисез горур, ирләрчә.
Кайсы гасырларга барасыз сез
«Кара урман» дигән көйләрдә?!

Мин бит сезне бик сагынып

кайттым,
Мин ич шушы җирнең баласы.
Имәннәрем, сезнең яшәештән
Килә минем өлге аласым.

## Болыннарны атлар табырлаган

Болыннарны атлар табырлаган,
Бер җыр ишетелә табуннардан:
— Дөрләп яна каен тузлары,
Бездән әле яшьлек узмады.

Чал башымны иеп басып торам,
Ләкин йөрәк һаман ярсып тора.
Җырлый йөрәк...
...Каен тузлары,
Юк, узмады әле, узмады.
Йөрәк кагып ярсу атлар килә,
Яшь егетнең җыры ишетелә:
— Тегә белсәң, ияр тузмый ул;
Картаймасаң, яшьлек узмый ул.

Чал башымны төрәм шомыртларга,
Чәчләремне егет күрмәсен,
Картлык ни икәнен белмәсен.

Болыннарны атлар табырлаган,
Бер җыр ишетелә табуннардан:
— Нык тегелгән ияр тузмый ул,
Чәч агара, яшьлек узмый ул.

*Гәрәй Рәхим*

## Им-томнар, ырымнар

Керәшеннәрдә тормышның төрле өлкәләрендә күзәтелә торган үзенчәлекле гореф-гадәтләр, ырымнар, им-томнар, борынгы мәҗүсилек чорыннан ук килә торган һәртөрле ышанулар күп булган. Аларның кайберләре әле бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән, тик алар хәзер күбесенчә өлкән буын кешеләрендә генә сакланып калган.

Керәшеннәрдә кеше чирләгәндә яки табигый бәла-казаларга дучар булганда кешегә ярдәм итә торган **«тел белүчеләр»** булган. Алар төрле серле сүзләр әйтеп «дәвалаганнар». Тик ул сүзләр бик зур сер булып исәпләнгән, аны «тел белүче» кеше үзе һәм аның семьясындагы иң ышанычлы кеше генә белгән. Ул сүзләрне имче карчык үзе уйлап чыгарган яки өлкән буыннан кече буынга күчә килгән. «Дәвалаучы» кеше күп очракта серле сүзләрне пышылдап кына бик кызу әйткән, алар кешегә аңлашылып та бетмәскә мөмкин.

Халыкның борынгы күзаллавын, фикерләвен чагылдырган бу ырымнар аерым такмазалар формасында булып фольклорның бер жанрын тудырганнар. Шигырь формасындагы бу тезмә юлларга образлы сүзләр хас. Күрәзәче яки им-томчы еллар буе шомартылган образлы сүзләрне тавышын бер күтәреп, бер түбәнәйтеп, бер ягымлы, бер куркытулы тавыш белән берничә тапкыр кабатлый. Текстларда төрле сәнгать чаралары: метафора, гипербола, аллегория, төрле рифма һәм ритм кулланыла. Им-томчы карчыкның такмакларында төрлечә боеру һәм куркыту ноталары чагыла.

*Флера Баязитова*

## Бакалы керәшеннәре

Элгәрерәк керәшеннәрнең күршебез Башкортстанның Бакалы районында да яшәүләре хакында ишеткәнем булса да, моңарчы әле ул якларга бер дә барып чыкканым юк иде. Сокланып туймаслык матур икән Башкортстанда яшәүче карендәшләребезнең торган-яшәгән яклары. Биредәге табигатьне бары тик оҗмах бакчаларына гына тиңләрлек. Ул кара урманнары дисеңме, җырларда җырланган Сөн, Ык елгалары буендагы болынлыклары, әрәмәлекләре, ул зәңгәр күлләр, урман полосалары белән әйләндереп-каймаландырып алган басу-кырлары — барысы да сине җаныңа тылсымлы илаһилык бөркеп каршылый. Беразга гына булса да рухыңны, күңелеңне дөнья авырлыкларыннан, ыгы-зыгыдан арындырып сихәтләндерә, дәвалый. Әйе, биредә, шагыйрь әйтмешли, әле дә «ак күмәч белән ашарлык саф һава», «урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк...» Шулай ук биредә киек-җәнлекнең дә исәбе-хисабы юк, диделәр. Чөнки биредә табигать бездәге, Кама буе регионындагы кебек, агулап интектерелмәгән, гарипләндерелмәгән — имгәтелмәгән.

Һәм табигатьнең оҗмах бакчасыдай шушындый игелекле почмагында аның бар изге сыйфатларын үзенә җыйган эчкерсез, самими, юмарт, кунакчыл һәм эшкә уңган карендәшләребез — асыл зат керәшеннәр яши. Районда аларның саны тугыз меңгә якын икән.

Биредә 22 керәшен авылы бар. Керәшен яшәгән төбәктә җир дә, табигать тә игелеклерәк, юмартрак була. Чөнки алар бер-берсе белән бер җан, бер тән булып берләшкән, бер-берсенә береккән, аларның рухы уртак, җаны уртак. Керәшен табигатьтәге һәрбер җан иясе белән уртак тел таба, аның белән ихлас элемтәгә керә ала. Ул һәрбер үләннең, бөҗәкнең, киек-җәнлекнең телен белә, аның көен көйли, әнә шуңа күрә алар булып бер уйда, бер теләктә, үзара тыгыз мөнәсәбәттә бербөтен яшиләр.

Әнә шуңа күрә биредәге һәрбер колхоз-совхозда бишәр-алтышар умарталык бар. Бал кортлары телен белә керәшен. Шулардан инде бөтен дөньяга атаклы башкорт балы алына. Керәшеннең борынгыдан килгән иң асыл һөнәрләреннән берсе — умартачылык шул. Чөнки ул хезмәте белән үзе дә бал кортына тәңгәл. Районның дистәгә якын хуҗалыгында бия асрыйлар, аларны савып, шифалы кымыз ясыйлар. Эшкә мөнәсәбәте белән керәшен шулай ук атка синоним була ала. Биредә шулай ук басуы-басуы белән җиләк-җимеш бакчалары. Бакалы совхозында гына да, мәсәлән, 1200 гектар алма бакчасы, диделәр. Алмаларының күплегеннән җиргә сыгылган агачларны күреп, күңелләргә эшчән карендәшләребез өчен куаныч-шатлыктан күкрәкләргә саф, чиста һава белән бергә горурлык хисе дә ургылып керә.

Ни өчен керәшенне генә мактыйсың, анда башка милләт вәкилләре дә бардыр бит, диярләр. Әйе, бик дөрес. Анда мөселман татары да, русы да, башкорты һәм башкасы да бар. Әмма борын-борыннан, кем чанасына утырсаң — шуның җырын җырларсың, дигәннәр.

Әнә шуңа күрә, ягъни асыл күршеләре керәшеннәрнең асыл гадәтләре аларга да йоккан. Тикмәгә генә керәшеннәр гомер-гомергә:

Без әүвәл дә асыл нәсел идек,
Тагы да асылларга катнаштык,—

дип җырламый шул.

Әйе, эчкерсез, эшкә карышусыз, самими һәм кунакчыл керәшен янында теләсә нинди милләтеңнең дә эшсөяргә әйләнми хәле юк. Эшчән керәшен үзенең серле тылсымы белән теләсә кемнең дә күңелендә эшкә-хезмәткә мәхәббәт ялкыны, дәрт, дәрман уятачак.

Ә ул үзе исә мондый тылсым-кодрәтне ихлас табигатьтән, югары, өстен көчләрдән ала. Табигатьне биредә үтә саф, имин рухлы, дидек. Чөнки ул бездәге кебек химия агуыннан бозылмаган.

Рәсми чыганаклардан күренгәнчә, Бакалының, авыл буларак, XVII гасырда формалашуы билгеле. Ә XVII йөзнең икенче яртысында ул казакълар яшәгән крепостька әйләндерелә һәм Пугачев җитәкчелегендәге крестьян күтәрелешенең үзәк районнарының берсе була. «Башкортстан географиясе» дигән китапта (1926 нчы елда басылган) ул Бәләбәй кантонының көнбатыш өлешендәге иң эре сәүдә, промышленность пункты дип бәяләнә.

Фәнни әдәбиятта, архив документларында һәм Уфа губернасына караган язмаларда бу территориядә яшәүче керәшеннәрне XVI—XVII гасырларда Казан ханлыгының үзәк районнарыннан күчеп утырганнар дип күрсәтәләр.

Бер төркем керәшен авыллары элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Бакалы һәм Нагайбәк волостьларында (хәзерге Бакалы районында) урнашкан. Бакалы керәшеннәренең тарихы шулай ук бик күптәннән килә. 1736 нчы елда төзелгән Нагайбәк крепосте ул чор өчен әһәмиятле хәрби объект булган. Сәяхәтче-галим П.И.Рычковның язмаларына караганда, крепость урынында элек Нагайбәк исемле башкорт яшәгән һәм авыл да аның исеме белән аталган, имеш. Әмма биредә керәшен авыллары XVI гасырда ук булган дип, ә аларда яшәүчеләр үзләрен кайчандыр Арча тирәсендә яшәп, соңыннан Нагайбәк крепостена караган җирләргә күчереп утырылган, дип исәплиләр.

Бу тирәдә яшәгән керәшеннәр 1748 нче елдан, казакъ сословиесенә кертелеп, алардан махсус казакъ полклары оештырылган. Нагайбәк округында барлыгы 11 авыл булган һәм анда 1359 казакъ исәпләнгән. Казакъларның саны шушы тирәдәге авылларда яшәгән яңа керәшеннәр исәбенә дә арткан. Бу авылларда яшәүчеләрне соңыннан нагайбәкләр дип атап йөртә башлаганнар.

Нагайбәкләр 1842 нче елга кадәр Бакалы авылы һәм крепость тирәсендә дә яшәгән. Әмма 1842 нче елда Казакъ кон-
тоны бетерелгәч, Бакалы һәм Нагайбәк станицаларына караган авыллардан казакъ гаиләләре Оренбург губернасының Верхне-Уральск өязенә көчләп күчереп утыртылган. Шулай итеп, Ык-Сөн елгалары бассейнындагы нагайбәкләр тулысы белән Көньяк Уралга күчерелә, һәм алардан бушаган авыл-
лар, җирләр Казан губернасыннан күчеп килүче керәшеннәргә бирелә.

Бакалы районы территориясендә район үзәгеннән тыш Акман, Батрак, Баҗыр, Ворсинка, Верхнетроицк, Дубровка, Егорьевка, Корчай, Красная Горка, Кәчти (Крип), Яңа Балыклы, Яңа Илек, Иске Әҗми, Петровка, Пушкин, Яңа Сарашлы, Иске Сарашлы, Сазоновка, Салкын Чишмә, Яңа Маты (Әрнеш), Иске Маты, Утар, Үмер дигән авылларда керәшеннәр яши. Аларның саны 6,5 меңнән артык.

Шунысын да әйтми булмый. Бакалы районында, башка төбәкләрдән аермалы буларак, урманнар, яшеллекләр бик күп. Биредә колхоз-совхоз җирләре дә шактый калын урман полосалары белән шакмаклап әйләндереп алынган. Бусы инде биредәге кешеләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсе: полосаларны алар утырткан.

Басуларга чыксаң, әнә нинди хозурлык ич. Күз күреме җирдә әйләнә-тирәдә урманнар, алар арасындагы басу-кырлар да урман полосалары белән тип-тигез шакмакларга бүлгәләнгән. Кош очар биеклектән караганда, ул тагын да гүзәлрәктер әле. Менә мондый тәртипле, чиста һәм саф төбәкне туган илем — Ватаным дию дә үзенә бер төрле горурлык һәм куаныч бит!

*Ямаш Игәнәй*

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

***Кышкы Микулы (19 нчы декабрь).*** *Аны салкын Микулы диләр.*

*Кышкы Микулы нинди булса, җәйге Микулы да шундый була.*

*Микулыдан каты салкыннар башлана.*

*Микулыда буран булса, кыш буе буран була.*

*Микулыга каршы бәс булса, солы яхшы уңа. Микулыда бәс булса, барлык игеннәр дә яхшы үсә.*

*Микулыда крестьян үзеннән артык икмәкне сата башлаган.*

*Кышкы Микулы — өлкәннәр бәйрәме. Бу көнгә яңа уңыштан мул итеп сыра әзерләнә. Туганнар бер-берләренә кунакка йөрешә. Сыра белән күңел ачу 3—4 көн дәвам итә. Бәйрәмдә катнашучылар уртак «казнага» акча яки әйбер салыша. Авылда бу чарадан читләшкән кешедән, саранлыкта гаепләп, ел буена көлә торган булганнар.*

*Кышкы Микулыдан кыз сорап яучы җибәрүләр башлана.*

## Балдак салу

Керәшеннәрдә яңа стиль белән 19 нчы декабрьдә Кышкы Микулы бәйрәме була, моңа каршы төндә, ягъни унсигезенче декабрьдә һәм Яңа елга каршы 31 нче декабрьдә, яңа стиль белән унөченче январьда балдак салулар була. Мондый йолаларга алдан ук әзерлек алып барыла башлый, сөйләшенеп куела, кемнәр киләчәге билгеле була.

Ул көнне хатын-кызлар алдан билгеләнеп куелган, аулаграк һәм иркенрәк бер өйгә җыелалар, тышкы яктан чит кешеләр күзәтеп тормасын, тыныч булсын өчен, тәрәзәләрне эчтән каплап куялар, аннан үз араларыннан берсе беренче бала булып туган, икенчесе төпчек булган ике кешене сайлап алып, кулларына чиләк тоттырып, бәкедән су алып кайтырга җибәрәләр. Ул кешеләргә юлда бер-берсе белән һәм очраган кешеләр белән сөйләшмәскә кушыла.

Акча салып, иман әйтеп, суны алып кайткач, балдак салуга катнашучылар эскәмия, сәке кырыйларына, өстәл янына тезелешеп утыра. Аларның һәрберсе, үзенең балдагы ешрак эләгеп чыксын өчен, аңа җәп белән я булавка, я божра, яисә тагын берәр балдак тага.

Менә берсе балдаклар салынган, өсте сөлге белән ябылган чиләктәге суны кулын тыгып болгата башлый. Бармагына балдак эләгү белән: «Балдак миндә, җыру кемдә?» — дип эндәшә.

Балдак салучыларның һәркайсы җыр әйтергә хаклы, һәркем эчтәлеклерәк, мәгънәлерәк, киләчәк язмышлар турында уйланырлык җырлар әйтергә тырыша, шаян җырларны да әйтергә онытмыйлар.

Чиләккә балдак салган хатын-кызлар киләсе елга кадәр йорт-җирнең иминлегенә, мал-туарның исәнлегенә, яшьрәк кызлар, киләчәк язмышларын исәпкә алып, салынган йөзекләренә юрап бирергә җырлар көтә.

Шулай итеп, һәркем, киләсе елга кадәр күңеленнән нәрсәгә булса да юрап, балдак салган. Балдак салучыларга такмаклар, уен җырлары да әйтелә.

*Александр Филиппов*

## Көмеш тояк тулпар атым

*Марс Макаров* көе
Халык сүзләре

Туп-туп кына басып килә
Көмеш тояк тулпар атым, һай!
Канатланып үзем киләм,
Җитмәс, диеп, язган хатым.

Атым килә туп-туп атлап,
Ташлы юлларны таптап, һай!
Сагынганда карар идем,
Карурман тора каплап.

Бергә чаклар искә төшә,
Казан, диеп бер җырласам, һай!
Кемне сагынып җырлар идем,
Казаннарда син булмасаң.

Туп-туп кына басып килә
Көмеш тояк тулпар атым, һай!
Канатланып үзем киләм,
Җитмәс, диеп, язган хатым.

***Декабрь-январь***

Халык календаренда декабрь аеның аеруча салкын, кыш тәмам урнашып җитә торган ае итеп саналган. «Микулы җитми кыш булмый» кебек сынамышлар да декабрьне шушы ук рухта сурәтли. (Кышкы Микулы көне искечә 6 нчы декабрьгә туры килә.)

Элекке вакытларда халык синоптиклары кыш айларындагы һава хәлләрен аеруча кызыксыну белән күзәтеп барган. Бу аңлашыла да. «Кышкы көннәр җәйне әйтер, җәйге көннәр җайны әйтер»,— диләр бит. Җәйнең — жайның ничегрәк булырын чамалауда декабрьнең кайбер көннәре шулай ук әһәмиятле аграр даталар рәтеннән исәпләнгән. Мәсәлән:

Егерме бишенче декабрьдә агачларны бәс тотса, алдагы елда иген уңар.

Егерме бишенче декабрьгә каршы төнне йолдызлар күп күренсә, чәчәкле ашлыклар бик уңар.

Декабрьнең егерме бишендә таң вакытында тын булып йомшак кына кар яуса, ашлык яхшы булыр.

Әгәр кар көндез яуса, чикләвек яхшы булыр. Бу көнне җылы һәм буран булса, җәй салкын килер.

Декабрьнең егерме бишендә, егерме алтысында, егерме жидесендә тамчы булса, июньнең егерме тугызында кырау булыр; кыяр уңмас, карабодайга килешер.

Утыз беренче декабрьдә бәс булса, ашлык уңар һ. б.

Декабрь аена караган сынамышлар һәм йола-ритуалларның күбесе 21—22 нче декабрьдә күзәтелә торган кышкы кояш торгынлыгы белән бәйләнгән.

Кышкы кояш торгынлыгын борынгы халыклар кояшның «үлеп кабат терелүе» яки «яңадан тууы» рәвешендә күзаллаганнар һәм аны ел саен бик зурлап, тантаналы төстә билгеләп узганнар. Мондый календарь бәйрәм «нардуган» дип йөртелгән. Аның атамасын монголча «нар» (кояш) һәм татарча «туу»

сүзләреннән ясалган дип аңлату бар. Әгәр бу шулай икән, нардуган, димәк, «кояш туган» дигән сүз булып чыга.

Нардуган үзенең асылы белән аграр йола, ягъни ул игеннәрдән мул уңыш алу хакына, шундый өмет белән уздырылган. «Нардуганга бармасаң, җитен булмый» кебек ышанулар яисә нардуган көйләрендә ашлыкка дип атап куркулык коюлар әнә шуңа дәлил булып тора. Әлбәттә, заманнар узган саен, нардуган, башка йолалар белән катнашып, алардан күп кенә яңа ритуаллар үзләштергән. Атап әйткәндә, Раштуа, Святки бәйрәмнәренең йогынтысы зур булганлыгы күренә.

Нардуганчылар, өйдән өйгә йөреп, җыр һәм такмаклар әйткән, йорт хуҗаларына Яңа елда муллык, иминлек, бәхет теләгән:

Нардуган, нардуган,
Нардуган, хуҗалар,
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын,
Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез уңсын,
Йомыркадай тук булсын,
Нардуган, нардуган!

Табигый ки, Яңа ел алдыннан һәркем үзенең киләчәк бәхете, язмышы турында күбрәк уйланучан була. Ихтимал, шуңа күрәдер, нардуган кичәләренең репертуарында фал ачу уеннары зур урын алып торган. Аулак өйләрдә кызлар бигрәк тә йөзек салыш уйнарга яраткан. Башта, уенда катнашучыларның йөзекләрен җыеп, аларны су тутырылган тирән савытка салганнар. Савытның өсте ябып куелган. Шуларны эшләгәннән соң, бер куплет җыр башкарылган. Аннан уен башы савыттагы йөзекләрне бутаган да, карамыйча гына, берсен тартып чыгарган һәм, баягы җырның эчтәлегенә карап, йөзек иясенең алдагы тормышын юрау башланган. «Нардуганым нарына, бакма кеше ярына», «Нардуганым нар төсле, матур ярлар бар төсле» кебек җыр өзекләреннән дә аңлашылганча, яше җиткән кызларны күбрәк «Быел кияүгә чыгаммы?», «Нинди кешегә тап булам?» кебек сораулар кызыксындырган. Йөзек салып, җыр белән юраудан тыш, күрәзәлек итүнең башка ысуллары да булган. Әйтик, төн уртасында абзарга кереп караңгыда бер сарыкны тоту — карт сарык эләксә, карт кешегә; яше эләксә, яшь кешегә тормышка чыгасың, имеш. Яки капка аркылы киез итек ыргыту — итек башы кая карап ятса, шул якка кияүгә китәсең, ди һ. б. Әгәр фал ачу нәтиҗәсе көтелгәнчә булмаса, моңа да артык борчылмаганнар, җырда әйтелгәнчә, өметне алга, киләчәккә күчергәннәр:

Нардуганның нары бар,
Кешеләрнең яры бар.
Ходай безне ялгыз итмәс,
Нардуганнар тагы бар.

*Александр Филиппов*

## Ир уртасы булдым

Сирәк кайтасың, дип орышасың
Сүзләр белән түгел, күзләр белән.

Хисләреңне, әнкәй, аңлыйм инде —
Ир уртасы булдым… Булып киләм.

Үземнең дә кызлар үсеп килә —
Синең хәлдә калам үзем дә.

Көтеп яшә мине. Кайтыр, диген,
Өмет уты янсын күзеңдә.

Кайтыр юлга чыктым. Кайтып киләм
Үзем генә түгел, кызлар белән.

Сирәк кайтасың, дип орыш мине
Сүзләр белән түгел, күзләр белән.

Сүзләр белән орышма син мине,
Син кичергән хисне кичерәм:

Синең кебек балаларны көтәм…
Ир уртасы булдым. Булып киләм.

### Кайт әйләнеп

Мин бит сине сагынып яшим әле,
Көтеп яшим әле бүген дә.
Иңнәреңдә иңнәремне тоеп,
Ярың гына түгел, парың булып,
Урамнарда телим йөрергә.

Мин бит сине урамнардан эзлим,
Сукмаклардан эзлим эзеңне.
Вак ялгышлар өчен үпкәләшеп,
Эчтән янып, тыштан горур булып,
Сынашмасак иде түземне.

Мин бит сине онытмадым әле,
Онытып та булмас, күрәсең.
Минем кебек сагынып яшәр булсаң,
Көтеп яшәр булсаң үзең дә,
Кайт әйләнеп, миңа кирәк син.

*Николай Максимов*

### Раштуаның өч көне

Раштуа (Рождество) бәйрәмен христиан динен тотучы күп төрле агымнарның барысы да: православие, лютеран, англикан, баптист, католик, протестант, кальвинист һәм башкалар бик зурлап билгеләп үтә. Соңгы елларда ул, дин дәүләттән аерылган булып саналса да, Президент Указы нигезендә, дәүләт бәйрәмнәре рәтенә кертелде һәм һәр елның 7 нче январе бәйрәм көне дип игълан ителде.

Ул табигатьнең, Кояш торгынлыгыннан чыгып, елның җәйгә таба авышуына туры килә. Димәк, ул, мәҗүсилек чорыннан ук күчә-күчә, төрле төсмерләр белән баетылып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән йола бәйрәме булып санала.

Раштуа христианнарда, шул исәптән керәшеннәрдә дә, элек-электән үк бәйрәмнәрнең бәйрәме буларак зурлап үткәрелгән. Раштуа алдыннан кешеләр алты атна буе итле, сөтле, йомыркалы ризыклар ашаудан тыелып тора, ягъни ураза тота. Пост төгәлләнгәч, Раштуага каршы төн үзе бер бәйрәм. Керәшеннәр бу төнне «авыз ачу» диләр. Ә аның алдыннан иртәдән кичкә кадәр — күктә беренче йолдызлар кабынганчы — кеше бер тәгам ризык та капмый. Авыз ачу боткасын (сочельник) күктә беренче йолдыз кабынгач кына ашарга ярый.

### Раштуадан Кач ману көненә кадәр

***Раштуа*** көне тугач, өйгә итле ризык исе чыга башлый. Өстәлне бодай камырыннан пешерелгән сыер, сарык, кәҗә, этәч, тавык сурәтләре бизи. Менә шуннан инде, кунакка йөрешүләр, кич утырулар, аулак өй ясаулар, нардуганнар, йөзек салышлар һәм башка төрле уеннар, күңел ачулар башлана.

Раштуа — христиан дине тотучыларның зур бәйрәме. Ул чиркәү тарафыннан IV гасырдан бирле билгеләп үтелә.

Раштуа бәйрәме кешелек тарихында зур вакыйгалардан санала. Борынгы гадәт буенча, бәйрәм көннәрендә халык үзен бик инсафлы һәм тәртипле тоткан. Эчкечелеккә, йортларда һәм урамнарда тавыш-гаугага, тәртипсезлеккә юл куелмаган. Күпләр бу изге көннәрне тыныч кына, дин кануннарына тугрылыклы булып үткәргән, йорттан йортка йөреп, Христосны данлаганнар, Аңа карата мактау сүзләре әйткәннәр, күңелле ял иткәннәр.

*Күп еллык күзәтүләрдән чыгып, Раштуа көненә карата халыкта төрле сынамышлар йөри.*

*Менә аларның кайберләре:*

*Бу көнне кар яуса, иген уңышы мул була. Җил карны себертсә, байлык һәм муллык килә. Өй кыегында кар ятса, арыш һәм печән биек булып үсә.*

*Көн җылы булса, ашлык куерып үсә.*

*Буран булса, умарта оясы яхшы аера.*

*Раштуа яңа айга туры килсә, ашлык уңышы начар була.*

*Раштуада агачлар бәсләнсә — бөртекле ашлык, төн аяз булса — борчак, чана юлы шома булса — карабодай уңа.*

*Тәрәзәдәге арышка охшаган бизәкләр аска таба салынып торса, яхшы уңыш булачагына ишарә.*

Кач ману (водосвятие) ул мәҗүси халыкларның суга табыну чорыннан ук калган. Кач ману йоласын «чукындыру» дип түгел, ә суны изгеләндерү мәгънәсендә аңларга кирәк.

Су, гомумән, бик борынгы заманнардан ук иң изге әйберләрнең берсе, барлык җан ияләренә рух өрүче булып саналган. Иордан суында гөнаһлардан арындыруны Коткаручыдан 6 айга гына алдан туган Чукындыручы Яхъя 30 яшендә башлап җибәрә.  19 нчы январь, Кач ману көне буларак, шул вакыйгадан башлана. Шулай итеп, мәҗүсилек һәм билгеле бер шәхес аркылы Аллага табыну икесе бергә үрелеп барган. Яһүдләрдә изгеләндерелгән су хәтта холык-фигыльне дә чистарта, сафландыра дип уйлаганнар. Менә шуңа күрә дә кач манылган су Тереклек суы дип йөртелә һәм ул барлык авырулардан (эчке һәм тышкы чирдән, күз тиюдән, әйбер кагылудан һ. б.) имгә ярый диләр.

*Александр Филиппов*

## Икона турында

Бездә иконаны, дин әсбабы булудан бигрәк, өйнең аерылмас бер җиһазы, өйне бизәү әйберсе итеп тоталар. Керәшен кешесе өчен икона почмагын бизәү кул эше осталыгын күрсәтүче кечкенә генә бер күргәзмә кебек. Әйтик, ир кеше такталарга матур сырлар, бизәкләр уеп рам ясый. Хатын кеше исә ул рамга үзе чиккән пәрдәләр, үзе бәйләгән челтәрләр элә. Бу чиста, пөхтә, ап-ак итеп юылган челтәрләр, пәрдәләр, зур һәм матур итеп эшләнгән рамнар артындагы икона исә, күп йортта уч төбе хәтле генә бер рәсем инде. Ә менә икона почмагы үзенең чигүләре, челтәрләре, нәкышләре белән балкып, бөтен өйгә ямь биреп тора. Җитмәсә, бәйрәм көннәрендә аны төрле матур, ачык төсләргә манылган кәгазьләрдән кисеп ясалган чәчәкләр, букетлар белән бизәп тә җибәрәләр. Шунысы кызык: дини бәйрәмнәрдә генә түгел, совет бәйрәмнәрендә дә өйне бөтенләй юып, түшәмнәрне кырып, иконаларны бизәп куя авыл халкы.

Иконаның кирәклеге болай аңлатыла: өйнең кояш чыгышы ягындагы почмагын шыр ялангач итеп тоту бер дә килешә торган эш түгел. Җитмәсә әле, карчык-корчык, иконасыз өйне яшен суга, анда яшәүчеләрне мур кыра, анда төрле җен-пәриләр, убырлар ияләшә, иконасыз өйдән өй иясе чыгып кача, дип куркыталар. Ә бит өй иясе өйдәгеләрне чир-чордан саклый, өйнең иминлеге өй иясеннән тора.

*Григорий Родионов*

## Нәсел тамгаларыбызны онытмыйк

Керәшеннәрнең ничә мең еллар дәверендә җыелып килгән һәм ата-бабаларыбызга васыять итеп калдырылган, изге саналырга тиешле рухи һәм материаль мирасы бар. Ул мирас — үзенчәлекле йола-бәйрәмнәр, музыкаль һәм шигъри иҗат, милли киемнәр, риваятьләр, авыллар тарихы, төрле үнәр сәнгате һ. б. Киләчәгебез өчен аларны белү бик әһәмиятле. Соңгы дәвердәге бик буталчык заманалар узганын искә төшереп үтик. Ул дәвер буыннар арасындагы рухи кендек җепләрен өзеп бетерде диярлек, чөнки үсеп килгән балалар ата-бабасының, ана-әбисенең дөнья көтү рәвешен, телен, гореф-гадәтен, асыл тамырын тиешле сыйфатта белми калырга дучар булды. Үткән дәвер идеологлары, барлык милләтләрнең традицион мәдәниятен, сәнгатьләрен бетереп, сайланып алынган өлешен бергә кушып, яңа бер төр культура уйлап табабыз дип кешене алдап, үзенекеннән мәхрүм иттеләр, бутап бетерделәр. Нәтиҗәдә без тамырларыбызның искесен дә югалта төштек, яңасын да, билгеле инде, төзи алмадык. Димәк, әлеге ялган сәясәт үз максатына иреште дип әйтеп була. Чөнки тотрыклы үз милли аңы һәм ныклы традицияләре булмаган балаларыбыз башка милләтләр арасына кереп эреп бетү өчен хәзер барлык шартлар да бар инде.

Җир шарындагы барлык халыкларның да үз йөзләрен саклау гомумкешелек дәрәҗәсендәге мөһим эш булып санала. Халкыбызның милли-мәдәни экология мәсьәләләрен чишү җәмгыятебез, интеллигенциябез алдындагы зур бурыч булып тора. Идел-Урал буенда яшәгән халыкларның һәм этнографик төркемнәрнең

үз йөзләрен, милли хәзинәләрен саклау шушы ук мәсьәлә түгәрәгенә керә. Бүгенге көндә бу проблеманы алга этәрү буенча нинди перспективалар бар соң? Беренчедән, милли мирасыбызның кадерен, эчтәлеген аңлый белүче һәм күңел, йөрәк көче булган, фән хезмәтенә сәләтле энтузиаст кешеләр кирәк; икенчедән, бу мирасны фәнни яктан тиешенчә өйрәнеп, белеп, аларның хәзерге көнкүреш шартларында яшәешен дәвам итү өчен төрле чаралар күрә, югалтмаска өнди белә торган хакимият чиновниклары, мәдәният-сәнгать хезмәткәрләре, керәшеннәрнең язмышын, киләчәген үз иң өстенә ала белгән ил агалары кирәк. Безнең мондый кешеләребез бар. Димәк, югалмабыз әле. Бүген милли мирасыбызның яшәве, өченче меңьеллыкка чыга алуы безнең намусыбызда, туганнар. Аны изге әманәт итеп, киләчәк буыннарга лаеклы итеп тапшырырга тырышыйк, өзелгән чылбыр буыннарын төзәтик.

* * *

Керәшеннәрнең мирасында әлеге вакытка кадәр игътибардан читтә кала биргән, әмма кыйммәтен һич тә югалтмаган бер уникаль өлеше бар. Ул исә — нәсел тамгалары. Бу юлларны укыганнарның күбесе бәлки белә торганнардыр: андый тамгаларны элек «җир тамгасы» дип тә әйткәннәр.

Борынгы заманнарда кешеләрнең, аерым хуҗаларның, ыруларның үз махсус тамгалары булган. Бу ыру кешеләре, шул тамгалар белән үзләре билгән урман өлешләренең читендә торган имән агачларын, печәнлекләрен, умарталыкларын, көтүлек һәм иген игү җирләрен, шулай ук төрле патша ярлыкларын, документларын теркәгән.

Тамгаларның барлыкка килүе бик борынгы дәверләргә барып тоташа. Шуңа күрә күп кенә тамгалар төрки руник язма үрнәкләренә бик якын тора һәм, һичшиксез, шулар белән бер тамырлы. Бүгенге көндә төрки руник язмалары һәм нәсел тамгалары актив рәвештә өйрәнелә. Бу җәһәттән караганда, буыннан буынга күчеп килгән керәшеннәрнең ыру тамгалары да тарихи һәм фәнни кыйммәткә ия. Элек һәр керәшен үз нәсел тамгасының сызылышын һәм махсус аталышын, нәселенең исемен, җиде буыннан да ким булмаган ата-бабасын белгән.

Әгәр безнең мәкаләне укыган кешеләр, олырак яшьтәге туганнарыннан сорашып белеп, үз нәселләренең тамгасын яңартса, алар, һичшиксез, үз туган җирләрендә аякларына ныграк басып, үз җирләрендәге тамырларын ныгайтыр, тирәнәйтер иде. Чөнки үз тамырыңның меңәр еллык тарихлы тамга документы булу ул зур горурлык бит. Аннан шунысы да бар: нәкъ безнең буын мең еллык нәсел тамгаларыбызны онытуда гаепләнмәсен иде. Киләчәк буын, безнең нәселебезнең тамгасы нинди булган, дип соравы бар. Ахырда ата-бабаларыбыз рухы алдында без җаваплы булып калабыз.

Адәм баласы шулай яралган инде, ул еш кына үзенең тамырлары турында уйлана, чыгышын беләсе килә. Шәһәрдә үссәм дә, минем дә, башка кешеләр кебек үк, нәселем тарихын беләсем килде. Шуңа күрә мәктәп елларыннан ук атамнан, анамнан гел сорашып килдем. Минем ата-бабаларым Сарман районы Керәшен Чыршылысы (Түбән Чыршылы) авылыннан. Элеккеге фамилияләре Тимашев булган, әтиемне Оста Микуш дип йөртәләр. Аның атасы Бәчелей, аның атасы Тегермәнче Гөрей (Григорий), аның атасы Макар, аның атасы, күрәсең, Тимәш булгандыр. Нәсел тамгалары — *киләп агачы.* Чыршылы авылы кешеләре чыгышлары буенча төрле җирләрдән җыелып утырган халыктан торган. Әтием 1921 нче елда туган, ул кечерәк чагында, олы яшьтәге туганнарының бәйрәмнәрдә, әрәт йөргән вакытта: «Без бит Тау Иле нәселләре — үзебезне сынатмыйык»,— дип сөйләшкәннәрен хәтерли.

*Мамадыш районы Әҗмәк (Васильево) авылы нәселләренең тамга үрнәкләре*

| Фамилия | Кушамат | Тамга | Тамга атамасы |
|---|---|---|---|
| Анисимов | үнич | | сәнәк |
| Артемьев | үртей | | сәнәк |
| Поляков | пүләк | | кисәү агачы |

Билгеле ки, XVIII—XIX гасырларда керәшеннәрне Каманың уң ягыннан сул ягындагы җирләргә күпләп күчереп утырта башлаганнар. Алардан соң буш калган авылларга Россиянең дәүләт түрәләре тарафыннан китертелгән рус крестьяннарын утырткannar. Шундыйлардан, мәсәлән, Мамадыш районы Тавели (ягъни Тау Иле) дигән рус авылы санала. Минем фикеремчә, бу авылның элекке төп кешеләре (керәшеннәр) Каманың сул ягындагы авылларга таратылып бетерелгән. Бу як керәшен авылларында күп кенә Тавлин, Горский, Тавлинов фамилияле нәселләр бар. Безнең нәсел, тамырлары Тавлин фамилиясен

йөртмәсә дә, бабаларыбыз Тау Иленнән икәнлеген онытмаган. Моннан чыгып, без Мамадыш яклары белән бәйле, дип исәпләргә нигез бар. Алдагы елларда җыелган тамгаларны чагыштырып тикшерүләр, бәлки, тагы да көтелмәгән ачышларга китерер.

Безнең Тамгалар китабы әле язылмаган, әмма, Ходай ярдәме белән, җан-күңелләрен суытмаган энтузиастлар, белгечләр тырышлыгы белән, ул әзерләнер дип өметләнәбез.

* * *

Югарыда сөйләнелгән сүзләрнең практик башлангычы итеп, төрле елларда җыелган тамга үрнәкләрен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Безнең тарафтан җыелган тамга материалларының үзенчәлеге бар. Аларның күпчелек өлеше керәшен зиратларында җыелды. Мондый эшкә хәзер дә мөмкинлекләр бар, чөнки элек, ягъни 50—60 нчы елларга кадәрле куелган һәр качта пәке белән нәсел тамгасы уелган. Әмма безнең язмаларда ул тамгаларның махсус атамалары, мәсәлән, *бөгалҗе, киләп агачы, казаяк, түтәл, өч борма* һ. б. кебекләре теркәлә алмады диярлек. Шуңа күрә тамга хуҗаларының исем-фамилияләре, нәсел кушаматлары күбесе теркәлмичә калды. Тамгаларның тик бер өлеше генә олырак яшьтәге кешеләрнең хәтере буенча язылып алынды. Телгә алынган кимчелекләр, әлбәттә, тәкъдим ителгән язмаларның кыйммәтлеген җуймый һәм алар тора-бара уникаль бер тарихи документлар дәрәҗәсен алыр.

Түбәндәге материаллар укучыларыбызга үзләренең нәсел тамгаларын табарга булышса яисә аларны табар өчен эзләү дәрте кабындырса, без бик шат булыр идек. Сезнең булышлыгыгыз белән, бәлки, әлеге мәгълүматларны тулыландырып та булыр иде, чөнки берәү генә яисә берничә кеше генә мондый җентекле эшне эшләрлек түгел бит. Әлегә кадәр алар зиратларда да бар, ә бик тырышып эзләнсәң, сорашсаң, тамгаларны белүче авыл картларын да табып буладыр. Мондый эш мәктәпләрдәге тарих дәресләре өчен бигрәк тә кирәкле һәм савaплы булыр иде. Алдагы көндә исә барлык керәшен авылларының да ыру-нәсел һәм тамга карталарын төзергә мөмкинлек туар, дигән өмет бар.

*Менделеев районындагы Бигәш Иске (Гришкино) авылының*
*нәсел тамгалары үрнәкләре*

Тамга

Тамга атамасы

Тамга

Тамга атамасы

1. бер чыбыклы — төрткеле кәшә

2. өч төрткеле

3. биш төрткеле

4. ике кыек чыбык — (какайлар нәселенеке)

5. капка

6. ике чыбык

7. крис

8. тапкыр

9. божра (җапайлар нәселенеке)

10. бер төрткеле кәшә

11. бер чыбыклы кәшә

12. кәшә (иштаннар

нәселенеке)

*Минзәлә районы Югары Юшады авылы зиратыкачларындагы тамгалар күчерелмәсе*

1.

өч борма

2.

киләп агачы

3.

4.

5.

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

***Февраль***

Татар халкы арасында озак вакытлар кулланылышта булган Кояш календаренда ел тәүлеге хәзерге февральгә туры килә торган хут ае белән тәмамлана. Бу — кояшның Хут (Балык) йолдызлыгыннан үтү вакыты. Ай исеме буларак, «Хут» атамасы безнең халык сынамышларында еш очрый: «Хут туды — ут туды», «Хут көне — ут көне», «Хут керде — хатыннарга ут керде» һ. б. Алар кышкы чорда, шул җөмләдән, февральдә, хатын-кызлар өчен уттай кызу эш вакыты булуга, төрле кул эшләренең күплегенә ишарә ясый.

Инде кыр эшләренә килгәндә, бу чорда игенчеләр алардан бераз бушап, тынып торган. Шуңа күрә дә аграр характердагы Ай–Кояш календаренда февраль «буш ай» дигән исем йөрткән. Хәер, моның мәгънәсен «амбарлар иске уңыш икмәгеннән бушап калган ай» дип тә аңлату бар.

Февраль безгә салкыннар, бураннар гына китерми, бәлки кояшлы көннәрне дә шактый ук юмарт бүләк итә. Көннән-көн югарырак күтәрелә барган февраль кояшы һаман ягымлырак карый, ул инде җиргә яктылыкны январьдагыга караганда ике тапкыр күбрәк сибә. Ай дәвамында көн озынлыгы ике сәгатькә арта. Халыкча, образлы итеп әйтсәк, «декабрьдә көн — чыпчык адымы, январьда — карга адымы, февральдә ат адымы кадәр озыная». Бу сынамыш мондый бер тәҗрибәгә нигезләнгән. Элек халык синоптиклары иң кыска көнгә —
22 нче декабрьгә — вакытның күпме өстәлә баруын утыртып куелган колга күләгәсенең төш вакытындагы озынлыгына карап билгеләгәннәр. Төш вакытында күләгә озынлыгы декабрьдә — чыпчык, январьда — карга, февральдә ат адымы кадәр кими барган.

Башка айларныкы кебек, февральнең дә аерым көннәре табигать календаренда әһәмиятле даталар булып санала:

Беренче февральдә төнлә йолдызлар күренсә — яз соңга калу галәмәте.

Әүвәл киче аяз — бик соң килер яз.

Икенче февральдә көн җылы булса, яз иртә килер һәм җылы булыр.

Икесендә иртә белән кар яуса, ашлыкның иртә чәчкәне уңа; кич белән кар яуса, гаҗәп түгел — соң чәчкәне уңа.

Унбишенче февральдә җылы булса, яз яхшы килә.

Февраль карга бай, апрель суга бай.

Февральдә каен ботагында карлар алка-алка булып асылынып торса, ул елда иген уңар.

*Александр Филиппов*

## Уразага керү

22 нче февраль Олы көн уразасы башланыр алдыннан ит ризыклары ашарга рөхсәт ителә торган иң соңгы көн булды. Ураза алдының соңгы атнасын халыкта Май чабу (Масленица) дип атыйлар. Православие дине кушуы буенча, бу атнаны май атнасы диләр һәм бу җиде көндә кешеләр ураза тоту юлы белән тәннәрен тазартырга, чистарынырга тиеш. Прости кичендә (Прощеное воскресенье) якыннарыңның, туганнарыңның җазыкларын җарлыкау, кичерү турында Евангелие укыла. Бу көнне бөтен христианнар бер-берсенең җазыкларын кичерә, җазыгы кичерелгән һәм башкаларның җазыгын кичергән кеше генә

икенче көнне Җан тынычлыгы белән Олы көн уразасына керә ала. Уразага керәсе атнага каршы сөт ризыклары (сырная пища) гына ашарга рөхсәт ителә. Кешеләрнең рухи яктан да чистарынуларын күздә тотып, бу атнада чиркәүләрдә кәбен кою (венчание) үткәрелми. Олы көн уразасы башлануга каршы көндә чиркәү барлык христианнарны Адәмнең оҗмактан куылуы турында искәртә, шул исәптән Алла сүзеннән чыкмаска, языкланмаска өнди.

Олы көн уразасы — иң озын ураза, ул кешенең җанын да, тәнен дә аруландыра. Соңгы вакытта фәндә бик күп төрле сәламәтләндерү методикалары барлыкка килде (Ивановчылар, аеры туклану, төрле диеталар куллану һ. б.).

*Дьякон Василий*

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН ГЕРОЙЛАР**

*Столяров Н. Г.*— очучы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое, Казанның Киров районында — батырның туган җирендә — аңа бронза бюст куелган. *Якушин А. М.* (Лаеш районының Иванай авылы), *Бикбов Е. А.* (Чиләбе өлкәсендәге Нагайбәк районының Остроленка бистәсе), *Гаврилов П. М.* (Питрәч районының Әлбәден авылы), *Гордов В. Н.* (Минзәлә районының Матвеевка авылы), *Карбышев Д. М.* (Омск шәһәре), *Кузьмин М. К.* (Яшел Үзән районының Иске Тебәрдин авылы), *Максимов И. Т.*, *Москвин М. К.* (Мамадыш районының Албай авылы), *Орлов Н. С.* (Актаныш районының Зөбәер авылы), *Осипов И. Т.* (Алтай өлкәсе), *Санфирова О. А.* (Самара шәһәре), *Тапиков С. М.* (Минзәлә районының Яңа Мәлкән авылы), *Токарликов Н. Е.* (Әлмәт районының Кәләй авылы), *Федоров И. М.* (Кайбыч районының Төрмән авылы), *Четенев А. С.* (Кемерево өлкәсе).

*Тугалева Надежда Никитична* — Бөек Ватан сугышының куркусыз разведчигы. 1923 нче елда Чиләбе өлкәсендәге Нагайбәк районының Париж авылында туган. Фронтка үз теләге белән китә һәм сугыш юлын 1945 нче елның маенда Германиядә тәмамлый. Кызыл Йолдыз, I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән, «Кенигсбергны алган өчен» һ. б. медальләр белән бүләкләнгән. Хәзерге көндә Магнитогорск шәһәрендә киләчәк буынга патриотик тәрбия бирү өлкәсендә зур эш алып бара.

*Санфирова Ольга Александровна* (1917—1944) — Советлар Союзы Герое. Самара шәһәрендә туган. Батайск авиация мәктәбен тәмамлап, Новосибирск шәһәре аэроклубында пилот-инструктор булып эшли. Сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китә һәм Тамань төнге бомбардировщиклары авиа-дивизиясендә очучы була. Яуда һәлак була. 1945 нче елның 23 нче февралендә Герой исеме ала. Гродно шәһәрендә (Белоруссия) туганнар каберлегендә күмелгән. Шул ук шәһәрдә бер урам аның исемен йөртә.

## Кызлар-йолдызлар

Бу китап кызлар турында, аларның мәхәббәте турында.

Давыллы, ялкынлы көннәрдә ике чибәр кыз яшәгән. Аларның берсе...

Аның рәсемен мин өстәлемдә тотам. Аңа карап сокланам. Яктыга сузылган гөл шикелле һаман аңа талпынам, аңа омтылам. Менә бүген иртән дә уйларымда шул кыз иде. Сак кына торып, өстәл янына килдем. Әнә нинди гүзәл ул! Дулкынланып торган чем-кара бөдрә чәч, кыйгач кашлар, озын керфекле кара күзләр, алсу иреннәр... Оялчан елмаюыннан алып керфек бөртегенә чаклы безнеке ул! Йокыга талган гүзәлләрне аның белән чагыштыру зур гаделсезлек булыр иде.

Патшалар, корольләр, ханнар, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр үзләренә кәләшлеккә сайлап алган асыл сөякләр тышкы салкын матурлыкка гына ия булган. Ә бу... Бу — лачын кыз. Сөйләтәсе иде аңардан зәңгәр күкләрне иңләгәндә күргән-белгәннәрен, ил хакын олылап кылган изгелек-тәвәккәллекләрен!..

Иптәшләре Ольга Санфированы, үз итеп, Лэйлә дип йөрткәннәр. Ул, 1941 нче елда илебезгә дошман бәреп кергәч, ВЛКСМ Үзәк Комитеты чакыруына кушылып, үзе теләп фронтка китә һәм Кызыл Йолдыз орденлы 46 нчы гвардия төнге бомбардировщиклар хатын-кыз авиация полкында гади очучыдан эскадрилья командиры дәрәҗәсенә күтәрелә. Кызыл Йолдыз, Александр Невский, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә. 1945 нче елның 23 нче февралендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек була...

Балкып кояш чыкканчы, күкләрне айкап, канаты каерылмыйча, гөлбакча-җиргә төшә алган икенче лачын кыз Мәгубә исемле.

Ул да Герой.
Ул да очучы булган.
Мәгубә белән Ольга бер полкта хезмәт иткәннәр.

* * *

Ләйләне шәһәр башкарма комитетының зур залына куйдык. Гродно халкы очучы кыз белән биш сәгать хушлашты. Табутны без, полкташлары, күтәреп бардык. Безнең арттан шәһәр халкы агылды. Парк уртасында казылган кабер янына тукталдык. Комиссар Рачкевич кайгы митингысын ачты, Ләйләнең батырлыклары турында сөйләде. (Ул чакта Санфировага Советлар Союзы Герое исеме бирелмәгән иде әле.)

Полк байрагы, беренче орденын алган көндә тезләнеп үпкән, дошманга рәхимсез булырга ант иткән гвардия байрагы түбән таба иелгән. Шунда ук бәрхеттә орденнар. Аларның хуҗасы Ләйлә үзе кызыл табутта ята. Йөзе ак, әүвәлгечә тыныч, сөйкемле аның. Ул, очыштан кайткач, йокыга талган шикелле, менә торып утырыр шикелле. Аның үлүенә ышанасы килми. Әле кайчан гына сугыш беткәч ничек яшәү турында икәү сөйләшкән идек, хыялланган идек. Шул хыялларны искә төшереп, Ләйләнең кара бөдрәләренә, күлмәгенә кадарга ярарлык чәчәкләр сыман, эре-эре кар бөртекләре кунган.

Аңа туй шатлыгын тату насыйп булмады шул, үзе кебекләр актан, пакьтән киенеп, никах мәҗлесе түрендә балкысын өчен, күпләр, бик күпләр чын яшәсен өчен аяусыз көрәштә өзелде аның чәчәк кебек гомере. Чибәрләрнең чибәрен, сылуларның сылуын бүген салкын җир куенына салып калдырырга туры килә. Әнә комиссар сөйләп бетерде. Оркестр матәм моңнары белән күңелләрне елата. Литаврлар үч алырга өндәп чыңлады. Өч рәт залп яңгырады.

— Хуш, сугышчан дустыбыз!..
— Хуш, Ләйлә, бәгырь кисәгем!..
*Шамил Рәкыйпов*

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН ГЕНЕРАЛЛАР**

*Белов А. Р.* (Менделеевск районының Яңа Гришкино авылы), *Колчерин С. Д.* (Зәй районының Әхмәт авылы), *Милушев А. К.* (Тамбов өлкәсенең Татарщино авылы), *Новиков П. Г.* (Чистай районының Югары Кондрата авылы), *Салманов Г. И.* (Башкортстандагы Бакалы районының Акман авылы), *Яковлев А. Е.* (Балык Бистәсе районының Иванай авылы).

## Илне саклау — егет бурычы

Аның Россия телевидениесеннән чыгышын берничә тапкыр карарга туры килгәне бар иде. Нык, таза гәүдәле бу генерал-лейтенант «кайнар» нокталардагы хәрби хәрәкәтләргә карата үз бәяләмәсен бирде. Россия Федерациясе чик буе гаскәрләре Баш штабы начальнигы урынбасары Владимир Николаевич Макаровның бик тә татар йөзле булуы игътибарны җәлеп иткән иде.

Менә шул чактагы тоемлау дөрес булып чыкты бит, әй! Эзләнә торгач, генерал-лейтенант В. Н. Макаровның безнең якташ һәм керәшен егете булуы ачыкланды. Аның әтисе Николай Семенович (инде вафат) һәм әнисе Елена Михайловна икесе дә Кайбыч районының Соравылында туып үскәннәр икән. Булачак генералның әтисе озак еллар майор дәрәҗәсендә Урта Азия чик буе округында хезмәт иткән. Әнисе исә мәктәптә укытучы булып эшләгән. Шулай итеп, Кайбыч районында туып үскән өченче генерал эзләп табылды.

...Володя белемне Ташкенттагы чик буе гаскәрләренең интернат мәктәбендә ала. Ә каникул вакытында һәр җәйдә Соравылга әби-бабалары янына ял итәргә кайта. Бирелдәге инештә су коена, урманга җиләккә йөри, мал-туар өчен печән җыеша. Әлбәттә, керәшен халкының үзенчәлекле гореф-гадәтләрен күреп, аңа үзендә эчке хөрмәт тәрбияләп үсә, барысын да хәтеренә сеңдерә. Ул әтисе хезмәт итә торган заставада, таш таулар арасында да еш була. Чик буе сакчысының авыр һәм мавыктыргыч хезмәтен кечкенәдән үк аңлап үсә.

1972 нче елда Төрекмәнстандагы Керки шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлагач, егет алдында, киләчәктә нинди һөнәр сайларга, дигән сорау да тормый. Ул әтисе юлыннан китәргә карар итә һәм Мәскәү Чик буе гаскәрләре югары хәрби училищесына барып керә. Аны тәмамлагач, әтисе янына кайтып, Урта Азия чик буе округында, СССР — Иран чигендәге бер заставада хезмәтен башлый.

Биредәге хәтәр тау сукмакларыннан, ком чүлләреннән аңа күпме чакрымнар узарга туры килде икән? Чик сакчысы моны саныймы соң! Ул туган иленең иминлеге өчен җавап бирә, аның чигеннән шпионнар, контрабандистлар һ. б. үтеп чыкмасын өчен, бөтен тырышлыгын куя. Яшь офицер Владимир Макаров тиз арада үзен алдынгы чик сакчысы итеп таныта. Табигый кыен шартларда да югалып калмавы, чыдам һәм сизгер булуы өчен һәрвакыт башкаларга үрнәк итеп куела.

Менә шул сыйфатлары өчен дә аны, Әфганстанда авыр сугышлар башлангач, беренчеләрдән итеп 40 нчы армия составына җибәрәләр. Офицер В.Макаров анда дүрт елга якын була, күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша, берничә орден һәм медаль белән бүләкләнә. Ә 1984 нче елдан якташыбыз М. В. Фрунзе исемендәге хәрби академиядә укый башлый.

Аны уңышлы тәмамлагач, югары хәрби белемле офицер Совет — Финляндия чигендә хезмәт итә, даны еракларда билгеле чик буе отрядына җитәкче итеп билгеләнә. Аннары без аның Россия Кораллы Көчләренең Генераль штабы академиясендә хәрби гыйлем арттыруын беләбез. Академияне «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлагач, Кайбыч егете Тын океан ярларында, Россия — Кытай чигендә хезмәт итә. Хатыны, чик сагы хезмәтенең өлкән прапорщигы Галина Николаевна белән бергәләп алар менә шулай Туган ил чигенең күп заставаларында булалар. Якташыбыз шул ук вакытта хәрби хезмәт баскычларыннан югары күтәрелүен дә дәвам итә. Инде әйткәнемчә, ул бүген Россия Федераль чик сагы хезмәтенең Баш штабы начальнигы урынбасары.

— Без биредә хәзер Татарстан Республикасындагы Баш Федераль инспектор, генерал-майор Марсель Мәгъфур улы Галимәрдәнов белән кулга-кул тотышып эшләгән идек. Аның белән, җае чыкканда, хәзер дә очрашып торабыз. РФ Федераль чик сагы хезмәтенең Көньяк-Көнчыгыш төбәк идарәсе начальнигы генерал-лейтенант Рамил Шамил улы Муллаянов белән аеруча еш аралашырга туры килә. Менә шулай татар егетләре без бер-беребезне онытмыйбыз,— ди Владимир Николаевич.

Якташыбыз бабасының әтисе Макар Иванович Ямщиковның 1904—1905 нче елгы рус-япон сугышында катнашуын әйтергә кирәк. Ул — разведка отряды командиры, прапорщик, зур батырлыклары өчен Георгий тәресе белән бүләкләнә. Әлеге югары дәрәҗәле сугышчан бүләкне таккан солдатларга хәтта генераллар да хәрбиләрчә сәлам биреп узарга тиеш була. Макар Иванович, әлеге сугыштан исән-сау калып, Соравылга кайта һәм гаилә корып җибәрә. Аны Соравылда өлкәннәр бик оста гармунчы, җырчы һәм балта остасы буларак хәтергә ала. Бер генә керәшен туе да аның катнашыннан башка узмый, бер генә өй дә аннан башка салынмый.

Батыр йөрәкле Макар Ивановичның кече улы Алексей әле дә Соравылда яшәп ята. Аның кызын — Татарстанның атказанган артисты, танылган җырчы, Казан дәүләт педагогика университетының музыкаль педагогика факультетының өлкән укытучысы Лидия Әхмәтованы кемнәр генә белми икән?! Мөгаен, андагы җыр таланты менә шулай берничә буыннан буынга күчеп киләдер... Бай тарихлы, бары тик ике фамилиядәге бер нәсел булган Макаровлар һәм Ямщиковлар турындагы кайбер мәгълүматларны безгә аларның туганы, Бөек Ватан сугышы ветераны, «Ватаным Татарстан»ның актив хәбәрчесе Виталий ага Мершинов та язып җибәргән иде.

— Нәселебездә кыю йөрәкле, бар яктан оста һөнәрле шундый бабам булуы белән бик горурланам,— ди генерал В. Макаров.

Генерал-лейтенант В. Н. Макаровның әтисе Николай Семенович, отставкага чыкканнан соң, гаиләсе белән Зеленодол шәһәренә кайтып урнаша. Ул инде вафат. Үзенең васыяте буенча, аны Соравылда җирлиләр. Әтисен күмәргә улы генерал Владимир Николаевич та кайта. Ул, безнең якларга кайтканда, әтисе кабере янында булмыйча, аның истәлеген хөрмәтләмичә калмый.

— Мин улым белән бик горурланам. Ул Зеленодолдагы фатирыма һәрвакыт шалтыратып, хәлемне белеп тора. Җае чыккан саен кайтып та китә,— ди генералның әнисе Елена Михайловна, куанычын уртаклашып.

Россия Кораллы Көчләрендәге бүгенге аяныч хәл күпләрне борчыйдыр. Генерал-лейтенант Владимир Макаров белән дә бу хакта сүз кузгалган иде. «Безнең егетләргә армиядә хезмәт итүдән куркырга кирәкми. Хәрби хезмәт яшь кешенең характерын ныгыта, алдагы тормышында очрыйсы каршылыкларны җиңәргә өйрәтә. Туган илне саклау һәр егетнең изге бурычы да бит әле! Минем якташларым моны бервакытта да хәтереннән чыгармасыннар иде»,— диде якташыбыз. Аның җавабы хәрби хезмәткә вакыты җиткән егетләрне уйландырмыйча калмас, дип уйлыйм.

*Нургали Булатов*

* * *

«Питрау үтте — җәйләр бетте»,— диләр,
Безнең якта халык сүзендә.
Питраудан соң чәчәк атмый гөлләр,
Сары йөгерә кырлар йөзенә.

Питраудан соң яфрак бәйләмиләр,
Мәтрүшкәләр җыеп кайтмыйлар.
Үләннәрдә хуш ис бетә, диләр,
Питраудан соң печән чапмыйлар.
Питраудан соң кош сайраудан туктый,
Ишетелми кәккүк тавышы.
Җирләр сүрелә, кояш көн балкытмый,
Салмаклана тормыш агышы.

Питрау үтте, димәк, җәйләр бетте,
Болыннарга сары йөгерде.
Бу тормышның питраулары җитте,
Кыл урталай бүлеп гомерне.

* * *

Көзләр кергән җиргә, кыр уңышы
Келәтләргә — ларга юл тоткан.
Инде пешкән Покрау пироглары
Төрле ярма, төрле орлыктан.

Бушап калган басуларны урап,
Кыйгачланып киткән торналар,
Уҗымнарда иртән кырпы-кырау,
Су читләре чирап торалар.

Ындыр артларында этләр генә,
Терлек-туар кергән абзарга.
Өйдән өйгә күчеп өмә йөри,
Ихатада кими казлар да...

*Клара Булатова*

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН ЯЗУЧЫЛАР**

*Яков Емельянов* (Балык Бистәсе районының Шеморбаш авылы), *Дарья Аппакова* (Минзәлә районының Байгол авылы), *Павел Апушев* (Питрәч районының Әлбәден авылы), *Василий Тарасов* (Василий Бәгрәшевский — псевдоним, Зәй районының Югары Баграж авылы), *Давид Григорьев* (Давид Савру-шевский — псевдоним, Мамадыш районының Олы Саурыш авылы), *Гурий Тавлин* (Зәй районының Югары Баграж авылы), *Егор Уткин* (Менделеевск районының Бөрешле авылы), *Григорий Родионов* — Гәрәй Рәхим (Лениногорск районының Федотовка авылы).

## Шагыйрь, поп һәм якташ

Ул — күптән яшәп дөнья кичкән зат. Тууы — моннан 150 ел элек, вафатына да 100 елдан артык. «Кайсы дәвер соң ул һәм кемнәр заманы?» диярләр. XIX гасырның икенче яртысы. Россиядә Александр II патша вакыты. Реформалар (крепостное право бетерелү) чоры. Рус булмаган халыкларны көчләп чукындыруның, миссионерлык басымының котырган дәвере. Мөселман-татар дөньясында вәисевчеләр хәрәкәте, мәрҗаниләр мәгърифәтчелеге, басма китап тәэсире көчәйгән чорлар... Менә шул заманда яшәгән Җырчы Җәкәү (Җәкәү Җырау) — Яков Емельянов дигәннәре. Шул заман тирәлеген күзалласаң, ул —

Кандалый, Гали Чокрый, Акмулла, Мәрҗани, К. Насыйрилар замандашы. Җирдә шаккатырлык байлык-мөлкәт, том-том әсәрләр калдырмыйча, 1893 нче елны 45 яшендә дөнья куйган якташны әдәби җәмәгатьчелек һаман онытмый. Элек заманда да, Совет чорында да, хәзер дә аның исемен даими телгә алалар. Тормыш юлы һәм иҗатына багышланган язма мәкаләләр дә җитәрлек: А. Григорьев, Х. Госман, М. Гайнуллин, М. Глухов, Р. Әхмәт һәм башкаларның хезмәтләрен күздә тотып әйтәм.

Яков Емельянов иҗаты — үз шәхесе кебек үк — каршылыклы, һәм әйтер идем, идеологияләштерелгән иҗат. Бер яктан, аңы белән остазы Ильминский идеяләренә хезмәт итәргә тырышса, икенче яктан, күңеле белән үзен тудырган гади, ярлы халык интересларын якларга, аларга үзләренең нинди хәлдә икәнлекләрен аңлатырга, төшендерергә тырыша, үгет-киңәш белән генә булса да аларга ярдәм итәргә омтыла. Христиан динен пропагандалау дип аның «Ходай сине илдән алган», «Саташканны уяту» кебек шигырьләрен санасак, ә «Кайгы», «Ярлы тормыш», «Олысымаклык», «Әләк», «Улым», «Әби үгете» кебекләре — халык тормышының җанлы чагылышын күрсәткән ачык мисаллар.

Миңа калса, шагыйрьнең эчке мәгънәгә, поэтик яңарышка, эстетик кыйммәткә ия шигырьләре берничәү: алар — «Әләк», «Кайгы», «Улым», «Кояш» һ. б. Я. Емельянов иҗаты турында фикерем үзгәрә-үзгәрә байтак еллардан бирле тәгаенләнеп килә инде. Беренче тапкыр бу исемгә мин үсмер чакта (1957 нче ел бугай) «Татар поэзиясе антологиясе» китабын укыганда тап булдым. Безнең төбәк кешесе булгач, үзгә бер кызыксынып, дулкынланып укыдым мин ул шигырьләрне. Дөресен әйтим: артык тәэсир итмәде алар миңа. Аңлашыла да: үсмер җанга романтика, оптимистик дәрт, хисләндергеч лирика кирәк, китапча югары стиль, матур чагыштырулар, томанга эретелгән образлар, хыялый серләр кирәк... Укылган шигырьләр минем өчен артык гади, хәтта тупасрак та булып тоелды. Безгә артыгы белән таныш натур фәкыйрь күренешләр... Бер ишләре әбиләр көн дә диярлек безгә тукып киткән үгет-нәсихәт, акыл өйрәтү сүзләре булып кабул ителде. Беренче тойгылар, беренче кичерешләр күп чакта дөрес була. Ул тәэссораттан ваз кичәргә җыенмыйм. Соңрак, студент елларында бу шагыйрьне бүтәнчәрәк аңлауда профессор Х. Госманның йогынтысы зур булды. Ул очынып-очынып укып күрсәтә иде «Җырчы Җәкәү» шигырьләрен! Халыкчанлы гына басым ясар иде, ритм-рифмаларының үзгәлеген әйтер, юл ахырыннан юл башына күчеп йөреп кабатлана торган сүзтезмәләр куллануны ачышларга тиңләр иде... Ул да, мәрхүм, үзенчә хаклы иде. Әмма эчке каршылыклы хис хәзер дә бетмәде... Хәер, объектив булыйк. Кайчан, кем тарафыннан, ни максаттан язылган әсәрләр алар? Җавап: моннан 120—125 ел элек христиан рухани тарафыннан шагыйрьлек миссиясенә дәгъва
итмичә күңелен бушатып, ачынып язылган «җырулар». Үзешчән иҗатның бер бөек (отышлы) ягы бар: ул — халыкчан. Я. Емельяновның 1879 нчы елда чыккан җыентыгының халык телендә «Дарҗа әби кенәгәсе» дип йөртелүе дә үзгә бер мәгънәгә ия. Бүгенге «мерседес» машинасыннан арбалы атка карап үз «бөеклегеңә» соклану егетлекме? Хәлне, вакыйганы, фактны шул заман күзлегеннән, шул заман хәятеннән чыгып бәялә син! Шул чорда иҗат иткән шагыйрьләрнең кайсысында гади халык тормышының реаль чалымнары күбрәк чагылган икән әле? Һәм дә кайсысының әсәрләрен бүгенге укучы йөгертеп аңлап укый алыр икән? Бу җәһәттән, Я. Емельянов иҗаты бик тә отышлы хәлдә. «Аны ни, нәрсә өчен олылыйлар?» дигән сорауга бер җавап-дәлил бу. Гомумән, бүгенге поэзиядә киң колач алган ирекле сөйләм интонациясенә корылган шигырьләрнең беренче яралгылары бит аларда.

Я. Емельянов турында әдәбият дәреслекләрендә беркадәр мәгълүмат булса да, алар шагыйрь шәхесен тулы күз алдына китерә алмыйлар. Асылда, ул мәгълүматлар язмадан язмага кабатланалар гына. Поп буларак, Я.Емельяновның бер авылдан бер авылга, бер приходтан икенчесенә күчеп йөрүе дә хәтер кардиограммасын тоныкландырган, әлбәттә. Халыкның хәерчелеге, руханиларның икейөзлелеге, өстеннән туктаусыз язылып торган шикаятьләр, әләкләр, һәм ниһаять, реаль тормышның үзе үк өндәгән максаттан бик-бик ераклыгы шигъри җанлы ирне нык уйландырган, йөдәткән булса кирәк.

Җәшнә, Кояш, җалтыра!
Яктың җирдә уйнасын.
Иртәнге кырау, соңгы суык
Яңа орлыкны коймасын,

дип, оптимистик рухта язса да, кырыс тормыш, барыбер, аны бөгә, сындыра. Исеме «каһәрләнгән поплар» рәтенә керә. Тикшеренүчеләрнең язуынча, гомеренең соңгы елларында ул депрессиягә бирелә...

Я. Емельяновның Борис исемле (Стариков Борис Яковлевич, нигә Емельянов түгел?) улы булуы билгеле. А. Н. Григорьев язмаларына караганда, ул да шигырьләр язган, матбугатта катнашкан. Язмышы ничек булып беткән, безгә билгесез. Алан-Полян авылында хәзер дә Стариков фамилияле гаиләләр бар. Аларның Емельяновлар нәселенә катнашы булырга тиеш. Һәрхәлдә, кызыксынучылар өчен җирлек бар.

Сүз уңаеннан, безнең як керәшен татарлары арасыннан соңгы дәвердә чыккан шәхесләр турында. Шактый алар. Чагыштырып карасаң, мөселман татарлары авылларыныкына караганда күбрәк. (Хәтердә: 1950—1960 нчы елларда Котлы Бөкәш урта мәктәбенә — Кызыл Йолдыз районына бер урта мәктәп! — Шеморбаш, Алан-Полян, Үри авылларыннан укырга килүчеләр дистәләгән иде, ә Күгәрчен, Күки, Балтач, Ямаш кебек зур татар авылларыннан килеп укучылар 1—2 генә була иде.) Кечерәк кенә авыллар үзләре — Алан-Полян, Үри, Иванай, Керәшен Казысы, Шеморбаш, Казак Чаллысы (Казаклар дип тә йөртәләр). Ә күренекле кешеләре күп, шөһрәт-даннары зур. Я. Емельяновның авылдашы — атаклы математик, профессор Петров А. Н. (1900—1969); Шеморбаштан — педагог, Үзәк керәшен мәктәбенең директоры Егоров Н. Н. (1870—1922); медицина фәннәре докторы, профессор Кибяков А. В. (1901—1989); профессор, үз вакытында Казан финанс-экономика институты ректоры, генерал-лейтенант Яковлев А. Е. (1903—1991); техник фәннәре докторы, профессор Никитин И. З. (1928); математик-профессор Ильин И. Ф. (1943); Казаклар Чаллысыннан — Советлар Союзы Герое Иванов В.П., филолог-профессор Марганова Р. А. (1954); Үридән — тарихчы әдип (керәшеннәр турында фундаменталь хезмәт — «Татарика. Энциклопедия» авторы) Глухов М. С. (1937) һ. б. Исемлекне яңа заман балалары исәбенә дәвам да итәргә мөмкин. Ә бүтән төбәк, әйтик, Зәй, Бондюг, Чистай, Бакалы (Башкортстан) якларыннан чыккан атаклы кешеләрне барлый башласаң? Уртак цивилизациягә кушылучы көчле агым килеп чыга! Моны бәһаләргә, моңа сөенергә кирәк. Гомумән, соңгы ун ел эчендә керәшен татарлары рухи тормышында җанлылык һәм яңарыш сизелә. Этномилли җәмгыятьләр барлыкка килә, җыр һәм бию ансамбльләре оеша яки торгызыла («Бигәш», «Игәнәй», «Айбагар» һ. б.), «Керәшен сүзе» газетасы нәшер ителә (1993), конкурс-фестивальләр уздырыла... Дөрес, халык тарихының чишмә башын эзләгәндә, төрле каршылыклар, гипотеза белән аксиоманы буташтырулар, чиктән чиккә ташланулар да була. Нишлисең, хакыйкать, күк капусы кебек, җиңел һәм тиз ачылмый. Шунысы куанычлы: теләсә кайсы ыру-төркемнең үз тарихын ачыклавы, үз рухи байлыгын барлавы, ахыр чиктә, уртак хәзинәбезне баету бит! Без, XIX гасырның шанлы бер улы Я. Емельяновның 150 еллыгын билгеләп үтүне дә әнә шул юнәлештә күркәм һәм кирәк бер гамәл дип бәялибез.

*Равил Фәйзуллин*

## Егор Уткин

Егор Васильевич Уткин (1932—1977) хәзерге Менделеевск районындагы Бөрешле авылында туган. Алабуга дәүләт педагогика институтын бетергәннән соң, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, газета редакциясендә хезмәткәр булып эшләгән.

Егор Уткин укучыларга лирик шагыйрь буларак билгеле. Үзенең шигырьләрендә ул, нигездә, бүгенге авыл кешеләре-нең фидакарь эшләрен, туган як табигатенең күркәмлеген, замандашларыбызның тынычлыкны яклап көрәшүләрен тасвирлый.

### Кояш сыйган кебек тамчыга

Кырыслыкка димим,
Тормыш мине
Гаделлеккә җирдә өйрәтте.
Бүрек салмыйм, илем,
Алдыңда мин
Ачып салам җанны, йөрәкне.
Уңышларың
Җанга якты бирә,
Ал нурларга көнем манчыла.
Син сыйгансың, илем, йөрәгемә,
Кояш сыйган кебек тамчыга.

### Җилдә янган учак кебек

Кеше килә, тирләп-пешеп иген игә,
Шатлык чишмәләрен ача, йортлар сала,
Йөрәккәе җилдә янган учак кебек...
Кеше бара, юллар ярып яна-яна.

Кеше китә... Карый җиргә, карый таңга
Күреп туймас, сөеп туймас күзе белән.
Бар шатлыгын безгә биреп калдыра ул,
Кайгыларын гына ала үзе белән.

## Кайту

Кызык эзләп кайтуларым түгел,
Маҗаралар эзләп китмәдем...
Артык күреп үстем һәрнәрсәдән
Туган җирнең хәләл икмәген.

Кала коймалары бүлеп тормый
Торган җирне туган җиремнән.
Балалар күк шаулап, кайттыңмы, дип,
Каршы ала мине игеннәр.

Миңа таба әнә йөгерә-йөгерә,
Колач җәеп килә солылар.
Солыларның кочагына кереп,
Сабый балалардай сыенам.

Җилләр сөя биттән, йомшак кына,
Әй, нечкәрде күңел, хисләнде.
Җаным җиргә тамыр җибәргән җир —
Туган авылым кыры, исәнме!

## Бөтен авыл чыгып озатты

Инеш буендагы тәбәнәк өй
Торыр инде, торыр йозаклы.
Карт ананы соңгы юлга илттек,
Бөтен авыл чыгып озатты.
Соңгы юлга китте ялгыз ана,
Яшелләнгәч, язгы җир кибеп...
Шушы өйдән яуга киткән иде
Өрлек кебек җиде ир-егет.

Гомерләрен салды җиде бөркет,
Утларында янды давылның.
Ап-ак чәчле ана кечерәйде
Күз алдында бөтен авылның.

Күз алдында бетеренде ничек,
Сагышыннан янып, ябыгып.
Кайгысын ил аның күтәреште,
Сүнмәс өмет йөртте аны бер.

Төпчек улы сугыш юлларында
Хат-хәбәрсез калды югалып.
Көтә иде, күзли иде ана
Шунысының кайтыр юлларын.

Күзли иде аяз иртәләрдә,
Кичен күкне япкач болытлар.
Аналарны җирдә Ана иткән
Сүнми торган хис бар, өмет бар.

Утыз еллап көтте, көтте ана,
Дөньяныкын каян beləсең!
Өметләнеп, төнгә элми иде
Капка бигеn, ишек келәсен.

Еллар белән ышанычы артты:
Кайтмый калмас йөрәк парәсе.
Күрде ана соңгы сулышында
Төпчек улын, күрде саташып.

«Кайттыңмыни, балам, мин белдем шул!
Гел күзәттем кайтыр юлыңны...»
Иренендә калды елмаюы —
Күзләр мәңгелеккә йомылды.

Сүнде сагыш... Сүнде якты гомер...
Авылым күңеленә моң ятты.
Карт ананы соңгы юлга илттек,
Бөтен авыл чыгып озатты.

## Яратам мин кышкы авыл өен

Авыл халкы кибетләргә йөрми,
Ул пешерә өйдә күмәчен.
Моны инде тормыш кына түгел,
Җаны таләп итә, күрәсең.

Иртән ягып, мичкә салган ипи
Пешеп, өсте җитеп килгәндә,
Өй эченә гүя июль килә,
Ят та ауна менә идәнгә.

Бүлмә тула басу исе белән.
(Бу чак тышта салкын... Кар ява...)
Башактагы орлык өлгергәндә,
Кырдан шундый хуш ис тарала.

Яратам мин яшьтән авыл өен,
Аның ачык йөзле кешесен.
Күңеле, миче кебек, җылы бөрки,
Бүлмәсендә икмәк — июль исе.

## Халык мәхәббәте яралган

Салкын җилләр исә, карлар төшә,
Урамнарда бүген кыш, буран...
Сирәк килсәм дә мин сиңа, Казан,
Тукай каберендә еш булам.

Бишектән үк җырын отып үстем,
Моннан изгерәк җир ул кайда?

Салкын бураннарда җанлы чәчәк —
Чәчәк китергәннәр Тукайга.

Кем китергән — эзен җил себергән,
Кемнәр киткән — эзгә кар яуган.
Һәйкәл тирәсендә, чәчәк булып,
Халык мәхәббәте ялалган.

### Ак каеннар томан ерып чыга

Яз кояшы күтәрелеп килә,
Бөтен дөнья нурга уралган.
Авыл кырындагы үзәнлектә
Ак каеннар чыга томаннан.
Үзән буйлап күксел томан ята,
Хәтерләтеп көзге инешне.
Яшь кызлар күк зифа бу каеннар,—
Яшь кызларга нәрсә килешми?!

Ничек көтсен, түзми көтсен алар
Томан-елга агып үткәнен.
Ак каеннар томан ерып чыга,
Чуклы итәкләрен күтәреп.

### Тамчы чыктай керсез бала чагым

Кояш нуры тулып мөлдерәгән
Яшел үләндәге тамчы чык,
Сабый чагым, синең кебек керсез,
Басу капкасыдай гел ачык.
Юлда җилләр, юлда яңгыр була,
Керләнәмен юлда, тапланам.
Тамчы чыктай керсез бала чагым,
Күңелем сиңа кайтып сафлана.

*Егор Уткин*

## Гурий Тавлин

Гурий Тавлинның вафаты турында хәбәр алгач, күңелемне авыр уйлар биләде. Әлбәттә, милләтчелектә гаепләнү, репрессия, төрмәләр кеше йөрәгендә эз калдырмыйча гына үтмәгәннәрдер. Реабилитацияләнгәч тә, бу гаделсез дөньяда кагылу-сугылулар да сәламәтлеген җимерүдә әз эш башкармаганнардыр. Гомумән, яшь чагында алган йөрәк яраларыннан гомеренең соңгы көннәренә кадәр кан саркыгандыр аның.

Гурий Тавлинның гомере тулысы белән гаделлек өчен көрәштән гыйбарәт булды, ләкин, кызганычка каршы, ул аның җиңүен күрә алмады.

Язучының вафатыннан соң мондый уйлануларымның сәбәбе шул: ул минем якын, таныш кешем һәм авылдашым иде. Күз алдыма аның яшь чагы: аксыл-соры шинель кигән озын буе, дулкынланып торган калын чәчләре, үз-үзенә нык ышанганлыкны хәтерләткән йөзе килеп баса. Аның исемен искә алуга, энесе Иван (Ванюк), әнисе Машук әби дә (алар да мәрхүмнәр инде) күз алдыма килә.

Керәшеннәр кушаматсыз булмый дигәндәй, боларның да нәсел-нәселдән күчеп килә торган икенче исемнәре «мулла» иде. Багражда Гурий Тавлинны, аның инде танылган олуг язучы булуына карамастан, яратып, үз итеп «Мулла Гүрие» дип йөрттеләр. Ул үзе дә бу кушаматны ихлас күңелдән яратып кабул итте, кушаматы белән дәшкәндә, һәрвакыт елмаеп кына җавап бирә иде.

Мулла — белемле, мәдәниятле һәм югары эрудицияле кеше. Аны мөселманнар гына түгел, керәшеннәр дә шулай кабул итә һәм шуңа муллаларны зурлыйлар да. Тавлиннар нәселенә «мулла» кушаматын дөрес биргәннәр, чөнки муллаларның күп кенә принципиаль, кешелекле сыйфатлары боларга да хас иде.

Тавлинның энесе Иван, дәдәсе кебек, яшьтән үк язучылык эшенә керешә — хикәяләр яза. Минем аңлавымча, хикәяләре тирән эчтәлекле, шул заман системасын кыю һәм үткен тәнкыйтьләү, түрәләрдән һәм заман пычраклыкларыннан ачы итеп көлү белән сугарылган иде. Ләкин ул вакытта, мәгълүм сәбәпләр аркасында, андый хикәяләрне басмыйлар, алар редакция киштәләрендә тузан җыярга гына кала иде.

Әниләре — Машук әби — авылыбызда иң укымышлы кеше булды. Дөрес, укымышлылыгы әллә нинди институт, университетлар түгел, ә дөньяви, җәмгыяви белемнәр генә иде. Авылдагы бөтен үлем-җитем, бала туу, керәшен дини бәйрәмнәре, гадәт-йолалары аның тиешле иман укуларыннан, келәү-җыруларыннан башка узмый торган иде. Аның үзенә генә хас матур чиркәү-келәү тавышы бар иде. Гомумән, Машук әби авылдашларга эзлекле дини тәрбия бирергә, балаларга, яшьләргә керәшен гореф-гадәтләрен, йолаларын тапшырып калдырырга тырышты, шуңадыр бу вазифаларны ул, яратып, үзенең күңел кушуы белән башкарды.

Әтиләре, «Афәт» романында тасвирланганча, җәмгыятькә, совет властена «башкача карашлары» өчен репрессияләнгән.

Кыскасы, Гурий Тавлин әнә шундый «мулла» гаиләсеннән чыккан талант иясе иде. Шунысын да әйтергә кирәк: аның фамилиясе Тавлин түгел, ә Тавлинов иде. Монысын, мөгаен, язучы булырга хыялланып йөргәндә, үзе кыскарткандыр, дип уйлыйм.

Безнең Гурий Тавлин белән яшь аермабыз 11 ел. Димәк, без таякка атланып «атлы» уйнап йөргән малай чакларда ул сугыш кырында булган, аннан соң институт аудиторияләрендә лекцияләр тыңлаган, ә инде без егет булып җитешкәндә, төрмә сәндерәләрен шомарткан. Аннан соң да байтак еллар буена безнең тормыш сукмакларыбыз кисешмәде. Шунлыктан без бер- беребезне фәкать авылдашлар буларак кына белдек.

Беренче мәртәбә аның белән мин 1992 нче елда Зәй шәһәрендә «Зәй офыклары» газетасы редакциясендә, мин газетаның редакторы, ул «Татарстан хәбәрләре» газетасының махсус хәбәрчесе буларак очраштык. Ләкин без күбрәк, нихәл итмәк кирәк, эш турында түгел, ә туган авылыбыз, туганнарыбыз, халкыбыз проблемалары турында сөйләштек. Мин аның энесен, әнисен, ул минем дәдәйләрне яхшы белгәнгә, без бер-беребез белән күптәннән таныш кешеләр кебек аралаштык.

Гурий Тавлин ул елларны туган Зәй якларына еш кайтты. Кайткан саен беренче безнең редакциягә керә торган иде. Тавлин дәрәҗәсендәге язучыларның, республика газеталары хәбәрчеләренең, хәтта аннан күпкә түбәннәрнең дә, районга килгәнче, беренче хакимияткә шалтыратуларын, үзләрен югары дәрәҗәдәге чиновникларны каршылаган кебек каршы алуларын, кунакханәләрнең иң шәп номерларына урнаштыруларын, алдынгырак колхоз-совхозларга, бераз мантып киткән предприятиеләргә озатып йөрүләрен таләп иткәннәрен мин яхшы беләм. Әлеге язучы-хәбәрчеләрнең тиешле заказ буенча язуларын да, тулысы белән әҗерен кайтарып алуларын да, соңыннан Казанына кадәр илттереп куюларын да яхшы беләм. Шулай булгач, андый язучы-хәбәрчеләрнең ни хаҗәтләренә кирәк булсын ул хәерче редакция — керү түгел, төкерми дә ул аңа. Ә Гурий Тавлин мондый хәсрәт язучы-хәбәрчеләргә капма-каршы кеше иде. Ул яртышар көн автобуста арып-талып килер иде, кунакханәгә дә урнашмыйча, я туган авылына кайтып китәр, я берәр таныш-белешенә урнашыр иде. Шулардан чыгып, мин Гурий Тавлинның чын керәшеннәргә хас холыклы: риясыз, тыйнак, беркайчан зарланмый, беркемгә үпкәләми, мөмкинлекләреннән усал һәм шәхси ниятләрдә файдаланмый торган кеше икәнлегенә чын күңелемнән ышандым.

* * *

Гурий Тавлинның бер килүендә, аның «Афәт» романы хакында җитди генә сүз чыкты. Романны мин «Казан утлары» журналыннан укыган идем, әсәрнең персонажлары да хәтеремдә ачык саклана. Мин язучыга шундый сорау бирдем:

— Гурий Иванович, син үзең керәшен, романыңда да, нигездә, керәшен тормышы күз алдына килә. Керәшен гадәтләре, йолалары әсәрдә күпләп бирелгән, хәтта сөйләмдә дә керәшенлек сизелә. Ә геройларның исемнәре татарча. Нигә дөреслек — объективлылык хакына булса да — үзеңнең геройларының яртысын керәшеннәрдән «ясамадың»? Минемчә, романың тагын да уңышлырак чыккан булыр иде,— дидем.

Гурий Иванович, бераз уйлап торды да, җитди төс алып:

— Син беләсеңме, Иван, мин роман язган вакытта һәм әсәр үз эченә алган вакыйгалар барган чорда керәшеннәрнең «юк» икәнен? Шулай булгач, әгәр мин романыма яртысын түгел, 3—4 кенә керәшен герое керткән булсам да, каян алган бу кешеләрне Гурий Тавлин, дип, әсәремне, беренчедән, басмыйлар иде, икенчедән, очраклы рәвештә басылганда да, мине ул елларда яңадан милләтчелектә гаепләүләре бар иде.

Мин язучының репрессияләр белән җәфалануы өстенә, шул вакытлар турында язылган романын егерме ел буена чыгара алмыйча, гомере буена фикерләр, намус, җәмгыяви системалар, милләтара ыгы-зыгылар, гаделсез дөнья эчендә тәмам эштән чыкканчы көрәшкән дә көрәшкән икән, дигән нәтиҗәгә киләм.

* * *

1996 нчы ел, май азакларының кояшлы, эссе бер көне. Кабинетыма Гурий Иванович килеп керде. Кыска җиңле соргылт калын күлмәктән, яланбаш, кулында зур портфель. Күзгә-күз карашып, кул кысышып күрештек. Шунда ук сизендем, моның белән нәрсәдер булган: йөреше дә бераз картларча-атыныбрак, йөзе дә нык кына таушалган-каралып киткән, сөйләмендә дә ниндидер таркаулык сизелә. Сөйләшү барышында аңлашылды: озак кына авырып яткан икән — микро-инсульт.

Ләкин, әллә язгы айның гаҗәеп матурлыгы, әллә каядыр барырга ашкынуы чирен бөтенләй оныттырган.

— Авылда булдым әле,— дип сүзен дәвам итте ул.— Зиратка барып, әнинең һәм Ванюкның кабер өсләрен чистарттым, рәшәткәләрен зәңгәр төскә буядым. Симеттә кешегә күрсәтерлек итеп хәстәрләп куйдым.

Сүз дә юк, Гурий Ивановичны Баграж зиратына кабер өсләре чистарту теләге генә түгел, ә олыгаю галәмәте, бәлки туганнарының кабер өсләрен соңгы мәртәбә күреп калу өмете, туган авылы табигатен, инешен, су буе тал-чыбыкларын, зәңгәр күген, каршы тавын күңеле түренә сеңдереп калу нияте сөйрәп кайтаргандыр. Олы кеше шуның белән үзенә алыштыргысыз юаныч таба — бу чиркәүләрдә үлгәннәр рухына шәм яндырып, җазыклардан арынуга тиң хис бит. Башымнан шундый уйлар узганда, Гурий Иванович саргаеп беткән бер фоторәсем сузды һәм: «Таныйсыңмы?» — диде.

Фоторәсемне кулыма алдым. Анда дүрт хатын — икесе алда утырып, икесе артта басып төшкәннәр. Фоторәсемнең артына, инде уңудан төсен югалткан кара белән, «1940 нчы ел» дип язылган. Алда утыручыларның сулдагысын мин тиз таныдым — ул Гурий Ивановичның әнисе иде. Машук әби озын гомер кичерде. Ул үлгәндә, мин үзем дә ир урталарына җитеп килә идем инде.

* * *

Гурий Тавлин татар әдәбиятында аның бүгенге аксакаллары белән янәшә куярлык шәхес, бернинди арттырусыз классикларыбызга тиң язучы иде. Ул беркайчан да дан, шөһрәт артыннан кумады. Аңа алар үзләре безгә билгеле һәм күп кенә билгесез сәбәпләр аркасында бик соңлап, гомеренең көзендә генә килде. Аның беренче зур әсәрен — «Дунай дулкыннары» романын — махсус юк иттеләр, икенче зур, тулы бер тарихи эпопеяны сурәтләгән роман-трилогиясе — «Афәт»не — чирек гасыр буена богауда яткырдылар. Кыска гына мизгел эчендә, шушы романнар укучыга үз вакытында килеп җиттеләр, дип күз алдына китерик — Гурий Тавлин, һичшиксез, халык хөрмәтен хәзергедән бик күп еллар элек яулаган булыр иде.

Гурий Тавлинның әсәрләре бүгенге көндә өйрәнүгә мохтаҗ. Аның роман-повестьларын мәктәп дәреслекләренә һәм хрестоматияләргә кертү хәзерге яшьләрне әхлакый тәрбияләүдә зур этәргеч булыр иде.

*Иван Глухов*

## Диңгез кабырчыгы

Мин мәктәп бусагасын яңа гына атлап кергән малай идем әле. Көз көне әнием белән бертуган тутамның улы Гриша дәдәй Ерак Көнчыгышта Кызыл Армиядә хезмәт итеп авылларына әйләнеп кайтты. Әнием белән мин аларга кунакка бардык. Дәдәйнең өстендәге кызылармеец киемнәреннән күзләремне ала алмадым. Хәрби киемдә дәдәй әкияти баһадир кебек иде. Мине бигрәк тә аның зур кызыл йолдызлы шлемы таң калдырды. Андый җыелма колакчынлы, очлы түбәле гаҗәеп баш киемен мин гомеремдә тәүге кат күрдем. Дәдәй минем шлемына мөкиббән китүемне чамалады, ахры, аны чөйдән алып:

— Мә, апаем, син дә кызылармеец бул әле,— дип, башыма кидерде.

Шлем миңа үтә дә дәү иде, күзләремне, бөтен йөземне каплады.

— Сиңа бүләк итәм аны, ал.

— Кирәкми, миңа зур ул, күзләремне каплады, салдыр.

— Димәк, синең кызылармеец булып йөрисең килми?

— Бәләкәй бит әле мин, үскәч булырмын...

— Дөрес әйтәсең, һәрнәрсәнең үз вакыты бар. Телисеңме, диңгез бүләк итәм сиңа?

Диңгез сүзен гомеремдә тәүге кат ишетсәм дә: «Телим»,— дидем.

Дәдәй дәү фанер чемоданыннан зур әкәм-төкәмгә охшаган, өсте чәнти бармак юанлыгы кыска тупас чәнечкеләр белән капланган, кәүсәсе урыны-урыны белән аксыл-коңгырт, шулай ук аксыл-саргылт төстәге коштабак дәүлеге әкәмәт әйбер чыгарды. Аның янтыгында нечкә иреннәре җай гына өскә һәм аска кайтарылып торган, эченә кул бармаклары һич авырлыксыз керерлек, күз явын алырдай елык-елык килгән перламутр төстәге озынча авызы бар иде.

Матур да, шул ук вакытта шөкәтсез дә икән дәдәйнең диңгезе, дип уйладым мин.

— Мә, колагыңа куеп кара әле шуның авызын, нәрсә ишетерсең икән? — диде дәдәй.

Дәдәйнең бүләген теләр-теләмәс кулыма алдым. Ул шактый авыр иде. Сагаеп кына колагыма куйдым. Башта, дулкынланып, берни дә ишетмәдем, аннары еракта нәрсәдер шаулый төсле булды.

— Берәр нәрсә ишетәсеңме? — диде дәдәй, түземсезләнеп.

— Юк.

— Шаулау да ишетмисеңме?

— Нәрсәдер пышылдый сыман.

— Кабырчыкны колагыңа ныграк терәп, җүнләбрәк тыңла әле.

Мин ул әйткәнне үтәдем.

— Менә хәзер нәрсәнеңдер шаулавын ишетәм.

Дәдәй җанланды.

— Диңгез иңрәгәнне, җил искәнне, тау-тау дулкыннар шаулаганны ишетәсең син. Дикъкать беләнрәк тыңласаң, акчарлаклар тавышын да ишетерсең әле.

Мин аптырап:

— Нинди акчарлаклар? — дидем.

— Шуны да белмисеңме? Акчарлаклар — диңгез кошлары. Уйнаклап һавада очалар, казлар һәм үрдәкләр күк дулкыннар өстендә йөзәләр. Балыклар белән тукланалар.

— Каңгылдыйлармы, әллә бакылдыйлармы?

— Алар чыелдыйлар...

Күпме генә тырышып тыңласам да, кабырчык эченнән чыелдау тавышы ишетмәдем.

Ул көнне миңа гомеремдә тәүге кат диңгез һәм акчарлак төшенчәләре мәгълүм булды. Диңгез хәтеремә ямьсез шома перламутр авызның нечкә иреннәре ипле генә өскә һәм аска кайтарылган әкәм-төкәмне хәтерләтүче кабырчык булып уелды. Ә акчарлакны исә, ничек кенә тырышсам да, күз алдыма китерә алмадым. Алары минем өчен озак вакытлар серле булып калды. Акчарлакларны дәдәем чыелдыйлар диде бит. Ә безнең якларда каңгылдаучы, бакылдаучы, каркылдаучы, сайраучы, сызгыручы, кытаклаучы, гөрләүче, чыркылдаучы, гөпелдәүче, торкылдаучы, бытбылдаучы кошлар гына бар, ә чыелдаучы кошлар юк иде бит.

Дәдәйнең бүләгеннән соң мин диңгезләр, океаннар белән мавыктым. Планетабызның алтыдан биш өлешен каплаган су дәрьясына кагылышлы бөтен нәрсәләрне белергә, өйрәнергә омтылдым.

Кулыма диңгезләр турында язылган китап эләксә, һәрвакыт аерыла алмый укыдым, диңгезләргә озакка сузылган сәяхәтләргә бару турында хыялландым. Диңгезләр, океаннар белән танышу Жюль Вернның татар телендә чыккан «Серле утрау», «Сиксән мең километр су астыннан» дигән романнарыннан башланды. Аннары русчаны ипилек-тозлык өйрәнгәч, диңгезләр турында язылган башка китапларга күчтем. Дәдәй бүләк иткән кабырчык, алдымдагы юлыма әйдәүче маяк сыман, һәрвакыт күз алдымда өстәлемдә торды. Мин гомеремне диңгезләрне өйрәнүгә багышларга хыяллана идем. Әмма омтылышларым эшкә ашмады. Хыялларыма сугыш чик куйды. Мин дә илебез азатлыгы өчен көрәшүчеләр сафына бастым.

* * *

Чын диңгезне мин беренче тапкыр 1945 нче елда Польшаны фашист илбасарларыннан арындырганда, Гдыня шәһәре янында күрдем. Чите төрле чүп-чарлар белән шакшыланган, өстендә зур-зур нефть таплары, фашист солдатларының мәетләре йөзгән пычрак Балтыйк диңгезе иде ул. Ни гаҗәптер, бала чактан ук үзем тартылган су дәрьясы белән очрашу миндә бернинди дулкынлану да, хис-тойгылар да кузгатмады. Мин диңгезгә битараф калдым. Язгы күңелсез, тын, аяз сүрән көндә булды бу. Пычрак дулкыннар иренеп кенә яр комына тәгәрәделәр. Болганчык киңлек өстендә хәсрәтле төстә тын гына кара бүрекле ак кәүсәле кошлар уйнаклады. Мин янымдагы иптәшемнән, болар нинди кошлар, дип сорадым, ул, акчарлаклар, диде. Нәкъ шул чакта минем кинәт кенә диңгездән дә, акчарлаклардан да күңелем кайтты. Бәлки, бу диңгезнең үтә дә пычрак, акчарлакларның гап-гади килбәтсез кошлар булганнарын күрүемнән килгәндер, әйтә алмыйм.

* * *

Сугыштан соң, туган авылыма әйләнеп кайткач, мин өебездә кайчандыр дәдәй бүләк иткән серле «диңгез»не инде очратмадым. Аны күрше малайлары, урлап, мәктәпкә алып барганнар, мәктәп остаханәсендә аны, пычкы белән икегә ярып, шаулау серен «ачыклаганнар» булып чыкты.

Соңыннан, җәйләрен Кырымга яки Кавказга ял итәргә барган вакытларда, базарларда миңа малай чагымда дәдәй бүләк иткән диңгез кабырчыкларының ишләрен байтак очратырга һәм аларны колагыма куеп тыңлап карарга туры килде. Ләкин мин аларның берсендә дә дәдәй бүләк иткән кабырчыктагы шаулауны ишетмәдем.

Югалган әйбергә шундый ук алмаш табу мөмкин түгел, күрәсең. Алар тышкы килеш-килбәтләре белән бер-берләренә охшаган, бер-берләрен ике тамчы су кебек кабатлаган төсле була, ә җисемнәре туры килми. «Ялгышмагыз, мин башка!» —дип кычкырып торалар.

*Гурий Тавлин*

## Сугышта югалган солдатлар

Дан җырлары иҗат итегез
Сугышта югалган туганнар хакына.
Дошманнарга нәфрәт булып барсын бу җыр,
Нәфрәт булып.
Туганнарга рәхмәт булып калсын бу җыр,
Рәхмәт булып.

Дан җырлары иҗат итегез
Сугышта югалган солдатлар хакына.
Онытылмасыннар арабыздан китсәләр дә,
Кайсы илнең кайсы якларыннан,
Кайсы юлның кайсы чатларыннан
Үтсәләр дә.
Дан җырлары иҗат итегез
Билгесез югалган туганнар хакына.
Илбасарга зур кисәтү булсын бу җыр,
Зур кисәтү,
Чын дусларга юл күрсәтеп тусын бу җыр,
Юл күрсәтеп.

Дан җырлары иҗат итегез
Билгесез югалган солдатлар хакына.
Һәйкәл куегыз җирдәге бар бакчаларга,
Кайсы илнең кайсы диңгезендә,
Кайсы якның кайсы нигезендә
Ятсалар да.

Дан җырлары иҗат итегез
Мәңгегә югалган туганнар хакына.
Сугышларны җирдән мәңге кусын бу җыр,
Мәңге кусын.
Тынычлыкны җирдә раслау булсын бу җыр,
Раслау булсын.

Дан җырлары иҗат итегез
Мәңгегә югалган солдатлар хакына.
Алар үлеме безгә тормыш китергәнен
Бөтен илнең бөтен батырлары,
Бөтен чорның бөтен гасырлары
Хәтерләсен.

## Павел Апушев

Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Павел Апушев чәчәкле, җиләкле җәйнең бер көнендә, 1938 нче елның 18 нче июлендә, Питрәч районындагы Әлбәден авылында туган. Үз ягының хозур табигате аны бик яшьләй сихерли, шигъри җанлы итеп тәрбияли. Әтисенең Ватан сугышы кырларында һәлак булуы бу тойгыны тагын да көчәйтә. Әсәрләре район һәм өлкә газеталарында, журналларда басыла. Һәр әсәре туган ягы, аның кешеләре турында. Ул — ике китап авторы: шигырьләр һәм чәчмә әсәрләр яза.

### Оста куллар белән кагылсаң

Туган якларыма аяк бассам,
Күңелләрдә моңнар ага гел.
Һәр үләне, агачлары көйли,
Серен генә аның таба бел.

Каен туздан телгән тар тасмадан
Дымлы ирен сихри моң таба.
Әрәмәдә курай сузса берәү,
Дөнья үзе гүя таң кала.

Туган җирем, бар да аңлар мине,
Синең туфрагыңа табынсам.
Һәр тарафың әзер җыр сузарга,
Оста куллар белән кагылсаң.

### Онытылмый

Рәхәт салкын биреп тора июль киче,
Аланлыкта аңкый пешкән җиләк исе.
Чикерткәләр тынмас дәртле җырын суза,
Печәнчеләр кайтыр юл да шуннан уза.

Яшел алан гүя татлы шәраб сыга,
Шәраб үзе күренми, тик исе чыга.
Җир җиләге, йөз яшергән кызлар кебек,
Җиргә иелеп, тыйнак кына тора көлеп.

Кояш аны комач төскә манып киткән,
Менә-менә өзелергә вакыты җиткән.
Җиргә тиям-тиям диеп торганда ул,
Сыта күрмим дигән төсле орына кул.

Өч-дүрт җиләк өзү белән учың тула,
Сусыл җимеш ал иренгә килеп куна.
Бу ләззәттән ничек икән тел йотылмый!
Кыска гына шушы җәйләр онытылмый.

### Әнисе кебек якын

Көтмәгәндә афәт килсә,
Дәшә кеше: «Әни!» — ди.
Ә әнисе күптән үлгән,
Ул гүя аны белми.

Ник белмәсен, үзе күмгән
Газиз куллары белән.
Йөрәккә бит «әни» сүзе
Мәңге чыкмаска сеңгән.

Ул чынлыкта җиргә дәшә,
Дөньяга дәшә сөеп.
Бала туса, «әл-ли!» диеп,
Кайгыдан «Ә-ни!» диеп.

Кеше йөрәге түрендә
Бар икән әле тагын,—
Җир белән дөнья бар әле
Әнисе кебек якын.

## Күзләремә кереп барышым

Урманнарда, кызыл мәрҗән булып
Пешеп өлгерделәр баланнар.
Күзләремә кереп барам инде,
Сау булыгыз, җәйге аланнар.

Сау булыгыз, баллы юкәләрем,
Сау булыгыз, яшел камышлар.
Урылдылар кырда арышларым,
Көтә мине яңа танышлар.

Юк, бармыймын сары сагыш төяп,
Сары ягылса да талларга.
Йомыш белән керәм мин көзләргә,
Уңышларны гына барларга.

Сагынганны белеп, җәйләр тагын
Яшел олау белән килерләр.
Быелларым ләкин кире кайтмас
Кире кайтмас үткән гомерләр.

Урманнарда кошлар җыры тынган,
Ишетәм тик җилләр тавышын.
Яшел җәйләр белән саубуллашып,
Күзләремә кереп барышым.

*Павел Апушев*

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

## Май чабу

***Май чабу*** (Масленица) да бик борынгы заманнардан — мәҗүсилек чорыннан ук сакланып килгән бәйрәм. Икенче төрле аны «Кышны озату» дип тә атыйлар. Бу һич тә дини бәйрәм түгел, ә игенченең язгы эшкә күчә башлау чорын билгеләп үтү. Христиан чиркәве «Май чабу»ны, дини бәйрәмнәр арасына кертеп, үзенә җайлаштырган гына.

Май чабу атнасы ел саен, Олы көнгә бәйле рәвештә, төрлечә килә. Ул һәрвакыт Пасха алдыннан була торган 7 атналык олы уразага (великий пост) бер атна калгач башлана. Борынгы бабаларыбыз аны төрле йолалар белән үреп үткәргән. Соңыннан алар саламнан ясалган карачкы яндыру, корбан ашлары —

коймак, көлчә, күзикмәк пешерү, киенеп-ясанып йөрү кебек халыкның традицион гореф-гадәтләренә әверелгән. Май чабу күп гасырлар буена халыкның массакүләм күңел ачуы буларак үткәрелгән. Җигүле атларны бистәр, сөлгеләр, җиз кыңгырау-шөлдерләр белән бизәп йөрүләр, төрле мавыктыргыч кызыклы уеннар, урамда пешерелгән кайнар коймак, күмер кызуында кыздырылган ит, баллы-җимешле чәй белән сыйланулар, чаңгы яки чәнәшкә белән тау шуулар... Ә бит «Май чабу», күрше авыл агайларының үзара килешеп куюлары буенча, атна дәвамында әле берсендә, әле икенчесендә уза торган иде.

Атнаның һәр көне билгеле бер тәртип буенча бара. Мәсәлән, дүшәмбе — «бәйрәм каршылау көне». Балалар «Май чабу»ны кардан таулар өеп башлап җибәрә.

Май чабу атнасының символы — коймак. Дүшәмбедә һәр өйдә, гаиләнең үзенә генә билгеле рецептлары буенча, коймак пешерелә. Табадан беренче төшкән коймак, ата-аналар рухы өчен дип, ачык тәрәзәгә (форточкага) куела яки хәер итеп бирелә.

Сишәмбедә төрле кызыклы уеннар башлана.

Чәршәмбе — «тәмле тамаклар» көне. Кияүләр каенанада кунакта була.

Кече атна — бәйрәмнең иң кызган көне.

Татар атнасы көнне каенаналар кияүләренә кунакка бара. Атна кич (шимбә) — каен сеңелләр утырмага килә торган көн.

Атна көнне «Май чабу» бәйрәме белән саубуллашалар. Башка көннәрдәге гадәт-йолаларның урыннарын алыштырырга да мөмкин. Ә менә «саубуллашу» көнен башкалары белән бутап булмый. Бу көнне кардан өелгән тау өстендә салам тутырып эшләнгән карачкы-курчак яндырыла.

*Май чабу атнасында егетләр һәм кызлар танышып калырга тырыша.*

*Бу елны өйләнешкән парлар, кызлар такмак әйтеп торганда, таудан бергә шуып төшәргә тиеш.*

*Атна уртасыннан башлап, өйләнмәгән егетләр тауда чана шуа, гармуннар белән җигүле «тройка»да узышалар.*

*Май чабуда кар яуса, карабодай уңа.*

*Май чабу алдыннан килгән якшәмбедә көн бозылса, җәй көне гөмбә күп була.*

*Александр Филиппов*

## Песнәк

Бәхәсләшмим. Яз җырчысы дип сыерчыкларга сокланган, табигатьнең сайрар патшасы дип сандугачларны мактаган кешеләр белән бәхәсләшмим. Тик мин бүген нәфис каурыйлардан һәм гүзәл сайраулардан мәхрүм булган песнәкне мактыйм, шуны җырлыйм.

Сыерчыкларның канатлары да нәфис, сайраулары да гүзәл. Ләкин сыерчыклар сайрый торган апрель көннәренең түбәләрдән яуган тамчы яңгырлары да, урам буйлап бөтенесе бер якка чапкан көмеш гөрләвекләре дә бар.

Ә менә февральнең салкын бер иртәсендә тәрәзә рамыгызга килеп кунган песнәкнең нечкә аваз белән чыелдап куюын ишеткәч, сезнең күңелегездә быелгы беренче яз дәрте кузгалып китә. Әле бит сез бүген генә тәрәзәдәге боз абагалар аша айлар буе һаман бертөрле булулары белән күзләрегезне арытып бетергән кар көртләрен күзәтә идегез. Язга кадәр әле салкыннар да, бураннар да булачак. Ләкин шул тәрәзә рамыгыздагы песнәк тавышын ишеткән көннән соң, инде сездә быелгы яз дәрте сүнмәячәк.

Миңа калса, салкын февральдәге песнәк чыелдавы җылы апрельдәге сыерчык сайравыннан ягымлырак, чөнки песнәк яз дәртен бураннар арасыннан эзләп ала!

Сандугач — табигатьнең сайрар патшасы, ләкин салкын яңгырлар көн буе ялангач ботакларны тараган, кайчандыр эре чәчәкләр күтәреп торган гөл сабаклары соргылт кура гына булып калган көзге көннәрдә инде сандугачлар да тыналар. Аның каравы тәрәзә каршыгыздагы шәрә ботакта әле яңа гына авылга килгән каралы-сарылы шул песнәкне күргәч, сезнең күңелегез шатланып куя: «Табигать әле бөтенләй үк үлмәгән икән...»

Ә песнәк үз бәясен ничек кадерләп саклый белә! Ул бөтен кошлар безнең якларга кайткан яз һәм җәй көннәрендә кеше күзеннән аулак урман чытырманнары арасына кереп яшеренә. Әйдә, көз көне авылга кайтыр әле. Матурлар арасында ямьсез булып яшәгәнче, ямьсезләр арасында матур булып яшәвең мең артык!

* * *

Бәхәсләшмим. Яз җырчысы дип сыерчыкларга сокланган, табигатьнең сайрар патшасы дип сандугачларны мактаган кешеләр белән бәхәсләшмим. Тик мин бүген нәфис каурыйлардан һәм гүзәл сайраулардан мәхрүм булган песнәкне мактыйм, шуны җырлыйм...

*Гәрәй Рәхим*

## Ике яздан — матур китап

Дөресен әйтәм: Луиза Янсуар (фамилиясе — Шарова, псевдонимы — туган авылы Янсуардан) шигырьләре белән танышканнан бирле, күңелемдә яз исе, гөлләр исе, сөенеч хисләре. Һәм чын горурлыкның үзе дип әйтер идем: әйе, әйе, шигъриятебезнең киләчәге өчен, мең еллар буе тупланган рухи байлыгыбыз — сүз сәнгатебезнең дәвамчылары өчен! Алмаш үсә, яңалар килә һәм ниндиләре генә әле! Әле кайчан гына яшьләр дип, яше утыз тирәсендә булган, университет тәмамлаган, кайдадыр эшләп, инде китаплар чыгарган шагыйрьләрне атый идек — үзебез дә шулай булдык, ахрысы... Ә менә бүгенгедәй, инде мәктәптә уку чорында ук шигырьләре белән таныла алган, хәтта китап та чыгарган Энже, Гөлназ, Лиана, Сөмбелләр ул чакта ерак хыял иде әле. Дөресен әйткәндә, без (шәхсән, үземне әйтәм!) алар яшендә бик зәгыйфь, өйрәнчек әйберләр язучылар идек, дисәм, бүгенге кайбер бөекләребез үпкәләмәс микән? Чыннан да, соңгы ун ел эчендә яшьләрнең үсү, өлгерү халәте нык үсте, үзгәрде — тиз танылу, яшьтән үк китап чыгару заманы килде! Ә бу хәл, нигә дөресен әйтмәскә, шигырьдәге соңгы 20—30 ел эчендәге казанышлар, күп төрле талантлар тудырган югарылык, биеклек, кыскасы, бүгенге татар шигъриятенең шиксез зур эстетик тәрбия йогынтысы нәтиҗәсе бит! Моның өчен дә горурланырга буладыр безгә — инде олыгая барган шагыйрьләргә. Шәкертләр өчен, әле китаплары булмаса да, инде танылып барган сәләтле Гөлнур, Эльмира Җәлилова, Илгөлемнәр өчен...

Ә Луизабызга килгәндә... «Юлыктым мин шундый бер чәчәккә» дип, Туфан сүзләрен кабатласам да урынлыдыр: ул, мөгаен, феноменаль бер күренештер. Гасыр башында, өлгергән шагыйрь булып, 16—17 яшендә китап чыгарган рус шагыйрәләре булган. Әйтик, М. Цветаева кебек, Луиза да, минем карашка, нәкъ шулай. Моннан ике ел элек Язучылар берлегендә узган яшь язучылар конференциясендә нәниләр өчен шигырьләре белән катнашкан бала ике ел эчендә өр-яңа шигъри дөньясы белән зур үсештә күренә. Бары ике ел, ике яз тудырган бу шигырьләрне. Әмма чын шигъри рух очышы, галәм белән аңлаша алырлык кыюлык омтылышы, шигъри тою, хис, моң, көч, тел-сурәт камиллеге, керәшен сүз стихиясе белән чын гадилек, җырга хас яктылык, кыскасы, чын шагыйрьләрчә өлгергәнлек аларда... Яшь шагыйрә зур юл башында. Нинди язмыш көтә аны?

Шушы биеклекне саклый алырмы, шигъри күкнең яңа катларына ашармы? Канатлары талмасмы? «Маңгаеннан үпкән фәрештәләр» гөнаһсыз яшьлегенә генә юлдаш булмасмы аның — киләчәктә нинди көчләр саклар бу шагыйрь яланны?

Сөенәм дә, борчылып уйланам да мин бүген яшь шагыйрә турында. Хәерле юл сиңа, биниһая зур очышлар язсын, бихисап күп шигъри язлар насыйп булсын сиңа, сеңелем Луиза! Амин! — диик.

*Рәдиф Гаташ*

## Ике канат

Ике яктан каплый ике канат —
Язмышыма җил дә кагылмас.
Мөлдерәмә тулган бәхетемә
Янар көчләр, затлар табылмас.

Ике яктан саклый ике канат
Искән җилдән, салкын яңгырдан.
Ә үзләрен күпме сынап сыккан,
Күпме яшен утта яндырган.

Ике яктан яклый ике канат,
Күңелемә иман иңдереп.
Ниләр белән түләп кайтарырмын?
Ни булса да, булыр ким кебек.
Ике яктан каплый ике канат —
Фәрештәдәй яши мине саклап.

## Китә калсам

Китә калсам,
Туган якларыма
Җылы туфрак дәшеп кайтара.
Ниндидер моң
Күңел кылын чиертә,
Таныш бер моң җанда чайпала.
…Ялан тәпи
Баскан эзләр калган
Изге туфрак дәшеп кайтара.

*Луиза Янсуар*

## ***Март***

«Март ае — шарт ае» яки «Март, мартның көне шарт» кебек сынамышларны һәркайсыгызның ишеткәне бардыр. Әйе, мартта салкыннан агачлар, өй бүрәнәләре шартлый; я булмаса язгы ташулар алдыннан елгаларда, шартлап, бозлар ярыла. Әмма монда «шарт» сүзенең әле тагын бер мәгънәсе бар: алдагы һавалар торышын һәм игенчелек хәлләрен билгеләү өчен, халык календаренда март аеның ничек килүе әһәмиятле шарт итеп санала. Озак вакытлар яңа елның беренче ае булып йөргән, яз фасылын башлап җибәрә торган бу ай (һәм бигрәк тә аның тәүге көне) турында сынамышларның аеруча күп булуы, әлбәттә, бик табигый хәл (көннәр иске стиль белән):

Март берендә аяз булса — аяз булыр бөтен яз.

Әгәр беренче мартта тәрәзәләргә боз катса, бу елны кыяр уңар.

Беренче мартта кояшлы көн булып, һава тын булса, яз яхшы булыр, җәй буенча һава яхшы булып, һәртөрле ашлыклар уңар.

Беренче мартта көн җылы булса, бөтен җәй җилле булыр.

Беренче мартта урамда су күренсә, язгы ташуда су күп килер.

Әгәр беренче мартта җылы булып, тамчы тамса, кар тиз китәр, бөтен җәй җылы булыр.

Беренче мартта төшкә кадәр тын булып, төштән соң җил чыкса, шул җәйнең әүвәлге яртысы яхшы булыр.

Беренче мартта буран карабодайга килешер.

Беренче мартта җил кыйбладан яисә көнбатыштан булса, ашлык яхшы булыр. Әгәр көнчыгыштан яки төньягыннан җил булса, ашлык начар булыр.

Беренче мартта кайсы яктан җил булса, бөтен җәй шулай булыр.

Март берендә аязлык — җәй көне кыярга туклык.

Март башында тамчы тамса, җәй яхшы килә.

Март башында чыпчык эчәрлек су булса, ел яхшы булыр.

Мартның әүвәлге якшәмбесендә җылы булса, ашлык уңар; кар яуса, чикләвек, колмак уңар.

Мартның әүвәлге шимбәсендә кар яуса, чикләвек һәм карабодай уңар.

Егерме бишенче мартта яңгыр булса, арыш игене уңар.

Мартта кар өстендәге салам карга эреп керсә, бер айдан кар китәр.

Мартта яуган кар — бакча җимешенә бик ярар.

Мартта кояш карны нык кыздырып эретә башласа: «Быел кар астына ут иртә керде, иген яхшы булыр»,— диләр.

*Александр Филиппов*

## Мишә буйлап — Иделгә

*(Повестьтан өзек)*

Ватан кайдан башлана? Бу сорау белән без еш очрашабыз. Бер караганда, гади, икенче карасаң, киң масштаблы сорау бу.

Ватан ул әниең тирбәткән бишектән, тәпи атлап киткән җиреңнән, туган йорт бусагасыннан башлана да илебезнең ерак чакрымнары белән тоташа.

Бөек Ватан сугышы башланган беренче көннәрдә үк Брест крепостенда тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән Советлар Союзы Герое, татар халкының бөек улы, якташыбыз Петр Михайлович Гаврилов өчен исә Ватан Питрәч районының Әлбәден авылыннан башлана. Биредә аның балалык һәм яшьлек еллары узган, коңгырт күзләре зур көрәш юлларына шушыннан төбәлгән.

* * *

Бу йортта икенче малай булып туды Питер. Санук түти өчен малайларның икесе дә кадерле. Беренче балаларының малай булуын Аллага ялварып теләгәннәр иде алар. Малай тугач, бәби ашы белән килгән һәр кешегә:

— Күктән теләгәнне җирдән бирде Ходай, малай бит, малай! — диделәр ата белән ана, куанычларын эчләрендә тота алмыйча.

Ничек куанмасыннар. Малай — җир, ә җир — икмәк, тормыш үзе дигән сүз ич. Малайга Сергей дип исем бирделәр, чукындырдылар һәм, чиркәүдән алып кайткан көнне үк, бәләкәч хөрмәтенә кечкенә мәҗлес үткәрделәр. Башта тәпи басуын, аннары тел чыгуын зарыгып көттеләр. Инде йөгереп йөрсә дә, малайга тел чыкмады, ишетмәде.

* * *

Сергей өч яшьтә чакта, Михайла дәдәй дөньядан китеп барды. Ирен күмгәндә, Санук түтинең карынында җиде айлык баласы тибә иде. Сагышлы ананың бар өмете туачак балага күчте. Малай булырмы ул, кызмы — монысы артык кызыксындырмады аны. Күңел түрендә, сискәндереп бер генә иман йөрде: кем генә булса да, саулыгы белән тусын, саны тигез булсын, и Ходаем, үзең ташлама.

Дөньяга көр аваз салып, йомры гына малай туды. Санук түти Ходайдан малай өчен тел һәм тәүфыйк сорады. Кендек әбисеннән түр почмактагы иконаны сорап алды. Андагы Изге Кыз Мария сурәтен иреннәренә тидерде. Сурәт өстенә аның күз яшьләре тәгәрәде.

Малайга Питер дип исем бирделәр. Печән өсте иде бу. Икенче көнне үк күрше-күлән, туган-ыру Санук түтигә бәби ашы китерә башлады, һәркем үз хәленчә: кайберәүләр майлы кабартма, арыш көлчәсе белән каймак, сөтле аш, кайсылары, урман җимеше шифалырак дип, җир җиләге алып килде.

Өч-дүрт көннән Санук түти аякка басты, вак-төяк эшләрне үзе караштыра башлады. Су китерү кебек авыр эшләрдә күрше кызлары булышты.

Яшь ярымнан малайның теле ачылды. «Әннә» сүзен ишетүгә, малайны күтәреп, Мәкчем дәдәйләргә йөгереп керде ана. Өйдә Мәкчем дәдәйнең хатыны Үлүн түти үзе генә иде. Бусагада ук Санук түтинең шатлыклы тавышы яңгырады:

— Малаемның теле бар, Питеремнең теле бар!

Нәкъ шуны раслагандай, малай телгә килде: «Әннә, мәммә, бу-бу».

— Тфү-тфү, күз тимәсен, сандугачлар алып килгәндер лә моңа телне! — дип, Үлүн түти малайны үзенә алды, ике кулыннан тотып тезләренә бастырды. Малай ят кулда һич ятсынмады, баягы сүзләрен тагын да ачыграк итеп кабатлады.

* * *

Пидырларның өе дә Питерләрнекеннән зур түгел. Әмма аларда күңеллерәк. Кич җиттеме, асылмалы җиделе лампа яна. Йоклар алдыннан ашау өчен мич көленә күмелгән бәрәңгеләрнең тәмле исе таралган. Сәке йөзлегендә Пидырның этисе Мәкчем дәдәй чабата ясый. Ян сәкедә кызлар сүс эрли. Әниләре Үлүн түти кулдан сугып әзерләнгән алачадан күлмәк тегә. Идәнгә җәелгән палас өстенә тагын берничә күрше малайлары сырышкан. Алар, Мәкчем дәдәләренең тылсымлы әкиятләрен тыңлар өчен, бирегә һәр көн җыела.

Питер бүген әкият тыңларга дип кенә кермәде. Мәкчем дәдәсе кулындагы бәләкәй чабата аның өчен тукыла. Кызыклы әкиятнең ахырын түземсезләнеп көткән кебек, матур чабатаның да калыптан тизрәк төшүен көтеп зарыга ул.

Мәкчем дәдәй эш көенә салмак кына сөйли дә сөйли. Каян килде икән соң аңа бу кадәр әкият һәм хәтер? Тәмам сихерләнеп өлгергән малайлар үзләрен әкият герое итеп хис итә башлый: канатлы атларга атланып, диңгезләр аша очалар, ат тоягы көярлек кызган ком тауларын үтәләр, аждаһаны, дию пәриләрен җиңеп, кешеләргә бәхет яулап бирәләр. Кешеләрне афәттән, ярлылыктан фәкать курка белмәү, шәфкатьле булу гына коткара икән.

Малайлар йокымсырый башласа, Мәкчем дәдәй тавышын күтәрә төшә яисә җанлырак сөйләмгә күчә. Кешеләрне авызына каратып сөйли алудан ул чиксез ләззәт таба. Чөнки әкиятләргә ул үз фикерләрен куша, әкият геройларына үзе хыял иткән яхшы сыйфатларны да бик юмарт өсти белә.

Күпмедер вакыт үткәч, Мәкчем дәдәй чабатасын сәке өстенә куя да:

— Хәзер, малайлар, бер генә минут,— ди. Малайларның күзләре, гадәт буенча, мич авызына юнәлә. Мәкчем дәдәй исә, зур таба алып, көлгә күмелгән кайнар бәрәңгеләрне чүпли башлый. Аннары әкият тыңлаучы яшь дуслары алдына йодрык кадәрле берәр бәрәңге тезеп чыга, тоз куя.

Башкаларга ничектер, ә менә Питергә әкияттәге яхшы геройлардан да игелеклерәк булып күренә бу вакытта Мәкчем дәдәсе. Аның күңеле түрендә зур үскәч, мин дә Мәкчем дәдәй кебек булыр идем, кешеләргә гел изгелек кылыр идем, дигән иман урнаша. Тиз, әкияттәге сыман бик тиз үсәсе килә аның.

* * *

Балачакның кабатланмас сәер гадәтләре була. Ул кемне яратса, шуңа охшарга, нәрсәгә сокланса, шуны үз куллары белән эшләргә хыяллана. Күп чакта әкияттәге тылсым да тиздән тормышка ашачак якындагы чынбарлык булып тоела аңа.

Мәкчем дәдәсе тукып биргән чабаталар Питернең исен-акылын ала. Ул яңа чабаталарны киярgә ашыкмый. Башта чөйгә элеп тота — иптәшләрен сокландыра. Аннары өй эчендә генә киеп йөри, ишегалдына чыга. Күзе тәмам ияләшеп беткәч, соклану кайнарлыгы сүрелә төшкәч кенә, урамга киеп чыгарга җөрьәт итә. Мондый чакларда аның өчен Мәкчем дәдәсе төсле матур чабата ясый белүчедән дә өстен кеше юк дөньяда. Ул үзен җиткән егет итеп күз алдына китерә һәм Мәкчем дәдәсе урынына куеп карый.

* * *

Урамнарда инде кар бетте. Урман буйларында гына кулъяулыгы-кулъяулыгы ак урыннар күренгәли. Апрель җиле аларны да комсызланып ашый, йота бара. Мишә елгасы үз урынына кайта башлады. Ерганаклардагы болганчык сулар, агудан туктап, ялга талды. Бүген беренче мәртәбә күк күкрәде. Питер белән Пидыр, сүз куешкандай, өйләреннән берьюлы атылып чыктылар да яшел чирәм борынлый башлаган җиргә ятып аунарга,

Тәннәр сырхаусыз булсын,
Билләр сызлаусыз булсын,—

дип, берсеннән-берсе уздырып такмакларга тотындылар. Беренче күкрәү вакытында җиргә ятып аунасаң, тән сырхауламый, урак урганда, бил сызламый дигән йола буенча, аларны әниләре шулай өйрәтеп чыгарган иде.

* * *

Иртәгә якшәмбе көн — Пасха бәйрәме. Әлбәденнең олысы-кечесе шуңа әзерләнә. Ирләр каралты тирәсен тәртипкә китерә, мичкә ягар өчен запас утын әзерләп куя. Бер атна буе барачак Пасха көннәрендә балта тавышы чыгарырга ярамый, диләр. Хатын-кызлар өй бизи, пешкән йомыркаларны кызылга буйыйлар, иртәгә бала-чага, өй саен йөреп, кызыл күкәй җыячак.

Санук түти дә йоладан читтә калмады. Питер алып кайткан чыршы ботакларын матурлап кисте, төсле кәгазьләрдән чуклар ясап, ылысларга бәйләде. Аларны стенага һәм тәрәзә төпләренә урнаштырды.

— Әни, безнең кызыл күкәйләр буламы? — дип сорады Питер.

— Булыр, улым, булыр,— диде ана, малайның башыннан сыйпап. Мондый сүзне әйтү аңа бик куанычлы иде.

Санук түтинең дүрт тавыгы бар. Аларның да икесе генә йомырка сала башлады. Олы бәйрәм хакына дип, ул шуларны балаларына күрсәтмичә генә җыйган иде.

Санук түти сак кына сәке астына иелде, аннан өстенә иске алъяпкыч япкан бәләкәй кәрзин алды. Берәмләп саный-саный, өстәлгә ап-ак йомыркалар тезәргә тотынды.

— Унсигез,— диде ул, соңгысын тотып,— ике дистәгә икәү генә тулмаган.

Әнисенең соңгы сүзләре Питергә кызыклы да, шатлыклы да булып тоелды.

Питер өйләре каршында бәбкәләр көтеп утыручы Пидыр янына килде дә:

— Безнең дә күкәйләр бар, ике дистәгә икәү генә тулмаган! — дип сикергәләргә кереште. Питернең куанычы шул минутта ук Пидырга да күчеп өлгерде. Алар, шул сүзләрне икәүләп көйли-көйли, Пидырның өйләренә килеп керделәр.

Өйдә Үлүн түти үзе генә иде. Ул, малайларга әллә ни игътибар итмичә, күвәшнәгә камыр изә бирде. Пидыр, аның янына килеп, колагына ук: «Питерләрнең дә күкәйләре бар, ике дистәгә икәү генә тулмаган!» — диде.

— Җараган, җакшы булган,— диде Үлүн түти. Аның эше төгәлләнгән иде бугай, икмәк калагын күвәшнәдән алды, пычакның үтмәс ягы белән, калакка сыланган камырларны кырып төшерде, зур агач табактагы җылымса суга тыгып чайкады да коры тастымалга сөртеп, казан өстенә куйды. Аннары ак эскәтер белән күвәшнәнең авызын бәйләде һәм аны җылы мич башына әчетергә куйды.

— Килегез әле, тыңлагыз,— дип, малайларны янына дәште ул һәм, дымлы кулларын камыр басканда гына бәйли торган алача алъяпкычы итәгенә сөртә-сөртә, сүзен дәвам итте.

— Мин сезгә бер нәстә сөйлием.

Үлүн түти дә ире Мәкчем дәдәй кебек хикәяләр сөйләргә ярата. Ләкин ул сөйләгәннәр дөньяви хәлләр түгел, дини уйдырмалар була. Мәкчем дәдәй аның теләсә нәрсәгә ихлас ышанып сөйләвен, беркатлылыгын өнәп бетерми. «Җитәр сәнә, җук-бар белән балалар башын катырма!» — дип, җиңел генә шелтәләп тә ала.

Мәкчем дәдәй хәзер өйдә юк. Үлүн түтигә сөйләргә бик уңай вакыт.

— Бүген Пасха киче, белеп торыгыз,— дип башлап китте ул, сәке йөзлегенә утырып,— төнге сәгать уникедә, төн уртасында, күк кабагы ачыла.

— Ничек ачыла?

— Кайда ачыла?

— Казер сөйлием. Бүген ярты төндә кояш баешы җагында күк чите җактырырга тиеш. Ул җазыксыз кешеләргә генә күренә, ди. Сезнең җазык жук, сезгә күренер. Ул бик тиз җактыра да бетә икән. Менә шул чакта Ходайдан ни сорасаң, шуны бирә, ди. Байлык сорасаң — байлык, саулык сорасаң — саулык. Анда күп сүз әйтергә өлгермисең. Шуңа күрә: «И Ходаем, саулык бир, байлык бир»,— дип әйтеп калырга кирәк.

* * *

Ямьле Мишә! Мәрхәмәтле Мишә! Көн-төн агасың да агасың. Юлыңда очраган барлык чишмәләрне тиңең итеп, үзеңә кушасың, киңәясең, зураясың, куәтләнәсең. Борылмалы юллар үтеп, мул сулы елгаларга барып чыгасың. Питерне дә таныйсың бит син. Әнисеннән туган көнне үк йомшак саф суың аның иреннәрен чылатты. Син аның аерылгысыз якынына, туендыручысына әверелдең, эссе көннәрдә кочагыңда йөздереп иркәләдең.

Кодрәтле Мишә! Иярт син аны йөгерек дулкыннарыңа, үзеңнән калдырма. Гел алга барырга, каршылыкларны җиңеп чыгарга өйрәт. Син аны саф күңелле, яхшы кешеләр арасына алып бар.

Әнә шундый изге ният белән ул Мишә елгасы буйлап китте. Сул ягыннан аны Мишә дулкыннары, уң ягыннан таулар озата барды. Әлбәден дә, Нурма авылы да артта калды. Монда калырга ярамый. Тотып алулары бар. Ерактарак берәр авыл бардыр әле. Бай авыл. Мишә аръягында авыллар күп ич. Пидыр белән бакчадагы усак башына менгән көнне үзе күрде ул аларны. Кайда гына барып урнашса да, әнисе белән Сергей дәдәсен, якын дусларын, туган авылы Әлбәденен онытмас ул!

Питергә Сәләнгеш чиркәве каршындагы мәктәпкә йөреп укырга туры килмәде. Ул сабакка йөри башлаганда, Әлбәденнең үзендә керәшен мәктәбе ачылган иде инде. Анда беренче укытучы булып, Кәвәл авылыннан Табагачов килде. Дин сабагы алырга гына чиркәүгә баралар иде.

Табагачов беренче карашка усал күренсә дә, ихтирамга лаек иде. Ул дәресләрдә балаларны тылсымлы фән дөньясында йөздерә, тарихны җанлы һәм мавыктыргыч итеп, бирелеп сөйли. Дәрестән соң да балалар аннан аерылып китәргә теләми.

Питердә онытылмас бер хатирә саклана. Икенче сыйныфта укыганда, Рождество бәйрәме алдыннан мәктәпкә Казаннан керәшен шкулларының башлыгы поп Тимофей әти килде. Табагачов аңа исемлек язылган бер бит кәгазь бирде. Тимофей әти исемлек буенча укучыларны үз янына чакыра һәм юкарак кына берәр китап, дәфтәр бүләк итә башлады. Исемлектә Питер дә бар иде.

* * *

Сишәмбе көнне Питрәчтә зур базар була. Әлбәдендә атна арасындагы көн исемнәре дә базарлар белән бәйләнешле: атна арты, Питрәч базары, Казы базары, кече атна, татар атнасы, мунча киче, атна көн.

Питер үзе дә иртәгә Питрәч базары көне икәнен белә иде. Кулында акча булмаса да, базарга менеп, сату-алу эшләре белән килгән авылдашларын күрәсе, алар аркылы өйдәгеләрнең хәлләрен сорашасы килә иде. Ә менә шул чакта кулында акча да йөрсә, нинди күңелле булачак!

...Филимон бай Питрәч авылының нәкъ үзәгендә яши иде. Алар урам якка дүрт тәрәзә караган, асты таштан, өсте агачтан салынган ике катлы матур йорт янында туктады.

— Филимон бай өе менә шушы инде,— диде Степан агай. Питер урам яктан икенче катка күтәрелә торган култыксалы биек баскычка исе китеп карап торды.

Кибет дигәне зур таш кладовой иде. Тимер ишек төбендә берничә ир-ат басып тора. Сөйләшеп торуларыннан аларның да эш хакы алырга килүләре аңлашыла.

Менә ишек ачылып китте. Эчтән урта буйлы, өстенә зәңгәр костюм, яшел чалбар, аягына ялтыравыклы хром итекләр, башына күн козыреклы картуз кигән Филимон бай килеп чыкты. Чиста итеп кырынган таза йөзеннән һәм кырыслык яшеренгән үткен күзләреннән нәрсәгәдер ризасызлык чаткылары сизелеп тора.

— Такта яручылар, беренче керегез, Степан, син дә шул ук чиратка! — Филимонның күзләре җигүле атларга һәм ат тирәсендә кайнашучы яшьрәк ирләргә төште.— Ә калганнар үз чиратыгыз белән...

* * *

Степан агай төшке аштан соң Маруся белән Питергә кунакларны җиләккә алып барырга рөхсәт бирде. Ир балаларны мөкиббән китеп ярата ул. Үзләренең малайлары булмаганга, мөгаен. Маруся аларның бердәнбер балалары иде.

Маруся җиләккә барырга поп кызы Таняны да чакырып килде.

— Иптәшең Федяга да кыз таптым,— диде ул Питергә пышылдап кына. Үзе күңелле генә кеткелдәп көлеп алды.

Ә Сергейның телсез һәм чукрак икәнен ул инде белеп өлгергән иде.

Алар күпердән чыктылар да болын буйлап урман кашына киттеләр. Малайлар юлда ук үзләренә шөгыль тапты. Пидырның үткен пәкесе белән тал кисеп, өч җәя һәм өч ук ясадылар һәм, барган уңайга, ату ярышы башлап җибәрделәр. Маруся белән Таня сызгырып очкан укларны куып китәләр, эзләп табалар да егетләргә китереп бирәләр.

Бераздан ук ату туйдырды малайларны. Әрәмәгә җиткәч, юанрак тал кисеп, кайрысыннан быргы ясадылар. Быргы очына сыбызгы эшләп куйдылар. Быргыдан чыккан калын тавыш әрәмәне яңгыратып җибәрде.

— Безгә дә ясагыз, безгә дә! — диеште кызлар.

— Кызлар өчен матур түгел бу,— диде Питер,— хәзер курай ясыйбыз. Сабак эче куыш аю көпшәсе кисеп, курай ясадылар. Курай тавышы нәфис тә, моңлы да иде. Малайлар кызларга да берәр курай ясап бирде.

Питер белән Пидырның табигать кочагында, иркендә калгач, җырлап җибәрә торган гадәтләре бар. Озын көйле никрут җырларын яратып җырлый алар. Курай уйнаудан туктап, малайлар җырга күчте.

Мунчаларга әле кемнәр яккан,
Һаваларга оча очкыны.
Туып үскән илдән әй аерылгач,
Елларга тиң була өч көне.

Татарча сүзләр аңлашылмаса да, көй ошады кызларга.

— Тагын, тагын! — дип кыстадылар.

— Без солдат җыры җырлыйбыз, аны җырлаганда, барлык кешеләр дә кочаклашып барырга тиеш,— диде Питер,— әйдәгез бергә.

Кызлар, бер-берсенә карап, көлешеп алдылар, нидер пышылдаштылар. Аннары Маруся Питерне, Таня Пидырны килеп култыклады. Сергейны малайлар үз араларына керттеләр дә «Алмагачы» көенә күчтеләр:

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз.

— Чират сезгә! — диде Питер кызларга. Кызлар да ялындырып тормады, «Авыл такмаклары»н җырлап җибәрделәр. Әлбәдендәге рус балалары да җырлый торган җырлар иде алар.

— Беләсезме, егетләр,— диде Таня,— сез безгә татар җырларын өйрәтегез, ә без сезгә рус җырларын... Минем калын җырлар дәфтәрем бар.

Пидыр татарча җырлар язып килүне үз өстенә алды. Мәкчем дәдәй белән Үлүн түтидә ниндиләре генә юк халык җырларының.

Урман кашы бик юмарт каршылады яшьләрне. Туйганчы ашаганнан соң да, тырыслар һәм бокаллар бик тиз тулды. Малайлар кайту ягын кайгырта башлагач та, кызларның кузгалыр исәпләре күренмәде.

— Качышлы уйныйк,— диде Таня,— күп кеше белән кызык була ул.

Качышлы уены да арыта төште аларны. Ләкин уен дәрте сүрелмәде. Кайтканда да, җиләкләрен куеп, әле куыш-тотыш, әле әйлән-бәйлән уйнап алдылар.

— Акыллы егетләр белән уйнау күңелле,— диде Таня,— безнең урамдагылар усаллар шул.

— Безнең Пырнай малайлары белән ничек сугышканны белмиләр шул болар,— дип Пидырга ишарәләде Питер.

— Һәй, ташлары булмаса, без аларны чүпкә дә куймыйбыз!

Степан дәдәйләргә кайткач, яшьләр туйганчы катык эчте. Степан агай Сергейга бер чиләк он салынган төенчек әзерләп куйган иде.

— Икегезгә авыр булмас әле,— диде ул, малайларның кесәләренә берәр телем икмәк тыгып. Питернең кибеттән алган күчтәнәчләренә дә урын табылды. Питер, Маруся һәм Таня кунакларны үр менгәнче озата бардылар.

* * *

Кешенең үткәне белән киләчәге, көн һәм төн, кыш һәм җәй алмашынган төсле, гел үзгәрешләрдән тора. Күңел күге дә шулай. Кояшы, ае гына түгел, болыты, яшьнәү-күкрәүләре дә бар ич күк йөзенең. Питернең яшь күңелен бер көндә әллә ничә тойгы иләсләндерә. Сулагай Антон шәһәргә ымсындырып киткәч, Питер үзен ике ут арасында итеп тоя башлады. Казан! Әле күзгә күренмәгән шәһәр аның хыялында гел якты, күркәм булып гәүдәләнә. Питрәч исә саран гына елмайган кояшы, салмак җилләре белән көннән-көн тоныклана, өмет ярларыннан артка таба шуыша бара. Питергә төннәрен буталчык төшләр керә. Кайсы иртәләрдә сөенеп, кайсыларында куркынып уяна. Төшендәге ләззәтләрдән арынасы килмичә, уянгач та күзләрен йомып ята, күңелле төшнең дәвам итүен тели. Куркынып уянса, тизрәк сикереп тора. Әле ярый төш кенә булган дип сөенеп куя.

Икеле-микеле уйлар белән йөргәндә, Питергә җил көтмәгән яктан китереп бәрде. Василийны да сугышка алдылар. Өлкән тегермәнче итеп гыж-гыж йөткерә торган бер чирләшкә картны куйдылар. Вакчыл һәм гасабилы карт Питернең тегермәнгә кереп йөрүен дә өнәми башлады. Питернең «китәргәме-китмәскәме» дип тирбәлеп торган үлчәү тәлинкәләре кинәт бер якка басты да куйды. «Китәргә» дигән якка.

Хәзер Питернең бар өмете Сулагай Антонда иде, һәр кич саен, ике күзен дүрт итеп, Казан юлын күзәтә, атларның кайтуын зарыгып көтә.

Март урталары. Кар катламы, челтәрләнеп, көннән-көн юкара. Түбәләрдән тамган тамчылардан ишегалдына, капка төпләренә сулар җыела. Күктә язның беренче хәбәрчеләре — кара каргалар төркеме күренә. Көн кичкә авышкач, җир өстенә салкынлык җәелә, аяк астын катыра башлый. Капка төбенә чыксаң, ерактан ук чана табаны шыгырдаган тавышлар ишетелә.

Казан атларын Питер әллә кайдан танып ала. Аларның чана табаннары үзләренә бер көй чыгара.

Бүген дә Сулагай Антонның күк аргамагы беренче иде. Питер, ат чабып килгән уңайга, чанага сикерде. Антон дәдәсе янына тезләнде.

Ул атчыларга он капчыклары төяште, атларын тугарышты, камыт-сбруйларын өйалдына кертеп урнаштырды. Көчкә таянып килгән яшүсмергә Антон дәдәсе сокланып карап торды.

* * *

Тегермән өендә Антон Питер белән җитди сөйләшүгә күчте. Китәргә дигән уен белгәч, янчыгыннан бер сум акча чыгарып бирде, аның эшчеләрдән җыелган булуын әйтте.

— Иртәгә үк яшь язуы алырга кирәк,— диде,— күрәсеңме, эшчеләрнең нинди халык икәнен, үз араларына киләчәк кешегә алдан ук ярдәм кулы сузалар. Эшчеләр арасында югалмассың, энекәш.

Таң беленер-беленмәстә атчылар Варвара түтиләрнең тәрәзәсен шакыды. Шуны гына көтеп яткан Питер өлгер генә сикереп торды. Өс-башына киенде.

Кашка күтәрелгәнче, атлар адымлап барды, аннары юртып киттеләр. Салкынча һава сулышны киңәйтә, башны җиңеләйтә, уйлар сине нindидер сихри дөньяга чакыра.

Питрәч — Казан юлы. Алда таныш булмаган авыллар каршылый, күңелне ымсындырып зур шәһәр көтә. Артта сыек зәңгәр булып күренгән карлы кырлар кала. Әлбәден кала. Питрәч кала. Аның дусты һәм яшьтәше Маруся кала. Юк, ул тагын әйләнеп кайтыр туган якларына, дуслары һәм туганнары янына. Кичер син аны, Маруся, кичер, Варвара түти. Антон дәдәсе сезгә барысын да аңлатыр.

Барган саен, караңгылык артта кала, җирдә яңа көннең игелекле сәламе булып яктылык канат җәя. Талгын җил шифалы яз исе алып килә.

Питерне татлы уйлары үткән язларга, Мишә буйларына алып кайта. Быел да яз ямьле булыр. Әлбәден яшьләре Мишәдә бозлар акканын карарга җыелыр. Елга, ярларыннан ташып, аргы яктагы болыннарга

җәелер дә Пимәр тавы итәгенә барып җитәр. Егетләрнең, кызларның гармун, җыр тавышларын язгы ташу еракларга алып китәр.

Бер язда Питер Мәкчем дәдәсеннән:

— Бу бозлар кая чаклы ага, Мишә берәр җирдә туктыймы? — дип сораган иде.

— Мишә — Камага, Кама — Иделгә, Идел диңгезгә коя,— дип җавап бирде Мәкчем дәдәсе.

Казанны бит мул сулы Идел буенда диләр. Идел ташуларын күрергә дә насыйп булыр әле Питергә!

*Павел Апушев*

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

***Апрель***

1 нче апрельдә су катса, 15 көнлек юлга чана белән чыгарга ярый.

Апрельнең алтысында аяз булса, җәй коры килер; болытлы булса, ашлык уңарга булыр.

Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшыга килә.

Апрель артык җылы булып китсә, май ае салкын, җилле булыр.

Кара каргалар ояга утырса, өч атнадан чәчүгә чыгарга кирәк.

Карлыгач килгәч, борчак чәчәргә кирәк.

## Бәрмәнчек

Олы көнгә бер атна калган якшәмбене бездә бәрмәнчек («верба» сүзеннән) бәйрәме, ә ике якшәмбе арасын бәрмәнчек атнасы диләр иде. Апрель — табигать уянгач, Зичә, Темкә инешләре буенда, әрәмәлекләрдә генә үсә торган талтирәкләр, бөре кабартып «көмеш чәчәк» ата торган вакыт. Бигрәк тә кызыл тал көмештәй песиләрен күп чыгара. Менә шуны бәрмәнчек диләр инде бездә. Без, малайлар, шул песиле нәзек ботакларны сындырып алып кайтып, үзебездән артканын күршеләргә өләшә идек. Ул шактый вакыт тәрәзә төпләрендә, кашагаларда өй бизәге булып торыр иде. Аны изгеләр сурәте каршына сулы банкага да утыртып куярлар иде.

Бәрмәнчеккә бәйле йолалар бик күптәннән килә. Аның турындагы риваятьләр дини әдәбият-чыганакларда сакланып калган. Борынгы яһүдләрдә үк ул Чатыр кору бәйрәме (төрле әдәбиятта куща, палатка дигән исем белән дә билгеле) буларак билгеләп үтелгән. Бу көнне барлык гаиләләр, өйләреннән чыгып, тал ботакларыннан чатыр корып җиде көн — бер атна дәвамында шунда яшәргә тиеш булалар. Бу исә яһүдләрнең хәзерге тору урыннарына күченеп яши башлауларына кадәр кырык ел буе Мисыр чүл-ләрендә сәяхәт итеп йөрү — иза чигү вакытларын искә алу өчен кануни кертелгән йола була. Аларда бу күңел ачу көне кырда һәм бакчаларда уңыш җыеп алынгач, халык эштән бушагач үткәрелгән. Мондый бәйрәм Җиргә Гайсә Коткаручы килгәнчегә кадәр үк зурлап үткәрелә торган булган. Чөнки Яхъя тәгъбир иткән «Изге Инҗил»нең җиденче бүлеге тулысы белән аның Чатыр кору бәйрәмендә катнашып, халыкка Алланың бөеклеге турында сөйләвенә багышланган. Соңыннан халыкның иза чигү елларын искә алу ниятеннән үткәрелә торган бу бәйрәм чиркәү кануннары тарафыннан изге бәйрәмнәр рәтенә кертелә һәм бездә ул Олы көнгә бер атна вакыт калганда билгеләп үтелә.

Төрле ырымнар бәрмәнчек белән бәйле. Аның песиләре им-дәва көченә ия исәпләнә. Аны ипи эченә салып пешергәннән соң малларга ашаталар. Әгәр дә кеше 9 песи-бөре ашаса, бизгәк белән авырмаган. Балага узмаган хатыннарга изгеләтелгән бәрмәнчек бөресе ашарга киңәш иткәннәр. Малларны яз көне беренче тапкыр көтүгә озынрак итеп сындырып алынган песиле тал чыбыгы белән куганнар. Аны юлда ташлап калдырырга ярамаган, ә өйгә алып кайтырга һәм абзар кыегына кадап куярга киңәш ителгән. Шу-лай эшләгәндә маллар исән-сау тора, барысы да өйгә кайта.

Изгеләндерелгән песиле тал ботагын бозлы яңгыр килгәндә ишегалдына ташласаң — боз явудан, җилгә каршы ыргытсаң — давылдан, янгыннан, кырга утыртсаң, уңышны саклый, дип уйлаганнар. Мондый мәҗүсилек ырымнары соңгы елларда кулланыштан чыгып бара.

*Александр Филиппов*

## Икенче Җәлил бит бу!

Бөек Ватан сугышы каһарманы, фашизм концлагеренда һәлак булган күренекле якташыбыз генерал Петр Георгиевич Новиков турында электән үк ишетеп белә идем. Әмма аның турында материаллар туплау, ничектер, һаман сузыла килде. Моны тизләтергә бер хәл этәргеч булды... Татарстан эзтабарларының

Севастопольдәге эзләнүләре турында газетабызда басылган хәбәрдә ялгышлык киткән икән. Анда: «Генерал П. Г. Новиков элеккеге Чаллы районында туган»,— дип язылган булган.

— Генерал П. Г. Новиков — керәшен татары. Ул элеккеге Биләр, хәзерге Чистай районының Югары Кондрата авылында туып үскән.

Материалларны җентекләп өйрәнгән саен, генерал П. Г. Новиков образы үзенең бөеклеге белән ачыла барды. Иң элек, чын мәгънәсендәге каһарманның Татарстан тарихы белән бәйле бер генә китапта да телгә алынмавы гаҗәпләндерде. Мөгаен, аның фашистлар әсирлегенә эләгүе моңа сәбәпче булгандыр, «Татарстан АССР тарихы»н төзүчеләр дә, үз хезмәтләренә, шундый «сатлык җан» исемен кертеп, китапны «пычратырга» уйламаганнардыр.

Ә бу каһарманның исеме Бөек Ватан сугышының иң күренекле геройлары белән янәшә торырга лаек бит! Профессор В. В. Иванов (ул озак еллар КПСС өлкә комитетында фән һәм югары уку йортлары бүлеге мөдире, Татарстан АССР мәгариф министры булып эшләде), төрле архивлар, шул исәптән СССР Дәүләт иминлеге комитеты чыганаклары белән элемтәгә кереп, генерал П. Г. Новиков турында шактый материал җыя һәм боларны КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеевка да күрсәтә. Фикрәт Әхмәтҗан улы аларны бик игътибар белән укып чыга.

— Син бит искиткеч язмышны ачыклагансың! Бу — икенче Муса Җәлил, икенче Дмитрий Карбышев бит! Мин СССР Верховный Советы Президиумына П. Г. Новиковка Советлар Союзы Герое исемен бирдерү турында үтенеч белән керәчәкмен,— ди ул, бик дулкынланып.

Әйткән вәгъдәсен беркайчан да җиргә салып таптамый торган Ф. Ә. Табеев моны һичшиксез үтәп чыгар иде. Әмма аның 1979 нчы елда СССРның Гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе булып Әфганстан Республикасына китүе генә моңа комачаулый. Шуннан соңгы еллардагы давыллы вакыйгалар һәм, ниһаять, СССРның таркалуы барысын да оныттыра. Данлы якташыбыз бары үзенең туган-тумачалары, авылдашлары өчен генә кадерле һәм якын булып кала. Нинди кызганыч хәл. Без геройларыбызны шулай мәңгегә онытырбызмы икән?

* * *

...Петр Новиков 1906 нчы елда ярлы крестьян гаиләсендә туа. Кечкенәдән белемгә омтылуы, кызыксынучан булуы аны Казанга алып килә. Ул биредә 2 нче ирләр гимназиясен, аннары Татар-башкорт кызыл командирлар мәктәбен тәмамлый. Соңрак М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә белемен күтәрә. 1936 нчы елда Испаниядә фашистлар баш күтәргәч, үз иреге белән, милли-азатлык хәрәкәтен якларга китә. Якташыбыз фашизм белән беренче тапкыр йөзгә-йөз шунда очраша, аның чын асылын шунда күрә. Испаниядәге кыюлыгы өчен Петр Новиков Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

— Бөек Ватан сугышы алдыннан аның Югары Кондратага самолет белән кайтып китүен өлкән буын кешеләре әле дә горурланып сөйли,— дип искә ала профессор В.В.Иванов.— Испания герое, яшь полковник авылдашлары белән бик җылы итеп сөйләшә, безнең илгә Көнбатыштан фашизм куркынычы янавын да әйтергә онытмый. Әтисе Георгий дәдәй белән әнисе Марфа түти улларын менә шулай соңгы тапкыр күреп кала. Берничә айдан инде ул яңадан сугыш ялкынына барып керә.

...Петр Новиков командалыгындагы 241 нче укчы полк 1941 нче елның 22 нче июнен Прут елгасы буендагы оборона ныгытмаларында каршы ала. Дошман аның позициясен көне-төне утка тота. Коры җирдән аңа танк армадалары ажгырып килсә, артиллерия өзлексез утка тотса, югарыдан кара тәреле авиация тынгылык бирми. Ике атна буе шулай дәвам итә. Әмма Новиков егетләре чигенми. Дошман уң һәм сул флангны өзеп бик эчкә үткәч һәм чолганышта калу куркынычы тугач кына, полк, командование әмере нигезендә, үз позицияләрен калдыра.

Ә аннары якташыбызны Одесса һәм Севастополь өчен тиңдәшсез көрәшләр көтә. Одесса оборонасы чорында Петр Новиков 2 нче кавалерия дивизиясе белән командалык итә. Ике тапкыр авыр яралана, әмма барыбер тылга китми. Аннары әлеге кавалерия берләшмәсен 109 нчы укчы дивизия итеп үзгәртәләр һәм аның командиры итеп яңадан яшь генерал П. Новиковны билгелиләр. Одесса өчен көрәшләрдәге батырлыгы өчен якташыбыз Ленин орденына лаек була. Генерал П. Новиковның Одесса һәм Севастополь оборонасы чорындагы каһарманлыгы Советлар Союзы Маршалы, ике тапкыр Советлар Союзы Герое Н. И. Крыловның «Беркайчан да сүрелмәс» дигән исемдәге мемуарлар китабында, генерал А. Ф. Хренов, И. А. Ласкин, А. И. Ковтун һәм башкаларның истәлекләрендә бик киң һәм җылы итеп сурәтләнгән. Якташыбыз турындагы юлларны горурланып укыйсың.

— Аның белән Одесса оборонасы башланган беренче көннәрдә очрашуымнан ук инде гаять җылы тәэсирләр калды. Тыныч табигатьле, аз сөйләшүчән бу хәрбигә һәрвакыт таянырга мөмкин булачагына, аның сынатмасына ышандым мин. Соңыннан беренче тәэсирләремнең һаман саен расланып торуына ышанырга туры килде,— дип искә ала Советлар Союзы Маршалы Н. И. Крылов.

Кырым ярымутравына төрле яктан куркыныч тугач, Верховный Башкомандующие Ставкасы 30 нчы сентябрьдә Одессаны калдырырга, аны саклаучы барлык көчләрне бирегә
күчерергә карар итә. 109 нчы укчы дивизия дә Севастопольгә чигенә. Кара диңгез буендагы куәтле хәрби портның
250 көнгә сузылган оборонасы шул көннән башлана. Якташыбызның фашистлар белән тиңдәшсез көрәштә яңа каһарманлыклары калкурак булып ачыла бирэдә. Хәзер герой-шәһәрнең бер урамы керәшен егете данлы генерал Петр Новиков исемен йөртүе, монда аңа һәйкәл куелуы, аның командалыгындагы дивизия сугышчылары батырлыгына багышлап, бирэдәге 12 нче йортта Дан музее ачылуы күп нәрсә турында сөйли. Герой-шәһәр Севастополь авыр чорда үзен саклаган каһарманнарны онытмый, алар истәлеген кадерләп саклый.

Генерал Петр Новиков, 109 нчы укчы дивизиягә командалык итү белән бергә, Севастополь оборона районының (СОР) беренче секторы коменданты итеп тә билгеләнә... 1942 нче елның июнь ахырына Севастопольне саклаучыларның хәле иң кыен чигенә җитә. Фашистлар шәһәрне диңгездән, коры җирдән һәм һавадан чолганышка ала. Нәтиҗәдә сугыш кирәк-яраклары, өстәмә көчләр, азык-төлек кертү мөмкинлеге бетә. Ә яралылар исә көннән-көн арта. 30 нчы июнь төнендә Севастополь оборонасы җитәкчелеге, Ставка рөхсәте белән, шәһәрне ташлап чыга һәм су асты көймәсе белән Новороссийскига юл ала. Ә калган гаскәрләргә җитәкчелек итүне, яралылар һәм җирле халык турында кайгыртуны генерал П. Новиковка йөкли. Ике көннән соң ул да Севастопольне калдырырга тиеш була.

2 нче июльгә каршы төндә генерал П. Г. Новиков җитәкчелегендәге җитмешләп кеше, 112 нче катерга төялеп, шулай ук Новороссийск ягына кузгала. Әмма таң алдыннан безнең катерны Кара диңгез өстендә фашистларның биш торпеда катеры «келәшчә»гә ала. Тиңдәшсез көрәш башлана. Авыр яралы булуга карамастан, генерал Петр Новиков аңа үзе җитәкчелек итә. Безнең сугышчылар дошманның бер катерын батыра, әмма үзләре дә, катерга фашист торпедасы тиеп, диңгез өстендә хәрәкәтсез кала. Күпләр һәлак була һәм яралана. Шулчак дошман корабле безнең катерга якын ук килә һәм, аның бортына трап салып, фашист диңгезчеләре эчкә ыргыла. Алар исән калганнарны, шул исәптән генерал Петр Новиковны кулга алып, барлык яралылар белән бергә 112 нче катерны шартлата.

* * *

Якташыбызның әсирлектәге газаплары шул көннән башлана. Аның концлагерьлардагы тормышын күзаллау өчен, әлеге җәбер-золымны бергәләп кичергән очраклы рәвештә генә исән калган кешеләргә сүз бирик әле.

Л. Некрашевич, отставкадагы өлкән лейтенант, Севастополь оборонасында катнашучы: «Фашистлар Владимир-Волынскидагы концлагерьлары уртасына кирпеч стена өйгәннәр иде. Аның ике ягындагы тимер элмәкләргә көн саен берничә совет хәрби әсире асылды. Бу безнең сугышчыларны куркытып тору өчен эшләнде. Беркөнне лагерьга немецлар озатуында хыянәтче генерал Власов армиясе офицерлары килде. Алар әлеге стена янына аракы һәм бик тәмле ризыклар белән өстәл китереп куйдылар.

— Кем генерал Власов армиясенә язылырга тели, өстәл янына рәхим итсен! — дип кычкырды теге офицерларның берсе.

Әмма берәү дә урыныннан кузгалмады. «Яхшы, сез курыксагыз, монда генералларыгыз үрнәк күрсәтер»,— диде власовчы ачу белән. Шулчак конвой белән өч совет генералын китерделәр. Мин Новиковны шундук танып алдым.

— Генерал Новиков! Сез Севастопольдә батырларча сугыштыгыз. Инде монда да үрнәк күрсәтегез, Власов армиясенә беренче булып язылыгыз,— диде аңа сатлык офицер.

Петр Георгиевич «смирно» командасы вакытындагы кебек туры итеп басты да:

— Син, килмешәк, коммунистларның үз Ватаннарын беркайчан да сатмаячакларын белмисеңмени? — дип кычкырды аңа усал итеп.

Шундый кыю җавапка рухланып, безнең әсирләр кул чаба башлады. Бу фашистлар өчен көтелмәгән хәл булды. Алар, команда да көтеп тормыйча, әсирләргә автоматлардан ут ачтылар...»

* * *

Шуннан соң генерал П. Г. Новиковны Хаммельсбургтагы офицерлар концлагерена китерәләр. Ул бирэдәге яшерен оешмага җитәкчелек итә. Провокатор лагерь җитәкчелегенә бу турыда җиткергәч, якташыбызны Флессенбургтагы лагерьга күчерәләр. Генерал П. Г. Новиковның бирэдәге соңгы көннәре турында сугыштан соң озак еллар үткәч кенә билгеле була. Әлеге лагерьда күп газаплар кичергән В.Володченков һәм Н. Панасенко истәлекләреннән:

— Бу лагерьдагы режим аеруча каты иде. Әсирләрне, шул исәптән генералларны да, ачка интектерделәр, авыр эш белән газапладылар, юк-бар сәбәп өчен генә дә вәхшиләрчә кыйнадылар.

Кышкы бер салкын көнне генерал Новиков башка әсирләр белән янәшәдәге бер кирпеч заводында эшләде. Менә шунда бер әсирнең авызыннан кан китә башлады. Башы әйләнеп, ул җиргә егылды. Новиков һәм тагын берничә кеше аны җылы урынга керттеләр. Әмма надзирательгә бу ошамады, фашист әсирне типкәли башлады. Новиков исә, авыру әсирне яклап, аңа аркылы төште.

Шуннан соң гитлерчы, ерткыч кебек, аңа ташланды. Ачлыктан һәм авыр эштән тәмам хәлсезләнгән совет генералы, аңын югалтып, тимер мич өстенә егылды. Лагерь врачлары (чех һәм поляк) Петр Новиковның баш миенә кан савуны ачыкладылар. Кичкә таба, гитлерчылар аның гәүдәсен, әле үлеп тә бетмәгән килеш, крематорийда яндырдылар.

Соңыннан бу фактны фашист архивларында эшләгән совет галиме Е. Бродский да гитлерчылар үзләре тутырган документлар белән раслый. Күренекле якташыбыз, данлы генерал П. Г. Новиков менә шулай һәлак була.

* * *

...Шушындый күренекле якташыбыз истәлеге безнең Татарстанда да булырга тиештер бит! Күңелгә гел әнә шул уй килә. Севастопольнең генерал Новиков урамындагы 109 нчы укчы дивизия музее белән элемтәгә кереп, нигә әле аның филиалын Югары Кондрата авылында булдырмаска икән? Нигә әле генералның туган авылындагы крестьян хуҗалыклары берләшмәсенә аның исемен бирмәскә?.. Данлы генералның әнисе Марфа түти, 60 нчы еллар башына кадәр яшәп, улының батырлыклары турында берни белмичә үлеп китә. Инде бүгенге буын данлы якташыбыз хакында азмы-күпме хәбәрдар булсын иде.

*Нургали Булатов*

## Керәшен туе

Җыр ургыла ишек, тәрәзәләрдән,
Нәни кыйтга — авыл ызбасы.
Керәшен туе бүген шул кыйтгада —
Борынгы җыр — болгар йоласы.

«Тәрәзә төбендә ай, тутый кош,
Ак мамыклар белән тотыгыз.
Безнең бәбкәебез сезгә килә,
Какмый гына, сукмый тотыгыз».

Кода-кодаларның җор телләре
Чакма белән гүя — чакматаш.
Җыр бәрелеп җырга очкын чәчри,
Тапкырлык һәм акыл башма-баш.

«Урманнарга кердем атым бәйләп,
Кисепкәйләр алдым киртәлек.
Хезмәтләрен килен аямаса —
Шунда булыр аңа иркәлек».

Ничек бөреләнгән яңа дәвам —
Үткәннәргә, яле, күз салыйк.
Асылташта кояш чагылгандай
Һәр йолага сыйган бер тарих.

Болгар учагыннан бүгенгегә
Төшкән чаткы чорлар аркылы.
Авыл ызбасында керәшен туе —
Чал тарихның нәни ярчыгы.

Шул ярчыкта бөтен ышанычы
Һәм өмете балкый ил-көннең.
Йөрәкләргә төреп киләчәккә

Илтиекче аны, и энем!..

*Ямаш Игәнәй*

## Теләче суы тәме

Әгәр өстендә генерал кителе булмаса, беренче очрашуда аның турында: «Мөгаен, укытучыдыр»,— дип уйлар идең. Сөйләшүе ягымлы, йөзеннән ниндидер нур бөркелеп тора, үз-үзен тотышы гаять итагатьле. Киң белемле булуын исә һәр сүзеннән аңлыйсың.

«Урта мәктәп тәмамлагач, хәрби училищены сайларга нәрсә сәбәпче булды?» — дип сорыйм аннан. Югыйсә бүгенге район үзәге Теләче авылы барлык сугышчан вакыйгалардан да читтә калган. Бирегә Октябрь җилләре дә сиздермичә генә килеп кергән, гражданнар сугышы да аны читләтеп узган.

Бу сорауны биргәч, генерал Александр Смирнов уйчанланып кала. «Мөгаен, моңа Бөек Ватан сугышыннан соңгы рух, данлы традицияләребезгә зур ихтирам этәргеч биргәндер»,—ди ул. Аннары, иң элек, әнисе ягыннан бабасын — өч сугыш ветераны, Петр Степанович Ивановны хәтергә төшерә. Теләче төбәге кешеләре аны бөтен күрше-тирәдә данлыклы базарның директоры буларак кына беләдер. Ә булачак генерал өчен ул үзенең бик күп сугыш истәлекләре, Кораллы Көчләребезнең данлы тарихын әйбәт белүе белән кадерле була.

Әтисе Афанасий һәм әнисе белән бертуган ике абыйсының фашизмга каршы көрәштә Берлинга кадәр барып җитүләрен дә әйтергә кирәк әле. Әгәр алар бәйрәмнәрдә бер өстәл тирәсенә җыелышсалар, истәлекләрен тыңлап кына өлгер. Я, мондый гаиләдә тәрбияләнгән үсмернең киләчәген башкача күз алдына китерергә мөмкинме соң? Шуңа күрә егет урта белем алуга Казан Югары командалык танк училищесына барып керә.

Аны тәмамлагач, яшь офицерның хезмәт юлы Карпат буе хәрби округында башлана. Львов өлкәсендәге Яворово шәһәрен, данлы «Тимер» дивизиянең анда урнашкан мотоукчы полкын әле дә онытасы юк Теләче егетенең. Взвод командиры буларак, аңа үз танкы экипажы өчен бар яктан җавап бирергә туры килә. Өйрәнүләр вакытында экипажның әйбәт нәтиҗәләр күрсәтә алуы, танкистларның бар яктан башкаларга үрнәк булуы тырышлыкның бушка китмәве турында сөйли.

Офицер А. Смирнов укуын дәвам иттерергә — бронетанк гаскәрләре Академиясенә укырга керергә бик теләсә дә, язмыш киләчәкне башкача хәл итә. Полк командиры подполковник О. Емельяненко һәм аның урынбасары Э. Борщевский аны комсомол эшенә күчәргә кыстыйлар. Теләмәсә дә, ризалык бирә офицер һәм шуннан, үзе дә сизмичә, яңа вазифага күнегеп китә, муеннан эшкә чума. Ул бераздан полкта, солдатлар арасында казармада ук яши башлый. Тырышлык бушка китми: хәрби частьта «дедовщина» дигән чирнең эзе дә калмый, солдатлар һәм офицерлар арасында җылы мөнәсәбәтләр урнаша, үзешчән сәнгать түгәрәге җанлана, шәһәрдәге музейларга культпоходлар оештырыла башлый...

Яшьләр җитәкчесенең бу уңганлыгын югарыда да күрәләр. Офицер А. Смирновны башта Ровно шәһәренә 13 нче армиянең сәяси бүлегенә өлкән инструктор итеп алалар. Аннары шул ук вазифага Карпат буе хәрби округының сәяси бүлегенә күчерәләр. Александр Смирнов читтән торып В. И. Ленин исемендәге хәрби-сәяси Академиягә укырга да керә. Яшьләр вожагы Украина комсомолының XXV съездында, ВЛКСМның XVII съездында, комсомол оешмалары секретарьларының Бөтенармия киңәшмәсендә катнаша.

Хәзер «комсомол» дигән сүзне ишетүгә кайберәүләрнең йөзләренә көлемсерәү чыга. Имештер, тоталитар режимның уң кулы булган оешма бит ул. Имештер, яңгыравыклы чакырулардан башка аның бер генә конкрет эше дә булмады... Генерал Александр Смирнов, әлеге чорлар үзе өчен инде шактый артта калса да, хәзер заманалар башка булса да, моның белән килешми. Комсомол күп данлы башлангычларда яшьләрнең әйдәүчесе булды. Бөек Ватан сугышында, аннан соң илне һәм хуҗалыкны аякка бастыру елларында ул берәүнең дә җилкәсе артына яшеренмәде. Яшьләрнең шушы сугышчан оешмасы тузды-рылгач, безнең егетләр һәм кызлар арасында төрле ямьсез күренешләр колач җәйде бит.

Әгәр кешенең үз күңелендә нәрсәдер булмаса, аны арттан этеп кенә яңа биеклекләргә күтәрүдән, яңа вазифаларга билгеләүдән мәгънә чыкмый. Тәрбия эше яшь кешене ниндидер һөнәргә өйрәтү белән янәшә барырга тиешлегенә чын күңелдән ышану офицер А. Смирновка яңадан-яңа энергия бирә, һәм аны, шундый инанган сәяси җитәкчене, әледән-әле җаваплырак урыннарга күчерәләр. Ул Коры җир гаскәрләре Баш сәяси идарәсендә дә, Совет гаскәрләренең Германиядәге группасында да эшли. 34 яше тулар-тулмаста биредәге 27 нче гвардия мотоукчы дивизиясенең сәяси бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнә.

Аннары ул Одесса хәрби округындагы 14 нче армиядә, Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флотының Баш сәяси идарәсендә. Ерак Көнчыгыш хәрби округының 51 нче армиясендә хезмәт итә. Соңгысында армия сәяси бүлеге җитәкчесе булып эшләгәндә аңа генерал дәрәҗәсе бирәләр.

Кораллы Көчләрдәге барлык сәяси-тәрбия органнар бөтенләй бетерелә. Әмма бераздан, моның ялгыш адым икәнлеген аңлап, һәркайда «шәхси состав белән эшләү» дигән исемдәге бүлекләр булдырыла, һәм генерал А. Смирнов да Ерак Көнчыгыш хәрби округына командующий ярдәмчесе итеп җибәрелә. Ул биредә генерал-полковниклар В. Новожилов һәм В. Чечеватов белән эшли. Ә 1993 елда ул Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең тыл начальнигы — оборона министры урынбасары ярдәмчесе итеп билгеләнде.

…Генерал Александр Афанасьевич Смирнов туган төбәге Теләчене һичкайчан онытмый. Бирегә ел саен берничә тапкыр кайтып китә. Әнисе — элеккеге укытучы Зоя Петровналар йортында исә, аның хәлен белешеп, әледән-әле телефон шалтырап тора. Генерал якташларына да кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша, аларның һәр уңышына сөенә. Район хакимияте башлыгы, Татарстан халык депутаты Илдар Низамов белән аларның үзара бик җылы мөнәсәбәтләре турында аерып әйтергә кирәк.

— Теләчедә күптән түгел бик заманча урта мәктәп салынуын, авылның шәһәр төсе алуын, урамнарга асфальт җәелүен, йортларга газ кереп бетүен яхшы беләм. Әмма минем күз алдымнан элеккеге агач мәктәп, бергә укыган дусларым китми,— ди генерал, хисләнеп.

Район хакимиятенең мәгариф идарәсе җитәкчесе Мансур Газизов белән ул бер партада утырган икән. Артиллерия маршалы Н. М. Чистяков исемендәге Казан Югары командалык ракета гаскәрләре һәм артиллерия училищесы өлкән укытучысы, подполковник Фәрит Нурисламов та аның классташы. «Яхшы билгеләренә генә хәрби училище һәм академия тәмамласа да, киләчәктә үсәргә барлык мөмкинлекләре булса да, Фәритнең көтмәгәндә Кораллы Көчләрдән китүен һич аңламадым»,— ди Александр Афанасьевич. Ул классташы, филология фәннәре кандидаты Валентина Романова белән дә горурлана. Аның Ватан каршындагы тырыш хезмәте зурлап билгеләп үтелүен дә әйтергә кирәк. Генерал А. Смирнов 3 орден һәм 11 медаль белән бүләкләнгән.

«Татарстанда туып үскән хәрби эшлекледер» дигән сүз чыгуга ул: «Ә 41 яшьлек Балык Бистәсе егете генерал-лейтенант Хәмит Камаловны — РФ Тимер юл гаскәрләре командующие урынбасарын беләсеңме?» — дип сорап куйды һәм бу эштә киләчәктә кулдан килгәнчә булышырга, яңа адреслар табып бирергә вәгъдә итте. Ә бер көннән редакциядә Мәскәүдән телефон шалтырады. Генерал А.Смирнов икән. «РФ Оборона министрлыгы Үзәк азык-төлек идарәсе башлыгының беренче урынбасары генерал Наил Михаил улы Сәләхетдинов телефоннарын язып куй әле. Казанда туып үскән, хәрби училище һәм академия тәмамлаган, бик акыллы, чын татар егете ул»,—диде Александр Афанасьевич.

Менә шулай белеп торыгыз: Теләчедән дә генерал бар!

*Нургали Булатов*

## Фонографлы гыйлем иясе

Керәшеннәрнең музыка сәнгатен үстерүдә күп көч куйган шәхесләребез бар, алар арасында XX йөз башында һәм аңа кадәр үк шактый күренекле эшләр эшләгән, әмма бүгенге көнгә кадәр киң җәмәгатьчелегебезгә аз билгеле булганнары да аз түгел. Хак сүз бит: тарихыбызның чишмә башларын тазартып, андагы шифалы сулар тагы да сафланып ага башлагач кына, без ныграк, җегәрлерәк булыр идек.

Керәшен көйләрен хор өчен эшкәртә башлаучыларның беренчесе — профессиональ музыкант Гаврилов Василий Семенович.

Гаврилов Бәчелей Симун улы Чистай өязендәге Актау авылында 1888 нче елның 11 нче январь көнендә туган. Башлагыч белемне ул халкыбыз арасында билгеле булган Бәчелей әтей (Тимофеев) җитәкләгән Үзәк керәшен мәктәбендә Казанда ала, аны яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Кече яшьтән үк туган халкының тарихы һәм сәнгате белән кызыксына. Мондый кызыксыну Керәшен мәктәбендә укыганда тагы да көчәя: мәктәптә төрле үнәр һәм сәнгать белән танышу өчен мөмкинлекләр күп була. Монда музыка дәресләре аеруча талантлы һәм югары белемле укытучылар тарафыннан укытыла, һәрбер балага нота гыйлеме өйрәтелә.

Халкының иҗатын өйрәнү кебек омтылышны хуплауда Керәшен мәктәбендә һәм Укытучылар семинариясендә ре-
гентлык фәне буенча дәресләр биргән күренекле галим, борынгы рус музыкасын тикшерүче хор белгече С. В. Смоленский өлешен дә күрсәтеп үтәргә кирәктер. С. В. Смоленский үзе дә керәшеннәрнең музыкаль фольклоры белән кызыксына. Аның архивында үзе язып алган керәшен көйләренең ноталары да булганлыгы билгеле.

Керәшен мәктәбендә укып, музыка гыйлемен яхшы үзләштергән укытучылар арасында Аполлон Топорков исеме дә бар. Ул туган төбәге Бакалы, Яңа Балыклы авылларында җырланган керәшен көйләрен

нотага салу белән дә мавыга. Бу мәктәптә скрипка, фисгармония, гитара кебек уен коралларында уйнарга өйрәнүчеләр күп була.

В. С. Гаврилов 1905—1911 нче елларда укуын Укытучылар семинариясендә дәвам итә. Әмма музыка белән мавыгуы аңа тынычлык бирми. Ул, параллель рәвештә, Казан музыка училищесында укып, андагы музыка теориясе бүлеген уңышлы тәмамлый. 1911 нче елдан соң ул музыка училищесына эшкә чакырыла һәм анда, теория фәннәрен укыту белән бергә, регентлык (хор) классларының мөдире була. Яшь белгечнең эше уңышлы барганлыктан, аны 1916 нчы елда Казандагы Рус опера театрына баш хормейстер итеп эшкә чакыралар.

Керәшеннәрнең милли үзаңы, башка халыкларныкы кебек үк, бу елларда актив рәвештә ныгый бара. Бу процесс үзен сәнгать, мәдәният өлкәсендә дә ачык сиздерә. В. С. Гаврилов һәм аның кебек башка керәшен музыка белгечләре дә милли музыка структурасын төзү өчен күп эш башкара. Алар Үзәк керәшен мәктәбендә даими концерт–кичәләр оештыра, халык көйләрен җыеп, аларны заманча эшкәртеп, халыкка кире кайтарырга тырышалар. Бу елларны Василий Семенович та үзенең эчке омтылышы белән керәшен музыкасын күтәрү, халык көйләрен җыю өстендә көне-төне эшли.

1917 нче ел җитеп, буталчык вакытлар башлангач, ул Себер ягына юнәлә. Аның болай еракка искәрмәстән китүе, бәлки, кызыл хакимият белән килешеп бетмәвенә протест билгесе булгандыр. 1918—1920 нче елларда ул Томск каласының халык консерваториясендә укыта һәм шундагы опера театрында хормейстер булып эшли.

Шул ук елларда, Урта Идел буе халыкларының музыкаль ихтыяҗларын искә алып, Казанда Шәрык консерваториясе оештырыла. Анда чуваш, удмурт (вотяк), мари (чирмеш), керәшен, татар филиаллары ачыла. Керәшен музыка мәктәбендә эшләү өчен В.С.Гаврилов чакырыла.

Керәшен музыка мәктәбенең мөдире М.М.Бударин һәм В. С. Гаврилов Арча Кыры буендагы элеккеге Керәшен мәктәбе бинасында керәшен балаларын музыкага өйрәтә башлыйлар. Мәктәпнең эше белән Губкомның керәшен секциясе вәкилләре даими кызыксынып тора. Мәсәлән, Г. Ф. Зубков консерватория укытучылары утырышларының берсендә Керәшен музыка мәктәбе укучыларына булган өметләрен белдерә, керәшен халкының милли профессиональ музыкасын булдыру турындагы хыяллары белән уртаклаша һәм якын арада булырга тиешле керәшеннәр съезды турында сөйли. Съезд көннәрендә яшь музыкантлар үзләренең уңышларын, махсус әзерләгән музыкаль әсәрләрен күрсәтсәләр, яхшы булыр иде, дигән теләк белдерә.

Шәрык консерваториясендә В.С.Гаврилов белән бергә күп кенә танылган галимнәр, иҗатчылар эшли. Алар арасында күренекле татар композиторы һәм фольклорчысы Солтан Габәши дә була. Ул бу елларны Гаврилов кебек үк хор классларын җитәкли һәм казакъ, башкорт, татар халык көйләре җыентыкларын әзерләү буенча фәнни эш алып бара.

Мәшһүр тюрколог Н. Ф. Катанов укыткан фән «Курс поэзии кряшен, татар, башкир и других народов Востока» дип аталган. Мондагы укыту һәм фәнни мохиткә зур тәэсир иткән шәхесләрдән профессор Н. В. Никольскийны атарга кирәктер. Чуваш халкының бу каһарман улы музыкаль этнографиягә бәйле фәннәрнең укыту программаларын төзегән, музыкант этнографик сүзлекләр төзүче галим буларак танылган.

Консерватория каршында төзелгән Фәнни музыкаль-этнографик ассоциация турында аерым әйтергә кирәк, чөнки аның эшчәнлегендә В. С. Гаврилов иҗаты да ачык чагылыш таба. Мәсәлән, 1921 нче елның 20 нче апрелендә ассоциация утырышында ул «Керәшен татарларының җыр-көйләре турында» дип аталган доклад белән чыгыш ясый. Доклад барышында В. С. Гаврилов керәшен җырчылары башкаруында фоноваликларга яздырылган төрле көйләрне фонограф аша яңгыраттыра. Бу фәнни утырышта катнашкан белгечләр тарафыннан керәшен көйләре мөселман динен тотучы татарларныкына күпмедер дәрәҗәдә охшаш, дигән фикер әйтелә. Докладчы күпмедер охшашлык булуын кире какмый, әмма шуның белән бергә алар арасында аермалык барлыгын да билгеләп үтә, керәшен көйләренә караганда мөселман татар көйләренең катлаулы бормалары күбрәк булуын искәртә. Галимнең чыгышын тикшергәннән соң, тыңлаучыларның бердәм фикере буенча, сөйләнгән доклад үтә кызыклы булды, дип һәм «баштан алып азагына кадәр музыка белеме фәнендә яңа сүз» дип бәяләнә. Нәтиҗәдә түбәндәге карар кылына:

— В. С. Гавриловтан мөмкин кадәр тулы һәм күбрәк итеп халык көйләрен язып алуны сорарга һәм аларның фәнни нигездәге музыкаль анализларын ассоциациягә җиткерергә; данлыклы халык җырчыларын фонографка язып алу өчен, В. С. Гавриловны Лаеш өязенә махсус оештырылган фольклор экспедициясенә җибәрергә.

Үткән 20 нче еллар дәвере хәзерге заманга бик охшаш. Ул вакытта да җирле сәнгатьне өйрәнү һәм үстерү, халкыбызга хезмәт итү өчен комачаулаган күп киртәләр дәүләт тарафыннан алынган булган, әмма

дәүләт бик нык ярлыланган, һәм, казна буш булу сәбәпле, мәдәният чыгымнарын күтәрә алмаган. Илдәге интеллектуаль көчләр, тормышның катлаулы шартларында халыкның милли мәдәнияткә булган ихтыяҗларын, теләкләре булса да, чикле рәвештә генә канәгатьләндерә алганнар.

20 нче еллар башында олы энтузиазм белән, тормыш авырлыкларына, илдәге ачлыкка карамыйча, күп шәхси чыгымнар тотып, В. С. Гаврилов, аркасына фонографлы капчык асып, авыллар арасында халык көйләрен язып йөри. Аның нияте керәшен җырулары җыентыгын әзерләү һәм аны китап итеп бастырып чыгару, керәшеннәрнең музыкаль структурасын яңа язма баскычка күтәрү, музыка мәктәпләре өчен әсбаплар төзү була. Язылачак китапта ул, мәсәлән, Актау авылында язып алынган бәйрәм арасы көйләренең ноталарын, Кибәч авылында ишетеп алынган балалар җыруларын, Кәвәлдәге шаян такмак һәм башка борынгы көйләр кертеп, фортепиано һәм хор белән башкарырлык итеп әзерләргә тиеш була. Әмма ул хыялларының тормышка ашмаячагын белми әле, югары омтылышлы уйлар белән ашкына-ашкына, халкының сәнгатен кичегүне белмәгән Вакыт упкыныннан саклап калырга тырыша һәм бу изге эшенең тормышка ашуына ышана.

Бу заманда аның яшәү шартларының да бик начар булуын искәртергә кирәк. Ул Казанда элеккеге Некрасов тыкрыгындагы 22 нче йортның 5 нче фатирында, яртылаш җимерек коммуналь өй тибындагы бер тулай торакта яши. Ачлы-туклы яшәп, суык тидереп, авыруларын да онытып һаман эшли, сукыр лампа яктысында нота материалларын эшкәртә, бу авыр заман бер бетәр, дип өметләнә.

Ниһаять, большевистик җиңү эйфориясе бетә башлый. Милли сәнгать, музыка проблемаларына игътибар азая, хәтта, киресенчә, милли көйләрне милләтчелеккә этәрә торган фактор дип бәяләүгә юл ачыла. Чөнки илдәге авырлыклар элеккеге байлар һәм буржуаз милләтчеләр корткычлыгы нәтиҗәсендә дәвам итә, дип белдерелә.

Профессиональ белемле һәм тәҗрибәле милли кадрлар булган музыкант-этнографлар В. Гаврилов һәм С. Габәшигә, Н. Катановка һәм Н. Никольскийга төрле яла ягылып, эшләреннән кысрыклау кампаниясе башлана, Шәрык консерваториясе һәм Керәшен музыка мәктәбе ябыла. Гаврилов Мәскәүгә юл тота һәм опера театрында баш хормейстер булып эшли башлый.

Мәскәүдә Татар опера студиясе оешкач, Гаврилов татар музыкантлары белән даими аралаша, хәленнән килгәнчә булышлык күрсәтә, аларның уңышларына сөенә. Шунысын да әйтергә кирәк: студиядә В. Гавриловның сеңлесе, киләчәктә
татар операсы солисткасы Лидия Семеновна Гаврилова да укый.

1939 елны, Казанда Татар милли опера театры ачылгач, танылган һәм зур тәҗрибәле хор белгече булган Василий Семенович Гавриловны Казанга эшкә чакыралар. Өлкән музыкант үзенең бар булган сәләтен, энергиясен биреп эшли башлый. Татарстан хөкүмәте һәм ВКП(б) өлкә комитеты В. Гавриловның татар опера сәнгатен үстерүдәге хезмәтен югары бәяли. 1944 нче елда аңа һәм балетмейстер Гай Таһировка Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә. Әлеге югары исемне алуга, җәмәгатьчелек үзенең эшен күреп бәяләгәнгә ул сөенгәндер билгеле. Әмма аның сәламәтлеге какшаган була инде. Шул ук елның азагында ул, каты авырып, кире Мәскәүгә китә һәм бераздан шунда дөнья куя.

Татар опера театры ветераннары В. С. Гавриловны бүген дә зур ихтирам белән искә ала. Мәсәлән, Любовь Дмитриева аны бик белемле, абруйлы хормейстер буларак хәтерли. Аның Усман Әлмиев белән дустанә мөнәсәбәттә булуын сөйли.

Шунысы бик үкенечле: В. Гавриловның соңгы адресын, туганнарын табып булмады. Югыйсә аның бай гына шәхси архивы да бардыр, кем белә бит?

Аның яшәү дәвере буталчык һәм авыр заманага туры килү сәбәпле, язма хезмәтләренең дә күбесе матбугатта басылмаганга, безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән.

«Булган эш эзсез калмый»,— дип юкка гына әйтмиләр. 1970 нче еллар азагында Казан дәүләт университетының архивы чистартыла һәм «кирәкмәгән» кәгазьләр чүплеккә ташлана. Битараф булмаган кешеләр аннан Н. В. Никольский тарафыннан чыгарылган «Краткий конспект по музыке народов Поволжья» китабын, аның эчендә В. С. Гаврилов тарафыннан әзерләнгән нота кульъязмасын табалар. Музыка белгече М. Н. Нигъмәтҗановка тапшыргач, ул аңа музыкаль-текстологик анализ ясый.

В. С. Гавриловның тормыш һәм иҗат юлы турындагы мәгълүматлар тулы түгел. Аның иҗат мирасын барларга, табылмаган әсәрләрен эзләргә кирәк. Шул чакта гына бу фидакарь кешенең халкыбыз тарихындагы чын урынын төгәлрәк билгеләп булыр иде.

*Геннадий Макаров*

## 10—11 НЧЕ СЫЙНЫФЛАР ӨЧЕН

## Керәшеннәр кайларда яши?

Керәшеннәр — христиан динендәге татарлар. Кызганычка каршы, керәшеннәрнең христианлашу тарихы фәндә ныклап өйрәнелмәгән, бу мәсьәләгә багышланган махсус хезмәтләр бик аз.

Тарихи хезмәтләрдән күренгәнчә, татарларны христианлаштыру рус патшасы Иван Грозный 1552 нче елда Казанны алганнан соң башланып китә. Архиепископ Гурийга христианлаштыру эшләрен башлап җибәрергә патшаның әмере тапшырыла.

Соңгы вакытлардагы кайбер хезмәтләрдә һәм матбугатта керәшеннәрнең бер өлеше тагын да элеккерәк чорлардан ук христиан динен кабул иткән булырга мөмкин, дигән фикерләр дә язылып чыкты.

Керәшеннәрне, христиан динен кабул итү вакытлары буенча, «иске» һәм «яңа» керәшеннәргә аерып йөрткәннәр. Казан ханлыгы рус дәүләте тарафыннан җиңелгәннән соң, ягъни XVI гасырның урталарыннан алып 1731 нче елга кадәр христианлаштырылган татарлар «иске керәшеннәр» дип аталган.

1731 нче елда миссионерлык эшен тагын да алга җибәрү максатыннан, махсус комиссия (новокрещенская комиссия) оештырыла. Бу комиссия оештырылганнан соң христианлаштырылган татарлар «яңа керәшеннәр» дип аталып йөртелә башлый. Яңа керәшеннәр XVIII—XIX гасырларда гына христиан динен кабул итә, аларның күпчелек өлеше шул вакыттагы мәҗүси чувашлар, марилар, удмуртлар була.

Шулай итеп, керәшеннәр үзләренең электән яшәп килгән урыннарында гына түгел, ә мөселман йогынтысыннан саклау өчен күчереп утыртылган урыннарда көн күрә. Патша хөкүмәтенең, миссионерларның шундый тырышлыгы нәтиҗәсендә, керәшеннәр татар халкының төп өлешеннән берникадәр аерымланып яшәгән. Керәшеннәрнең рухи һәм матди мәдәниятендә, тел-сөйләм үзенчәлекләрендә кайбер борынгылыклар сакланган, шул ук вакытта христиан дине белән кергән йолалар һәм йола сүзләре барлыкка килгән.

Керәшеннәр барысы да бер төрле түгел, алар үз эчләрендә дә бер-берсеннән шактый нык аерыла. Тел-сөйләм үзенчә-лекләре, шулай ук икътисади һәм рухи мәдәнияткә караган үзенчәлекләрне чагыштырып караганда, шактый ерак араларга сибелеп утырган керәшеннәрнең биш зур төркеме бүленеп чыга (китапның 6—7 нче битләрен карагыз).

Тарихи материаллардан күренгәнчә, татарларны христианлаштыру чорында татарлар белән янәшә яшәп, алар йогынтысында торган күп кенә башка халыклар — удмурт, марилар һ. б. да христиан диненә кертелгән һәм, керәшен булып, татарлар белән аралашып яшәп киткәннәр. Казан арты төбәгендә күп кенә татар авылларына нигез салучылар удмуртлар һәм марилар булган, соңга таба алар, татарлар белән аралашып, кушылып беткәннәр яки күчеп киткәннәр.

Тел үзенчәлекләре ягыннан Казан арты керәшеннәре бер төрле генә түгел, бу сөйләшне берничә урынчылыкка бүлеп карарга мөмкин:

Мишә буе керәшеннәре сөйләше;
Ташкирмән авылы сөйләше;
Пакшин авылы сөйләше;
Вятка буе авыллары сөйләше;
Кама буе авыллары сөйләше;
Шушма буе авыллары сөйләше;
Кукмара керәшеннәре сөйләше.

Архивта сакланган һәм Түбән Кама тирәсендә яшәүче иске керәшеннәр яши торган авылларны күрсәткән исемлектә Юшады, Мәлкән, Мәләкәс, Сәвәләй, Драгун-Бикмәт, Пәнәче һ. б. авыллар бар. XIX гасырда христиан динен саклау һәм аның йогынтысын ныгыту максаты белән керәшен авылларында чиркәүләр салына башлый. Мәсәлән, Уфа епархиясе язмаларында түбәндәге мәгълүматлар бар:

Юшады авылында чиркәү 1885 нче елда салынган, приходта 1785 иске керәшен, чирмешләр, 407 чуваш, мөселманлыкка чыккан 196 керәшен исәпләнгән.

Мәлкән авылында чиркәү 1890 нчы елда салынган, приходта 1818 иске керәшен, мөселманлыкка чыккан 80 керәшен исәпләнгән.

Балтай авылында чиркәү 1889 нчы елда салынган, приходта 291 керәшен, мөселманлыкка чыккан 34 керәшен исәпләнгән.

Сәвәләй авылында чиркәү 1889 нчы елда салынган, приходта 291 керәшен, мөселман диненә чыккан 34 керәшен саналган.

Драгун-Бикмәт авылында чиркәү 1889 нчы елда салынган, приходта 410 чуваш, мөселман диненә чыккан 61 керәшен саналган.

Баткак авылында чиркәү 1882 нче елда салынган, приход-
та 137 керәшен, мөселман диненә чыккан 532 керәшен саналган.

Мәләкәс авылында чиркәү 1888 нче елда салынган, приходта 2898 иске керәшен саналган.

Балчыклы авылында чиркәү 1882 нче елда салынган, приходта иске керәшеннәр теркәлгән.

Аты авылында чиркәү 1890 нчы елда салынган, приходта 1705 иске керәшен, 397 чуваш, мөселман диненә чыккан 379 керәшен исәпләнгән.

Ләке авылында чиркәү 1782 нче елда салынган, 1932 иске керәшен исәпләнгән.

Борды авылында чиркәү 1888 нче елда салынган, приходта 2450 иске керәшен, мөселман диненә чыгучы 49 керәшен теркәлгән.

Усы авылында чиркәү 1895 нче елда салынган, приходта 941 иске керәшен теркәлгән.

Кили авылында чиркәү 1871 нче елда салынган, приходта 23 башкорт һәм типтәр, 1133 иске керәшен, 297 мордва исәпләнгән.

Маты авылында чиркәү 1887 нче елда салынган, приходта 683 чуваш, 1021 иске керәшен исәпләнгән.

Ахман авылында чиркәү 1893 нче елда салынган, приходта 28 мәҗүси чуваш һәм иске керәшеннәр теркәлгән.

Түбән Кама тирәсе керәшеннәренең сөйләше үзе дүрт урынчылыкка бүлеп карала.

Чистай районындагы керәшен авылларының барлыкка килүе XVII гасырда патша хөкүмәте тарафыннан Кама арты линияләренең төзелү чоры белән аңлатыла.

Тел үзенчәлекләре ягыннан чыгып караганда, Чистай керәшеннәре сөйләше, бигрәк тә лексика өлкәсендә, мишәр сөйләшләренә якын тора, Казан арты һәм Түбән Кама тирәсе керәшеннәре белән дә уртак.

Тау ягындагы керәшен авыллары Татарстан белән Чувашстан чигендә урнашкан. Күрше булып торган татар һәм чуваш авыллары элек-электән бер-берсе белән нык аралашып, үзара йөрешеп яшиләр, бәйрәмнәр һәм кичке түгәрәк уеннарда чувашлар да, керәшеннәр дә бергәләп уйный, уртак җырлар җырлый. Бу төбәктәге татарлар һәм чувашлар арасында гаилә бәйләнешләре дә көчле булган, киленнәрне чувашлар-дан алу гадәти күренеш булып саналган. Әмма чуваштан килгән киленнәр керәшен гаиләсендә бик тиз генә татарча сөйләшүгә күчеп киткән. Биредәге авылларда яшәүче керәшеннәрнең күпчелеге ике телдә: чувашча да, татарча да яхшы сөйләшәләр.

Халык телендә сакланган истәлекләргә караганда, хәзерге керәшеннәр христиан динен XVI нчы йөздә кабул иткән. Авыл исемнәре, зиратлардагы кабер ташлары бу авылларга нигез салучыларның исемнәре белән бәйле булса кирәк. Мәсәлән, Куясан авылы — Хуҗа Хәсән, Мәлки — Мәүликәй, Кырбаш — Корбангали, Тәрбит — Тәңребирде һ. б. Орым Тәрбите авылы янындагы иске зиратта (бу авыл кешеләре аны мазар, мазарлык дип әйтәләр) язулы кабер ташлары сакланган, шуларның берсендә Тугаш улы Тәңребирде исеме һәм ташның 1550 нче елда язылган булуы турында мәгълүматлар бар.

Тел үзенчәлекләре һәм материаль культурада чувашлар белән уртаклыклар булса да, бу төркем керәшеннәрне борынгы татарлар дип карарга нигез бар. Ә күрше чуваш халкы белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнашу христиан динен кабул иткәч, тагын да көчәеп киткән булырга тиеш.

1924 нче елга кадәрге административ бүленеш буенча Чиләбе өлкәсендәге керәшен авыллары Оренбург губернасының Верхнеуральск өязенә караган.

Нагайбәкләр XIX гасыр урталарына кадәр Уфа губернасының Бәләбәй өязе Нагайбәк крепосте тирәләрендә казнага ясак түләп яшәгән. Соңыннан, башкорт бунтларында катнашмаган өчен, Нагайбәк крепосте тирәләрендә яшәгән керәшеннәр ясактан азат ителгән, үз кулларына җирләр бирелгән һәм 1748 нче елдан башлап бу керәшеннәрне казакъ сословиесенә керткәннәр, алардан махсус казакъ полклары төзе-гәннәр. Нагайбәкләр 1842 елга кадәр Бакалы авылы һәм Нагайбәк крепосте тирәләрендә яшәгән. Әмма 1842 нче елда, өченче казакъ кантоны бетерелгәч, Бакалы һәм Нагайбәк станицаларына караган авыллардан казакъ гаиләләрен Оренбург губернасындагы Верхнеуральск өязенә күчереп утыртканнар.

Рус армиясенең Италия, Германия, Франция белән булган сугышларда ирешелгән уңышларын мәңгеләштерү максатыннан, нагайбәкләр яши торган авылларга да чит шәһәрләр исеме: Париж, Варлам, Фершампенуаз, Требия һ. б. бирелгән.

Нагайбәкләрнең килеп чыгышлары, кем булулары белән галимнәр күптәннән кызыксынган. П. И. Рычков, В. Н. Витевский нагайбәкләрне Казан ханлыгы җимерелгәч үк чукындырылган Арча ягы татарлары дип исәпли. Ф. М. Стариков, П. Небольсин аларны чукындырылган нугайлар дип карый. С. А. Токарев нагайбәкләрне керәшеннәр дип исәпли. Хәзерге вакытта нагайбәкләр үзләре дә Казан ягы керәшеннәре белән кардәш икәнлекләрен онытмаганнар, алар үзләрен «иске ил керәшеннәре» дип атый.

Нагайбәкләрнең һәм элекке Казан, Уфа губерналарында яшәгән керәшеннәрнең теле бер-берсеннән бик аз аерыла. Моңа Н. Ф. Катанов та игътибар иткән булган. Әмма нагайбәкләр күп еллар дәвамында татар халкының төп массасыннан читтә, башка халыклар — казакъ, башкортлар чолганышында яшәгәнлектән, аларның сөйләшендә күпмедер аермалы үзенчәлекләр дә бар.

Нагайбәк сөйләшендә әдәби телдән аермалы булган үзенчәлекләр фонетика, морфология һәм лексика өлкәсенә карый һәм алар урта диалектның башка сөйләшләре, бигрәк тә Казан арты керәшеннәре сөйләшләре белән уртак.

*Флера Баязитова,*
филология фәннәре докторы

## Әти җаны

Ак күбәләк мендәремә кунды,
Әти кайтты минем яныма.
«Хәлең» ничек?» — диеп сорау бирде
Әти җаны минем җаныма.

Авыр әле, әти, хәлем, дигәч,
Ак канатлар куйды тетрәнеп.
Өч мәртәбә кайтты әти җаны,
Ак күбәләк булып әйләнеп...

— Әйдә, китик, кызым, минем белән,
Язмышыңнан ерак качарсың.
Ә сагынсаң инде балаларың,
Ак күбәләк булып очарсың.
— Китмим әле, әти, мин булмагач,
Туганнарым ничек яшәрләр.
Ике балам, тезләренә менеп,
Кемгә «әни» диеп дәшәрләр?

*Мария Логинова*

## Безнең як керәшеннәре болай сөйләшә

Безнең авылның рәсми исеме Федотовка булса да, халык телендә аны Аланлык дип йөртәләр. Саф керәшен авылы буларак бездә чит теллләрдән кергән алынма сүзләр фонетик яктан бик нык татарчалаштырыла, дөресрәге, төркиләштерелә. Әйтик, татар теленә ислам дине белән килеп кергән ф, в, х, һ авазлары безнең авыл телендә бөтенләй юк. Гаеп итмәгез, без «файда» сүзен «пайда», «хәбәр»не «кабар», «Фатыйма»ны «Патима», «Фатыйх»ны «Патик», «Христос»ны «Кристус», «хач»ны «кач», «колхоз»ны «калкуз», «һава»ны «ауа», «хәл»не «әл», «дәфтәр»не «дәптәр» дип сөйләшәбез. Ни өчен «гаеп итмәгез» дим, чөнки без башкача сөйләшә белмибез. Шулай ук, төрки телләргә хас булганча, бездә сүз «р» авазыннан яки «ст» дип башланып китә алмый. Бездә «рәсем» — «эрәсем», «рәхәт» — «ыракать», «Родион» — «Ырадибан» яки «Ырайман», «рам» — «ырам», «стакан» — «ыстакан», «Степан» — «Ычтапан».

Мондый төркиләштерүләр кеше исемнәрен әйткәндә аеруча нык сизелә. Билгеле булганча, христианлаштырылган татарлар, ягъни керәшеннәр, рәсми төстә рустан кергән исемнәр йөртә. Безнең авыл кешеләре арасында үз исемнәрен түбәндәге үзгәртелмешләрдә генә куллану инде тәмам ныгып өлгергән: без «Гурьян»га «Гүрҗән», «Прокопий»га «Күпей», «Ульяна»га «Үлүк», «Арина»га «Үркәй», «Кристина»га «Керечтей», «Корнелий»га «Курый», «Антон»га «Унтый», «Татьяна»га «Татук», «Ефим»га «Җәпей», «Лев»ка «Элүп», «Терентий»га «Терәнтей», «Кирилл»га «Киркук» яки «Кируш», «Дарья»га «Даржа», «Мария»гә «Маржа» дип дәшәбез.

Гадәттә, һәр авылда бер үк исемдә ике яки берничә кеше була. Бу бездә дә шулай. Әмма безнең авылда аларны тәгаен аерып йөртү һәм мөрәҗәгать иткәндә бер-берсен бутамау өчен игезәк исемлеләрнең

һәркайсына аерым-аерым исем әйтелеше тагалар. Әйтик, авылдагы ике «Кузьма»ның берсен «Көҗмә» дип, икенчесен «Көҗей» дип йөртәләр. «Афанасий»ларның берсе «Апанае», берсе «Әппин» була, «Константин»нар — «Кечтәнтей» һәм «Күчтә», «Анастасия»ләр «Начта» белән «Начтук» дип аерып йөртелә.

Бер үк исем өч һәм аннан да күбрәк кешегә бирелсә дә, аптырап калмый безнекеләр, һәрберсен аерып булырлык, бер-берсе белән бутамаслык исемнәр табалар. Элегрәк авылда «Александра» дигән хатын-кыз исеме аеруча күп иде. Бер үк чорда бишәр Александра булуын хәтерлим мин. Әмма авыл кешеләре аларны биш төрле исем белән йөртә: «Әләксандыра», «Сандыра», «Сандырый», «Санук», «Әләч». Дүрт Григорийны «Гөргөри», «Гүрей», «Герүк», «Гөрей» дип аерып йөртәләр.

Беренче ишетүче кешегә безнең авыл кешеләренең әнә шулай сөйләшүен тыңлап тору үзенә бер мәзәк булып тоелыр. Әмма мин авылыбыз телен татар халкының борынгы төрки сыйфатын иң нык саклаган бер кыйпылчыгы дип карар идем.

*Григорий Родионов*

**ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР**

## Өч Микулы

***Язгы Микулы*** *(22 май)*. Микулы көннәре архиепископ Николай Чудотворец исеме белән бәйләнгән. Ул могҗизалар тудыручы, Алладан соң кешеләрне икенче яклаучы, игенче һәм терлекчеләрнең химаячесе, су хуҗасы дип санала. Бездә ул борынгы грекларның диңгез патшасы Посейдонын һәм римлыларның Нептунын алыштырган. Элек авыл халкы язгы кыр эшләренә Микулының ничек килүенә карап керешкән.

*Микулыдан соң 12 тапкыр кырау була.*
*Микулы көнне бакалар кычкырса, солы уңа.*
*Микулыга кадәр карабодай чәчәргә, сарык йонын алырга ярамый.*
*Микулыга кадәр коенырга ярамый.*
*Микулыда атларны кырга куалар.*

***Май***

— Искечә 23 нче апрельдә (5 нче майда) иртә белән чык күп төшсә, карабодай уңар.
— Искечә 6 нчы майда чык булса, кыярга туклык.
— 9 нчы майда бака кычкырса, солы тишелә башлый. Тугызында җил булса, бөтен җәй җилле булыр.
— 10 нчы май көнне яңгыр булса, бөтен җәй яңгырлы булыр.
— 11 нче майда юеш булса, бөтен җәй юеш булыр.
— 13 нче майда озынборын чыга.
— 19 нчы майда кыяр утырт.
— Май ае салкын булса, игенгә туклык булыр.
— Майның яңгырлы булуы игенчегә файда, җимешкә зыян.
— Майда яңгырлар күп булса, арыш уңар.
— Кояш бату белән, караңгылык төшсә, яңгыр булыр.
— Яңгыр буласы, көн бозыласы булса, казлар-үрдәкләр су өстендә җәяү йөгерер.
— Микулы (искечә 9 нчы май һәм 6 нчы декабрь) җитми, җәй булмый, Микулы җитми, кыш булмый.

Май климаты табигатьнең чын мәгънәсендә яшәрүе, чәчәк атуы өчен бөтен уңай шартларны тудыра. Карлар инде тәмам эреп беткән, көннәр кояшлы, җылы, якты. Хәзер төннәрен дә һава артык суынмый. Дөрес, май аенда салкыннар да булып алгалый. «Майда туның калдырма, кышын үзең белерсең»,— диләр ич. Аерым елларда хәтта кар яву очраклары да күзәтелгәне бар. Тик бу — кыска вакытлы күренеш. Яшен яшенләп, күк күкрәп җылы яңгырлар явып узганнан соң, кояшның шифалы нурлары астында чирәмнәр, үләннәр, уҗым һәм сабан ашлыклары бердән күтәрелеп китә. Җир өстенә яшел келәм ябып куйгандай була, ә төрле төсләрдәге хисапсыз-сансыз чәчәкләр гүя шул келәмдәге нәкыш-бизәкләр булып балкый. Майның «яшел яз» дигән сыйфатламасын раслап, урманнарда, әрәмәлекләрдә, бакча һәм паркларда бер-бер артлы агачлар, куаклар яфрак яра башлый. Ә шомырт һәм сиреньнәр инде чәчәк атып та өлгерә. Озак та үтми, җимеш бакчалары да шау чәчәккә күмелә. Әмма язгы табигать хозурлыгы өчен болар гына җитмәсен сизгән шикелле, май башында җылы яклардан назлы кунаклар — кәккүкләр, карлыгачлар, сандугачлар кайтып җитә. Сынамышларда әйтелгәнчә, майның яме күке белән. Күке текелдәмичә, май хәтта җылынмый да икән. Ә сандугачның теле каен яфрагыннан чык суы эчкәч кенә ачыла икән...

Халык календаренда май яз белән җәйне кавыштыра торган ай буларак та искә алына. Май ахыры — ул инде чынлыкта җәй башы да. «Микулы җитми, җәй булмый» дигән сынамышны хәтерегезгә төшерегез. Микулы яңа стиль буенча 22 нче майга туры килә.

Чәчү өстендә вакытның һәр сәгате алтындай кыйммәт. «Бер көн алдан чәчсәң, бер атна алдан урырсың»,— ди халык. Май сынамышларында без, барыннан да элек, алдагы уңыш язмышы турында зур кайгыртучанлык күрәбез (сынамышлар иске стильдә бирелә):

Май ае салкын булса, игенгә туклык булыр, чебенгә юклык булыр.
Майда яңгырлар күп булса, арыш уңар.
Майның яңгырлы булуы игенгә һәм печәнгә файда, җимешкә зыян.
Алтынчы майда чык булса, кыярга туклык.
Тугызынчы майда бака кычкыра башлый, солы тишелә башлый.
Тугызынчы майда бәрәңге утырт.
Тугызынчы майда җил булса, бөтен җәй җил булыр.
Унберенче майда юеш булса, бөтен җәй юеш булыр.
Унтугызынчы майда кыяр утырт.
Майның егерме берендә яңгыр булса, көз яңгырлы булыр.
Егерме тугызынчы майда арыш баш җибәрә.

*Александр Филиппов*

## Каргышлар

Каргышлар* — татар халык авыз иҗатының сирәк очрый торган жанры. Башка төрки халыкларда ул әдәби жанр дәрәҗәсенә күтәрелсә дә (мәсәлән, кыргызларда), бездә тәмам онытылып бара. Хәзер инде каргыш дигән сүз үзе дә аерым бер кешене, күренешне, вакыйганы каһәрләү, ягъни сөйләүченең объектка карата кире мөнәсәбәтен белдерү мәгънәсендә генә сакланып калган. Ләкин ул элегрәк заманнарда теләкнамә, үгет-нәсихәт, васыятьнамә, мактау өчен дә кулланылган. Шулай да, кагыйдә буларак, каргышта трагизм өстенлек итә.

Каргыш әйтүнең билгеле бер ныклы калыбы бар: патетик пафосы, стиле, экспрессивлыгы бу жанрны форма ягыннан тотрыклы итә. Ләкин каргышлар эчтәлек ягыннан тотрыклы һәм массовый түгел. Каргыш әйтүче һәр кеше, бу жанрның формасын нык саклаган хәлдә, аңа үз фикерен, үз эчтәлеген, үз образын сала. Чөнки каргышлар күбесенчә гадәти булмаган конкрет хәлләр, язмышлар, күренешләргә багышлана. Шул ук вакытта каргышлар шушы тирәлеккә билгеле кешеләргә, күренешләргә, тормыш-көнкүрешкә тирән эз салып киткән вакыйгаларга төбәп әйтелә.

Каргышлар бик борынгыдан, мәҗүсилек чорыннан ук калган жанр булса кирәк. Чөнки, беренчедән, алар арасында табигать күренешләренең гадәти булмаган очракларына багланышлылары күп очрый (ай, кояш тотылу, койрыклы йолдызларның Җиргә якын килүе, корылык, су басу, давыл, янгын, гомуми үлем-җитем), икенчедән, каргыш әйтүче гарәп-фарсы сүзләрен бөтенләй кулланмый диярлек. Ә бу күренеш аның татар халкына ислам дине кергәнче үк яшәгәнен күрсәтә. Соңгырак чорларда каргышларның ил язмышы, иҗтимагый вакыйгалар белән дә бәйләп әйтелә башлавы, аның мәҗүсилек эчтәлегеннән иҗтимагый-дөньяви эчтәлеккә таба үсешен күрсәтә булса кирәк.

Каргышта, кагыйдә буларак, трагизм өстенлек итә. Шуңа күрә, ахры, Бөек Ватан сугышы елларында безнең авылда (Лениногорск районы Аланлык авылы) каргышлар шактый активлашып китте. Әле хәзер дә, халыкара хәлләр кискенләшкән вакытларда, керәшеннәр арасында сугышка каршы каргышлар әйтелә.

Түбәндә тәкъдим ителә торган әсәрләрдә каргыш жанрының даими калыпларыннан читкә китkәләүләр бар. Чөнки автор монда халыкта яши торган төп-төгәл каргыш формасын күрсәтүне төп максат итеп куймады, ә шул жанр нигезендә яңа әдәби әсәрләр тудыруны күздә тотты.

## Сугыш кырында ятып калган этиләр каргышы

Әй улым, илләр күреп кайт, җирләр күреп кайт, ирләр күреп кайт, дөньяда ни булса, барын да күреп кайт, ләкин мин күргәннәрне күрмә!

Баллар таты, ширбәтләр таты, майлар таты, җимешләр таты, иреннәр таты, дөньяда ни тәм бар, барын да таты, ләкин мин татыганнарны татыма!

Сандугачлар сайравын ишет, үзәк өзгеч симфонияләр ишет, гомердә ишетмәгән халык җырларын ишет, дөньяда ни моң бар, барын да ишет, ләкин мин ишеткәннәрне ишетмә!

Мин күргәннәр, мин татыганнар, мин ишеткәннәр барысы да — Кешелек өчен мыскыл, адәм хуры. Мин күргәннәрне, мин татыганнарны, мин ишеткәннәрне сөйләсәң — сүз җитмәс, язсаң — кәгазь җитмәс, еласаң — күз яше җитмәс, эчтән тынсаң — тын җитмәс.

И углым!

Тау-ташларны актарып алтыннар эзлә, нефть эзлә, металлар эзлә, күмер эзлә; тирән су төпләренә төшеп, мәрҗәннәр эзлә, алтын балыклар эзлә, файдалы суүсемнәр эзлә; иксез-чиксез галәмнәр гизеп, яңа дөньялар эзлә, яңа планеталар эзлә, яңа Айлар эзлә, яңа Кояшлар эзлә — дөньяда ни кызык бар, ни сер бар, барын да эзлә, ләкин беренче чиратта безнең каберләрне эзлә.

### Каргыш-теләкнамә

Тормыш-яшәеш!

Җирсезләргә — җир бир, илсезләргә — ил бир.

Дансызларга — дан бир, шансызларга — шан бир, сансызларга — сан бир.

Телсезләргә — тел бир, котсызларга — кот бир, башсызларга — баш бир, мәнсезләргә — мән бир.

Мәзәксезләргә — мәзәк бир, фатирсызларга — фатир бир, имансызларга — иман бир, холыксызларга — холык бир.

Тормыш-яшәеш!

Адәм баласына изгелек кылучыларның теләгендә булганнарның барын да бир, ләкин мылтыклыларга — дары бирмә, әләкчеләргә — тел бирмә, сатлыкларга — ил бирмә.

### Әниләр зары

Ирләр ул гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына дип китә дә...
Югала.
Һәм еллар хәбәрләр китерә:
— Билгесез югалды...
— Приказны үтәгәндә...
— Батырлык күрсәтеп...
Малайлар гел шулай:
Чәй кайнап чыкканчы гына дип китә дә...
Югала.
Һәм көн дә газетлар хәбәрләр китерә:
— Тайгада шәһәрләр төзелә...
— Чирәм җир сөрелә...
— Космостан әйләнеп кайттылар...
Көненә ничәмә мәртәбә куела самовар.
Көненә ничәмә мәртәбә әйтелә:
— Чәй кайнап чыга бит,
Кайтырлар...
Кайтырлар...

*Гәрәй Рәхим*

#### КЕРӘШЕН МӘГАРИФЕ ТАРИХЫННАН

### Телен югалтмаганны тарих югалтмый

Тарих нинди генә шәхесләрне белмәгән. Араларында, үзе исән чакта макталып, данланып та, үлгәннән соң онытылганнары да бар. Кайсылары, гомере буе халыкка хезмәт итеп тә, ул халык тарафыннан эшенә тиешле бәя ала алмыйча, үлгәч тә макталмаган. Иң яманы: бүген дә кемнәрдер аларны үзе хезмәт иткән халык күңеленнән сызып ташларга, онытырырга тырыша.

Сүзебез рус миссионеры, кайбер угро-фин һәм төрки халыкларының грамматикасын төзүгә зур өлеш керткән олуг тел галиме Николай Ильминский — гомеренең 35 елын Идел-Кама буйларында яшәгән христиан динендәге халыкларны укытуга, аң-белем бирүгә, агартуга биргән мәгърифәтче турында. Шушы

еллар арасында аның җитәкчелегендә һәм
катнашында татар, чуваш, чирмеш, ар, мордва, кыргыз (революциягә кадәр казакъларны шулай атап йөрткәннәр), алтай, бурят, тунгус, якут һ. б. телләренә дә тәрҗемә ителеп
184 мәртәбә басылган хезмәтләре бар. Тәрҗемәләренең күбесе (184 нең 49 ы) керәшеннәр өчен бастырып чыгарыла.

Бүгенге көндә бу кеше турында татар матбугатында уңай фикер әйтүче булмаса да, без аның эшчәнлегендәге кайбер — үзебез уңай дип санаган — фикерләрне әйтеп китәргә бурычлы.

Тарихтан билгеле булганча, керәшеннәрнең яшәеше, рухи һәм культура үсеше, гомумән, 18 нче йөзнең 60 нчы елларына кадәр язмыш иркенә тапшырылып, керәшен халкы ятимлек авырлыгы кичерә. Кан кардәшләр булып та, диннәре төрле булганлыктан, христиан динендәге татарлар белән мөселман динендәге татарлар арасында мәдәният таратучы уртак үзәк (мәктәпләр, газета һәм журналлар, китаплар һ. б.) булмый. Икенче яктан, керәшеннәр, диннәрендә күп кенә уртаклыклар булуга карамастан, телләре төрле булу сәбәпле, руслар белән аралашып, якынаеп яши алмаган.

Н. И. Ильминский беренчеләрдән булып  керәшеннәрне үз ана телләрендә укытуга алына, рухи үсешенә юл ача. Үз язулары булмаган керәшеннәр өчен рус хәрефләренә нигезләп, 1862 нче елда беренче алфавитны төзи. Мамадыш өязендә яшәгән керәшеннәрнең сөйләменә нигезләнеп төзелгән бу әлифбадагы сүзләрнең язылышын фонетик принципка нигезләп, татар халкының авазларны әйтүдәге үзенчәлекләрен дөрес аңлап, тоеп, сүзләрнең язылыш кагыйдәләрен дүрт ел дәвамында кайта-кайта эшкәртә, камилләштерә. Алфавитка кайбер авазларның билгеләрен (ө, ә, ү, ң, в, я, ю, е хәрефләрен) кертә. Телебезнең асыл законына — сингармонизм законына төшенә. Шуңа нигезләп, керәшеннәр өчен мәктәп дәреслекләре әзерли. Шуның белән керәшен язуында һәм телендә төрки телләрдә аралашучы халыкларның сөйләмендәге күп кенә уртак үзенчәлекләрне саклап кала ала.

Керәшеннәр өчен беренче мәктәпләр дә Н. И. Ильминскийның соравы һәм катнашы белән ачыла. Ул мәктәпләрнең (хәтта, керәшеннәр үзләре дә белмәгән!) йөз еллык тарихы бар. Бүгенге галимнәрнең күпчелеге керәшен мәктәпләрендә «руслаштырылган» балаларның исәбен саннарда күрсәтә алмасалар да, булган керәшен мәктәпләрен руслаштыру урыны итеп язуларны дәвам итә. Укыту программаларында башлыча христиан дине өйрәтелеп тә, укыту ана телендә алып барылганда, керәшен мәктәбе «руслаштыру» урыны итеп карала аламы? Икенче бер динне өйрәнү, аңа табына башлау гына, канына мең еллар дәвамында мәҗүсилек кануннары сеңгән халыкның үзаңын, җиде бабадан килгән әдәбен, ана сөте белән бирелгән әхлагын, гореф-гадәт-йоласын алыштыра алмый.

Н. И. Ильминский фикеренчә, һәр халыкның укыту өлкәсендә эшләгән кешесе — укытучысы һәм тәрбиячесе — ул халыкның үз арасыннан чыккан, аның өчен, аның омтылышлары белән янып яшәүче, ул халыкның сөйләм телен, гореф-гадәт-йолаларын, холкын, психологиясен аңлап эшли белүче кеше генә булырга тиеш. Күргәнебезчә, тәҗрибәле педагог буларак, Ильминский тәрбиянең нәтиҗәлелеген укучы һәм укытучының бер халыктан булуыннан күрә. Шуларны истә тотып, халык арасыннан керәшен балаларын укытырлык яшьләрне сайлап алып, укытучылык эшенә өйрәтә. Керәшен авылларында беренче керәшен укытучылары күренә башлый. Моңа кадәр мәктәпнең ни икәнен дә белмәгән балалар, мәктәпләргә, чиркәү яны мәктәпләренә йөреп, христиан дине дәресләре, математикадан башлангыч белем ала, язарга өйрәнә. Чиркәүләрдә ана телендә дини җырлар җырлый башлый. Элек тә җыры, моңы булган керәшен авылларында халыкның яшәеше җанланып, тулыланып китә.

Ильминский тәкъдиме белән, керәшен балаларын укытуга хатын-кыз — табигать тарафыннан тәрбияче итеп яратылган зат тартыла башлый. Бу хәл дә керәшен балаларының мәктәпкә йөрешен арттыруга үзенә күрә этәргеч бер көч була. Керәшен интеллигенциясе барлыкка килә һәм әйдәп баручы көчкә әверелә.

Бүгенге керәшеннәрнең дөрес сөйләше — шул мәктәпләрдә укыткан һәм укыган бабаларыбыз, әбиләребезнең буыннар аша безгә җиткерелгән дөрес сөйләше ул.

Н. И. Ильминский хезмәтләрендә бүгенге көндәге керәшен «тарихына»да күпмедер ачыклык кертерлек урыннар бар шикелле. Ул да, бүгенге галимнәр кебек, керәшеннәрне иске (бәлки элеккегедер, чөнки рус телендәге «старые» сүзенең, мәгънәсен татарча шулай дип та бирергә мөмкин) һәм яңа керәшеннәргә аерып карый. Соңгылары иске керәшеннәрнең керәшенлектә калу, христиан динен алу сәбәпләрен төрле ташламалар, льготаларда гына күрсәтергә теләсә, Ильминский, үзенең күп еллык күзәтүләренә таянып — ул 35 ел гомерен керәшеннәр арасында үткәргән — һәм замандашлары (галимнәр һәм дәүләт эшлеклеләре Рождествин, Чечерина, Юзефович һ. б.) язганнарны исәпкә алып, түбәндәге нәтиҗәгә килә: элеккеге керәшеннәр ислам дине йолаларын бөтенләй белми, гарәп язуын танымыйлар. Алар, күрәсең, бер вакытта да мөселманлыкта булмаганнардыр, ди ул.

Н. И. Ильминскийны сүгүче кешеләр үзе яшәгәндә үк аз булмаган. Татарларның бер өлеше аны керәшеннәрне «руслаштырганы», рус кешеләренең кайберләре «руслаштыра алмаганы», керәшеннәрдән

ни татар, ни рус булмаган үз динле, үз гореф-гадәт-йолалы, үзенчәлекле культурасы булган этнос барлыкка китергәне өчен сүккәннәр. Кемнәрдер Н. И. Ильминский эшчәнлегендә бүген дә диннән яздыручы, халыкны бүлүче образын күрсәтергә телиләр икән — күрсәтсеннәр. Ләкин без, керәшеннәр, аның ярдәме белән ачылган мәктәпләрдә, ана телебездә укып, борынгыдан килгән үз гореф-гадәт-йолаларыбызны, үзенчәлекле культурабызны, тормыш итү рәвешен саклап кала алганбыз. Шуның өчен Н. И. Ильминскийны олылап, хөрмәт белән искә алыйк.

## Керәшен укытучылары мәктәбе

Керәшеннәрнең үз араларыннан укытучылар әзерләү максатыннан, 1863 нче елның ноябрь аенда Казанда дүрт еллык Керәшен укытучылары мәктәбе ачыла. Ачылган вакытта монда барлыгы 30 малай һәм 1 кыз укуга алына. Ә биш елдан соң укучылар саны 117 гә җитә. Мәктәптә укыту нигездә татар телендә алып барыла, рус теле, аерым фән буларак, ана теленә нигезләнеп өйрәтелә. Анда атнага 32 сәгать дәрес бирелә. Дәресләрнең сәгатьләп бүленеше түбәндәгечә: закон божий (татар телендә) — 6 сәгать, славян язуын уку — 3 сәгать, туган тел — 4 сәгать, рус теле — 6 сәгать, язу (рус һәм татар телендә) — 6 сәгать, җыр (рус һәм татар телендә) — 3 сәгать, хисап (татар телендә) — 3 сәгать, гимнастика — 1 сәгать. Казанда мәктәп ачылып озак та үтми, урыннарда аның филиаллары ачыла башлый. 1884 нче елга Мамадыш өязендәге 33 керәшен авылында, Лаеш өязендәге 11 керәшен авылында, Чистай өязендәге 10 керәшен авылында мәктәп ачыла. Мәктәпләрнең барсында да укытучы булып Казан керәшен мәктәбен бетергән укытучылар билгеләнә. 1863—1913 нче еллар арасында — 50 ел эчендә — бу мәктәптә барлыгы 6339 кеше укыган. Шулар арасыннан 4454 ир-ат, 1885 хатын-кыз булган. Ирләрнең 636 сы, кызларның 260 ы укытучы һөнәрен сайлаган. Мәктәпне бетергән 167 кеше — поп, 45 кеше — дьячок, 30 кеше дьякон булып эшләгән. Мәктәп шул дәвердә барлык керәшеннәр өчен бердәнбер культура үзәге вазифасын башкарган.

Мәктәп нәшерлек эше белән дә шөгыльләнә: керәшен мәгариф системасын дәреслекләр һәм дини китаплар белән тәэмин итә.

Керәшен укытучылары мәктәбенә нигез салучы кеше — Василий Тимофеевич Тимофеев (1836—1896). Ул 1836 нчы елда Мамадыш районындагы Никифорово (Чиябаш) авылында туган. Казандагы Духовная академиядә миссионерлык курсларын бетергәннән соң, шунда ук татар теле укытучысы итеп калдырыла. Анда күпмедер эшләгәннән соң, священник дәрәҗәсенә күтәрелә. Татар теле укытучысы буларак, керәшеннәр өчен кириллицага нигезләнгән әлифба төзи, балаларны ана телендә укыту буенча үз педагогик системасын тәкъдим итә. Аның ярдәме белән керәшен мәктәбендә беренче тапкыр дини йолалар ана телендә үткәрелә башлый. Укытучысы Н. И. Ильминский белән берлектә ул керәшен укучылары өчен русчадан берничә уку китабын һәм «Дин сабакларын» тәрҗемә итә.

Шушы мәктәп 1918 нче елда Керәшен укытучылары семинариясе итеп үзгәртелә һәм 1922 нче елга хәтле эшли.
Ә 1922—1930 нчы елларда тагын исеме алышына. Аны Керәшен педагогия техникумы итеп үзгәртәләр.

*Николай Максимов,*
филология фәннәре кандидаты

### КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН УКЫТУЧЫЛАР

*Даулей Р. П.* (Мамадыш районының Шеморбаш авылы), *Иванова Ф. И.* (Мамадыш районының Чиябаш авылы), *Игнатьев В. И.* (Мамадыш районының Зур Әртәш авылы), *Камашев И. И.* (Менделеевск районының Иске Гришкино авылы), *Мурин К. Д.* (Менделеевск районының Яңа Гришкино авылы).

### ЕЛ ФАСЫЛЛАРЫ ҺӘМ ЙОЛАЛАР

## Олы көн (Пасха)

Нинди көн соң ул Пасха? Керәшеннәр аны Олы көн, диләр. Бу бәйрәм безнең көннәргә кадәр мәҗүсилек чорыннан ук килә. Хәзер бу бәйрәм, һавадагы айның торышына карап, һәр елны төрлечә — 4 нче апрельдән 8 нче май араларындагы атна-көнгә (якшәмбегә) туры килә.

Бу көнне бөтен авыл халкы иң затлы киемнәрен кия. Олы көнгә каршы төндә хуҗабикәләр, бөтен гаилә белән бергә, тәм-томнар өлгертә. Олы көн йомыркасы пешерү — иң изге йолаларның берсе. Мария

Магдалинага кагылышлы риваятькә караганда, ул кызыл төскә манылырга тиеш. Эңгер-меңгердә балалар, өйдән өйгә кереп, йомырка җыеп йөри башлыйлар. Керә-керешкә алар: «Христос яңадан туган!» — диләр. Ә хуҗалар аңа: «Чыннан да яңадан туган!» — дип җавап кайтаралар һәм бүләкләр бирәләр.

Пасха — Гайсә Коткаручының яңадан тууы хөрмәтенә үткәрелә торган зур дини бәйрәм. Халыкта Пасха төне һәм иртәнге гыйбадәт вакыты белән бәйле табигатьтән өстен көчләргә ышанулар, сынамышлар, гореф-гадәтләр яши. Әйтик, бу төнне, имеш, бөтен җен-пәриләр мәче, эт һәм дуңгызга әверелә, дип уйлыйлар. Шуңа күрә кешеләр төнлә ишегалдына яки урамга чыгарга куркалар. Ә иртәнге гыйбадәт вакытында нәрсә теләсәң, шул тормышка аша, дип фаразлыйлар. Ул иртәдә кызлар яхшы кияүгә чыгуларын, аучылар зур табыш, мохтаҗлар байлык килүен телиләр һ. б. Куркыныч юрамышлар да бар. Мәсәлән, Пасханың беренче көнендә кем дә булса нәрсәдер вата икән, ул кеше шушы елны үлә, диләр. Бу көнне савыт-сабалар белән эш иткәндә бик сак кыланалар.

Пасханы бәйрәм итү атна буена сузыла. Яшьләр төрле күңелле уеннар, күмәк күңел ачулар оештыралар, кунакка йөрешәләр. Олы көн өчен генә хас уеннар бар. Төрле төскә манылган йомырка отышлы уйнау — дауларның берсе. Бездә җиргә бер рәткә тезеп куелган йомыркалар өстенә чүпрәктән тегелгән яки сыер йонынынан әвәләнгән туп тәгәрәтеп җибәрәләр иде. Туп йомырканы аударса — отасың, тимәсә, уенны синнән соңгы кеше дәвам итә.

Пасха бер генә авылда да тагансыз узмый. Таган ел саен бер урында корыла һәм анда хәленнән килгән бөтен кеше атына. Таганнан читтәрәк җырлы-биюле әйлән-бәйлән уеннары оештырыла.

## Симек

Симек Олы көннән соң җиденче кече атна көнне, тройсынга ике көн калгач, зур бәйрәм итеп үткәрелә. Күп кенә керәшен авылларында аның Яфрак бәйрәме итеп үткәрү йоласы буларак саклануы да язны озатып, җәйне каршылау көне булуына ишарәли. Бу көнне авыл каен, өрәңге ботакларыннан, урман-кыр чәчәкләреннән яшеллеккә төренә. Иске йола, гореф-гадәтләрне саклаган авылда, иртәнге якта зиратка барып кайткач, төштән соң кызлар кулъяулык, сөлге, төрле төстәге тасмалар белән бизәлгән каенны күтәреп, урам буйлап җырлап йөргәннәр. Күңел ачу өчен билгеле бер йорт сайланган. Анда яшьләр ризыклар, колмактан коелган өй сырасы, әче бал алып киләләр. Яшьләр, шушы йорт ишегалдына кадап куелган каенны күтәреп, яңадан урманга яки чишмә буена төшеп уен оештыралар. Күмәк җыр, бию, такмак, саф һаваны яңгыратып, кич буе дәвам итә.

Симек көнне кызлар каен себеркесе бәйләп, аны агымсуга ташлаганнар. Кемнең себеркесе яр буена барып төртелә, ул бу елны кияүгә чыкмыйча утырып кала, кемнеке батса, ул я үлә, я аның сөйгәне бүтәнгә карый, ә йөзеп китсә, бу кызның сөйгәне аның турында уйлый, сагына, дип фараз кылына.

### ***Июнь-июль***

Сагынып көтеп алган ямьле җәй җитте. Элек июньне җирле календарьда, нәкъ үз асылына туры китереп, «җәй ае» һәм «чәчәкле ай» дип атаганнар. Календарь җәйдән тыш,
бу айда әле астрономик җәй дә башлана. Анысын 22 нче июньнән — җәйге кояш торгынлыгы көненнән исәплиләр.
Бу вакытта инде көн озынлыгы иң соңгы чигенә җитә — «сәгать унҗидене суга», ә төн исә «бер саплам» кадәр генә булып кала.

Урманнарда, болын-тугайларда хәзер күпме ямь, никадәр гүзәллек! Тукай әйтмешли, «ак күмәч белән ашарлык саф һава». Бөтен тирә-юнь ямь-яшел. Кая гына карама — аллы-гөлле чәчәкләр. Берөзлексез кошлар моңы агыла!..

Июнь аеның аерым көннәре халык календарендагы мөһим даталар булып санала:

Сәгать унҗидене суккан көнне иртә чәчкәнең җитсә дә, кич чәчкәнең җитмәс (ягъни өлгермәс).

Унҗиде сәгать көн озайган көнне яңгыр булса, ашлык яхшы булыр.

Унҗиде сәгатькә тикле яхшы җылы яңгыр яуса, икмәк басуга сыймас.

Егерме сигезендә яңгырлы — җиде атна яңгырлы.

Игътибар итегез: сынамышларның күбесендә сүз явым-төшемнәр тирәсендә йөри. Яңгырлар белән бәйләнештә табигать календареның борынгырак сәхифәләренә дә күз салып узу урынлы булыр. Элекке заманнарда корылыклы елларны, «су юллары ачылсын өчен», кояшка, болытка багышлап ак яки кара терлек корбан иткәннәр. Халык каршында ак төс — иминлек, пакьлек, кара төс яңгыр символы булып йөргән. Күрәсең, мондый төсләр сайланышында суның аклыгы, болытның каралыгы исәпкә алынгандыр. Инде безгә таныш булган «Көтү килгәндә, алдан кара сыер килсә, болытлы булыр» дигән ышану да шул

хакта сөйли. Яңгыр теләгәндә, терлек чалудан тыш, тагын яңгыр боткасы пешерү йоласы да киң таралган булган. Җәй көне озак вакыт яңгыр яумый торса, өй саен йөреп, ярма һәм сөт, май ише әйберләр җыйганнар да, су буенда ботка пешереп, шуны олысы-кечесе бергәләп ашаганнар. Аннары кемне дә булса киемение белән суга ыргытканнар, узган-барганнарга чүлмәкләр, чиләкләр белән су сибеш башланган. Бу вакытта «Чүлмәк-чүлмәк май кирәк, чиләк-чиләк яңгыр кирәк» шикелле такмаклар әйтелгән. Моннан тыш, яңгырга мөрәҗәгать итеп әйтелә торган махсус теләү текстлары да булган:

Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Илгә ачлык килмәсен,
Ачтан халык үлмәсен,
Чума чире йөрмәсен.

Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Иген-ашлык күп булсын,
Башаклары тук булсын,
Кибән-эскерт зур булсын.
Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын,
Сөтле сыер абзарда,
Бар да булыр яуганда.
Яңгыркаем, яу, яу, яу!

Июнь ае кызыклы календарь йолаларга, аграр даталарга никадәр бай булса да, алар арасында иң күңелле бәйрәм,— әлбәттә, сабан туе! Дөрес, әүвәлгерәк чорларда ул язгы чәчүгә кадәр үткәрелеп килгән. Сабан туена чакырып, сөрән салып йөргәндә, малайлар: «Сөрәнгә, сөрәнгә, сөрәнгә! Сөрән беткәч, сабан, сука төрәнгә»,— дип такмаклый торган булганнар. Ягъни сабан туе узу белән, крестьян сөрергә керешкән. Революциядән соң, бигрәк тә колхозлар оешкач, сабан туйларын язгы эшләрне тәмамлагач, җәйнең беренче аенда уздыру гадәткә кереп китте.

Сабан туена әзерләнүдә һәм аны уздыруда элек-электән килә торган йола-традицияләр бар. Магик эчтәлегеннән аерып караганда, барыннан да элек, ул — язны каршылау, язгы хезмәт алдыннан уңганлык, осталык, көч-җитезлек сынашу, күңел ачу бәйрәме.

*Александр Филиппов*

### Торойсын — җапрак бәйрәме

Торойсын. Төшемдә күрдем:
Атылган йолдыз сыман
Сызылып үтте яшьлегем
Абайлар турысыннан.

Җапрак бәйрәмнәре җитсә,
Ләкедә, Торойсында
Җыела идек уенга
Абайлар турысына.

Ияреп, кайчак, бәйрәмнең
Өлкән кунакларына
Кузгала идек Багыраж,
Я Сарсаз якларына.

Юк иде юкса ул якта
Туган да, тумача да.
Куныплар йөрдек шул чакта
Туганнар булмаса да.
Бәйрәмнәр төптән бүленгән,
Аталып авылларга:
Питравы —Ләкеләрнеке,

Torойсын — Багыражга.

Кемгә — кум, кемгә — печкәчәм,
Кемгәдер кода килә.
Иртәдән алып кичкәчә
Аш йөри өйдән өйгә.

Кемгә — бал, кемгә — пүрчинкә,
Табында бар булганы.
Гаҗәеп кунакчыл иде
Керәшен авыллары.

Үз көе бала-чаганың,
Үсмернең үз кызыгы.
Ә кырда, алан, яланда
Яшьләрнең үз уены.
Егетләр, кызлар ярыша,
Җыр аша сер, сүз куша.
Күз кыса, ымнар кагыша,
Парлаша, озатыша.

Суларда кызлар «яр бага»:
Кемгә кем кайчан китә?
Торойсын кушкан парларны
Покрауда туйлар көтә.

Торойсын. Җапрак бәйрәме.
Яшь каен яфраклары.
Күңеленнән китми кемнең дә
Беренче сөйгән яры.
Тик анысы миндә булмады,
Минем бит, әйтсәм әйтим,
Туп-туры икенчесеннән
Башланды мәхәббәтем.

Аның беренче дигәне
Шул ерак Торойсында
Ничектер югалып калды
Абайлар турысында.

Ә бүген кайтты төшемдә
Яңадан җанны сызып,
Абайлар йорты өстеннән
Атылган йолдыз булып.

*Клара Булатова*

## Питрау

Июль — төрле йола һәм гореф-гадәтләргә иң бай айларның берсе дисәк, һич тә ялгыш булмас. Питрау — шуларның иң мәртәбәлесе. Аннан бер атна алдан — 6 нчы июльдә килә торганы Аграфена Купальница, 7 нче июльдәгесе Иван Купала көннәре дип атала. Питрауга кадәр кайбер урыннарда Давыт, Самсон көннәрен билгеләп үтәләр. Болар барысы да Питрауга әзерлек рәвешендә уза. Әйтик, Аграфена көнендә ел буена җитәрлек итеп мунча себеркесе әзерлиләр. Дару үләннәре һәм тамырлары җыялар. Кызу парлы итеп мунча ягалар. Бу эшләр Иван Купала көнендә дәвам итә. Ике көндә дә күмәкләшеп су коену оештыралар. Елга буйларында яр өстендә төнлә учак ягып, аның тирәли бииләр, ялкын өстеннән сикереп чыгалар.

Питрау һәр елны 12 нче июльдә билгеләп үтелә. Бу көнне ике атналык Питрау уразасы тәмамлана. Питрау ул — Гайсә Коткаручының ике шәкерте Петр һәм Павелны искә алу көне. Петр һөнәре буенча балыкчы була. Шуңа күрә күп җирләрдә балыкчылар аны үзләренең һөнәри бәйрәмнәре буларак та билгеләп үткән. Сүз уңаеннан әйткәндә, бу атна эчендәге бәйрәмнәрнең барысы да суга бәйләнешле.

«Евангелие» язмаларына караганда, Петрның апостоллык гомере гаять катлаулы, дулкынландыргыч, фаҗигале вакыйгаларга бай була. Петр һәм Павелны Рим императоры Нерон әмере буенча, Мамертина зинданына ябып куялар, Петрны
57 нче еллар тирәсендә әлеге зинданда качка кадаклап, укытучысы кебек үк газаплап үтерәләр. Аны озатып йөрүче хатыны да шундый ук җәзага тартыла. Петр Палестинадан читтә яшәүче яһүдләргә ике мөрәҗәгать — хат язып калдырган. Павел да ун елдан соң шул ук Нерон әмере белән газаплап үтерелә. Аның төрле затларга һәм халыкларга язган 14 хаты бар. Аларның һәркайсын «Библия» китабыннан табып укырга мөмкин.

Петр һәм Павел көне мәҗүсилек чорыннан ук килә торган бәйрәмнең дәвамы булырга тиеш. Питрау ул — җәйнең нәкъ кыл уртасы. Питрау көнне тереклек һәм үсемлекләр дөньясында үзгәреш чоры башлана. Бу көнне нәкъ төш вакытында барлык кошлар сайраудан туктый. Бу көнне җыеп киптерелгән кыр чәчәкләрен кайнатып эчсәң, барлык авыруларың китә, диләр. Бу айда туган балаларга күбрәк Петр яки Павел исемнәре кушалар.

Күп кенә керәшен авылларында бу көнне Питрау тәкәсе — корбан чалу гадәте хәзер дә сакланып калган. Иртәнге якта басудан кыр чәчәкләре җыеп алып кайтып, өй эчен, капка һәм коймаларны бизәү дә — матур гадәтләрнең берсе.

Питрауда ерак авылларда яшәүче туганнар бер-берләренә кунакка йөрешә. Кичке бәйрәм өстәле янына бары тик өлкәннәр һәм картлар гына утыра. Яшьләр төнне болында, кырда яки урман аланында күңел ачып үткәрә, төрле уеннар оештырыла. Бу «Кояш каравыллау» дип тә атала. Бу иртәдә һәркем кояш чыкканын күреп калырга тырыша. Чөнки бу иртәдә ул уйный, нурларын төрле төсләргә манып сибә икән. Безнең якларда Зичәбәш, Кабан-Бастырык, Дүрт Мунча, Түбән Биш, Әхмәт, Кадер, Борды һәм башка күп кенә авылларның керәшен яшьләре Шыкмай авылы янындагы биек Чабак тавы түбәсенә җыелалар иде. Анда таңга кадәр җыр, бию, гармун тавышлары тынып тормый иде. Андагы күрешүләр, танышу һәм вәгъдәләр гомер буена онытылмый.

Соңгы елларда Питрау бәйрәмен олылап билгеләп үтү матур гадәт булып яңадан кайта.

*Александр Филиппов*

* * *

Әй җырладык болын уртасында
Ун классны тәмамлаган көндә.
Балачакны җырлап озаттык без —
Елыйсы да килде, көләсе дә.
Туйлар җитте. Безнең биюләргә
Чыңлап торды ишек көләсе дә.
Егет чакны биеп озаттык без —
Елыйсы да килде, көләсе дә.

Балалар да үсте, мәйдан буйлап
Үтә алар чорның киләсенә.
Алар килә, безнең яшьлек китә —
Елыйсы да килә, көләсе дә.

Шомыртларны ак күбеккә күмеп
Тыелгысыз ярсу язлар килә.
Тагын бер яз кимеп калды бездә...
Юк, елыйсы килми... көләсе дә.

*Гәрәй Рәхим*

## Галина Казанцева

Татарстанның халык артисткасы Галина Александровна Казанцева Тукай районының Керәшен Маҗыны авылында 1953 нче елның 12 нче ноябрендә туган. Чаллы шәһәренең М. Вахитов исемендәге урта мәктәбен, Әлмәт шәһәренең музыка училищесын, Казан дәүләт консерваториясе профессоры Зөләйха Хисмәтуллина классын тәмамлаган. Ул — 20 ел буе М.Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында эшләп, татар опера сәнгатенә зур өлеш керткән шәхес. Ул бүген дә актив иҗади эшчәнлек белән яши. Татарстан районнарына концертлар белән чыга. Татар, рус, керәшен халык җырларын, классик әсәрләрне зур осталык белән башкара. Аның Казан һәм Чаллы шәһәрләренең зур залларында оештырылган бенефислары зур уңыш белән узды. Күптән түгел Төркиядә Бөтендөнья төрки халыклары корылтаенда булып, анда мәдәният секциясендә доклад ясап һәм күп кенә җырлар башкарып, бөтен төрки дөньяга керәшеннәрнең барлыгын танытты.

Җырчы иҗатына карата уңай бәяләмә ул — витаминлы җырлар дип әйтү. 16 яшьлек Галинага мондый матур сүзләрне Әлмәт музыка училищесына укырга керергә баргач, композитор һәм җырчы, шушы уку йортының директоры Мәсгут Имашевтан ишетергә туры килгән.

Болай була бу. Әлмәткә чибәрлеккә чамасыз, җил чыкса, күбәләктәй очып китәрдәй кыска буйлы чандыр бер кыз җырлый-җырлый барып төшә. Музыка училищесын эзләп таба. Коридорлар, аудиторияләр тып-тын. Абитуриентлар, имтихан тотып, өйләренә таралган. Галина директор ишеген шакый. Эчкә уза. Ишек тоткасын кулыннан ычкындырмаган килеш сүзен башлый:

— Имтиханнар беткән икән, Чаллыда без моны белмәдек,— ди ул.— Миңа сезнең училищега керергә кирәк, җырларымны тыңлап карагыз, зинһар!

— Балакаем, бигрәк яшь бит әле син, тавышсыз калсаң, гомер буе үкенергә туры килмәгәе,— дип кисәтә директор.— Бераз үсә төшкәч килерсең...

— Тыңлагыз инде...

— Җырлап кара соң алайса.

Берне җырлый Галина, икене, өчне... Директор абзый һаман, җитәр инде, дими. Ике сәгать буе җырлый ул. Кайчандыр отып калган җырлар искә төшеп кенә тора. Мәсгут Имашевның күңелендәге уе тышка бәреп чыга:

— Витаминлы җырлар! Алам! — ди ул.

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Татарстанның атказанган артисты Г. Казанцеваның 20 еллык иҗат эшчәнлегенә багышланган «Көмеш чыңлы моңнарым» дип аталган бенефисы бара. Шунда сәхнәгә моңлы җырлары белән халык күңелен яулаган җырчы һәм композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мәсгут Имашев күтәрелә. Сәхнә йолдызының остазы һәм укытучысы моннан чирек гасыр элек Галинаның үзенә генә әйткән сүзләрен, алма төшәрлек урын да калмаган залдагы тамашачыларга карап, яңадан кабатлый: «Галина Казанцева гына башкара ала торган витаминлы җырлар». Шаярып кына әйтелгән сүзләр кебек үзе. Ә уйлап карасаң, никадәр тирән мәгънә ята икән бу сүзләрдә. Артист үз халкына бирелеп хезмәт итә. Тамашачы аны ярата. Сәхнәгә чыккан саен алкышларга, чәчәкләргә күмә.

Г. Казанцеваның иҗат кичәсендә А. Шутиков җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры да катнашуы, әлбәттә, нур өстенә нур булды.

Шулай да Г. Казанцева иң беренче нәүбәттә нинди җыр башкарыр? Тамашачы монысын да фаразлый һәм ялгышмый. Әлбәттә инде, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан Алтынчәч ариясен.

Консерваториядә укыганда Г. Казанцева Нәҗип Җиһановның иң хөрмәт иткән студентларыннан берсе була. Монысы инде, әлбәттә, үзенең өметле җырчы икәнлеген раслаганнан соң. Ә аңа кадәр... Әлмәттән аны юллама белән Татар дәүләт филармониясенә җырчы итеп җибәрәләр. Камал театры да аны җырчы артист итәргә тели. Тик ул башка юлны сайлый — консерваториягә юл тота. Ә анда документларны кабул итмиләр.

— Министр рөхсәте кирәк,— диләр аңа.— Үзегез барып сөйләшеп карагыз...

Бара. Күрә министрны. Аңлата. Каршы төшәләр.

— Мин укырга тиеш,— ди ул, кызып китеп,— сезнең минем бу теләгемә каршы төшәргә хакыгыз юк. Бу минем конституция белән беркетелгән хокукым...

— Казанцеваның документларын алыгыз!

Буй җитмәс кебек тоелган консерваториягә кереп, имтиханнар тапшыру өчен телефоннан әйтелгән шул сүзләр дә җитә.

Казан тамашачысы җырчы Г.Казанцеваны иң беренче М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә Н. Җиһановның «Алтынчәч» әсәреннән төп рольне — Алтынчәч ариясен башкарганда күреп

ала һәм үзенең югары бәясен бирә. Бу көнне аны иң нык алкышлаучы, тәбрикләүче Зөләйха Хисмәтуллина булгандыр. Күп кенә танылган артистлар кебек, Галина да аның мәктәбен узган җырчы.

Ә аңа кадәр... Шундый зур сәхнәгә менгәнчегә кадәр, әлбәттә, тавышың, җырларың нинди генә колоритлы булмасын, консерваторияне тәмамларга кирәк. Галина монысын да «җырлап кына» уза. Ул елларда консерваторияне тәмамлагач, яшь җырчыларның бөтенесен бер театрга җыеп, ярминкә үткәргәннәр. Җырчылар базары, ягъни мәсәлән. Бу турыда сөйләгәндә, ни өчендер, тарих китапларында язылган борынгы Римдагы коллар сату базары күз алдына килә. Бик үк шәп чагыштыру түгел, билгеле, ләкин шуңа охшашлыгы булгач, нишлисең... Әлбәттә, ул базарда таза, көчле беләкле коллар югары бәядән сатылган.

Шулай итеп, ярминкә булгач, ярминкә. Бу кадәресе артистның сәхнә арты тормышына кагыла торгандыр. Әмма анда да гыйбрәтле хәлләр күп була бит. Галиналар чыгарылышының ярминкәсе Свердловскида була. Бөтен Союздан җыелганнар. Сәхнәдә — әле беркая да эшкә урнашмаган кичәге студентлар. Кемнең кая китәсен бүгенге «базар» хәл итәчәк. Залда илнең төрле театрларыннан җыелган режиссерлар, театр директорлары... Һәм дә яшь җырчыларның укытучылары. Монда инде һәркем үзенең театрына кирәкле артистны, энә күзеннән үткәреп, сайлап утыра. Теге яки бу театрдан килгән вәкил эшкә билгеләү комиссиясенә, үзенә ошаган артистны сорап, гариза язып бирә.

Сәхнәгә Галинаны чакыралар. Зал шаулап куя. Монысы аның үз-үзен тотышына, чибәрлегенә беренче бәя була. Рус театры сәхнәсеннән татар моңы сибелә. Итальян, рус җырлары яңгырый. Бу минутларда сәхнәгә йөзләрчә күз төбәлгән булса да, шулар арасыннан ул бары тик бер кешенең генә карашын тоя. Йөзләгән кеше арасыннан аңа Зөләйха Хисмәтуллина көч, дәрт, куәт һәм дәрман биреп утыра. Ике пар күз карашы зал өстендә очрашкан да, үзләре генә белгән телдә сөйләшә. Ә сәхнәдән, күңелнең әллә кай җирләрен актарып, саф моң сибелә. Шул арада комиссия өстәленә Мәскәү, Ленинград, Свердловск, Новосибирск һәм башка бик күп театрлардан чакыру кәгазьләре агыла. Үҗәтрәкләре, җырлап чыгуга, шәхси чакыру тапшыру өчен аны сәхнә артында ук каршылый. Ләкин ул аларның берсенә дә ризалык биреп ташларга ашыкмый. Галина чакыруны башка җирдән көтә. Аңа туган ягы, туган халкы кадерле. Аңа кечкенә генә туган авылы Керәшен Мамадышына якынрак булган Казан кадерле. Аның туган телендә җырлыйсы килә. Ләкин, ни хикмәт, аны Казаннан чакыручы кеше булмаган. Чакыру ясаган дистәдән артык театрның берсен сайлап алуны Г. Казанцеваның үз ирегенә куялар. Шунда Казан опера һәм балет театрының ул вакыттагы баш режиссеры Нияз Даутов күтәрелә.

— Ул сайлаганчыга кадәр мин үз фикеремне әйтергә тиеш,— ди ул.— Монда килгәндә мин аңа алдан чакыру ясамадым. Хәзер мин үз тәкъдимемне әйтәм. Без аны яңадан Казанга алып кайтып китәбез.

Һәм ул комиссия рәисенә алдан ук әзерләп куелган гаризасын чыгарып бирә. Кайтып төшсә, опера театрында Мәсгут Имашев аны шатланып каршы ала. Ул, Әлмәттән кайтып, монда директор булып эшли башлаган икән. Яхшы туфракка төшеп шыткан орлык кебек, Галинаның таланты өчен дә киң офыклар ачыла. Опера театрында эшләгән вакытта ул барлык спектакльләрдә дә чыгыш ясый. Балалар операсы һәм оперетта, классик опера спектакльләре булмасын, ул күп очракта төп рольләрне оста итеп башкара. Бизеның «Кармен»ында — Микаэланы, Римский-Корсаковның «Снегурочка»сында — Кар кызын, Пуччининың «Богема»сында — Мюзеттаны, Бородинның «Князь Игорь» әсәрендә — Кыпчак кызын, Н. Җиһановның «Алтынчәч»ендә — Алтынчәчне, Б. Мөлековның «Кара йөзләр»ендә — Галимәне, Җ. Фәйзинең «Башмагым»ында — Сәрвәрне, Сәйдәшнең «Наемщик» драмасында Гөлйөземне һ. б. иҗат итә.

Г. Казанцева актерлык иҗатының беренче елында ук бөтен җаны-тәне белән эшкә чума. Катлаулы партияләрне зур осталык белән башкара.

* * *

Аның башкара торган әсәрләре — халык йөрәгеннән тамган моңнар. «Янбикә», «Гөлҗамал», «Көймә килә», «Фазыл чишмәсе», «Талы, талы», «Сакмар», «Таң атканда» җырларын гына атап чыгу да җырчының диапазонын билгели булыр. Алар янына тагын «Безнең ил», «Кәләй», «Таш пулат», «Кыр үрдәге», «Кәтүк түти», «Вак балык», «Безнең зат» кебек керәшен җырлары килеп кушыла.

Һәрбер концерт — җырчының яңа бер биеклеккә ирешүе ул. Г. Казанцеваның булып узган бенефисын да шулай бәяләү дөрес булыр. Җырчы «Көмеш чыңлы моңнарым»ның беренче бүлегендә, итальян, татар һәм рус җырларын оркестр белән башкарып, үзенең югары артистлык осталыгын үстерә баруын тамашачы алдында тагын бер кат раслады.

Ходай Тәгалә Галинадан талантны кызганмаган. Бу — аның бөтен байлыгы. Ул аны, тагын да ишәйтеп, тулыландырып, туган халкына мул итеп өләшә. Монысы аның бәхете. Җырчы кайда гына

булмасын, кайда гына чыгыш ясамасын, һәркайда кешеләргә шатлык алып килде, тормыш никадәр генә ачы булмасын, аны яратырга өндәде. Бу сүзләрне раслау өчен концертта башкарган теләсә кайсы җырны әйтү дә җитәр иде. Аларда Г. Казанцеваның эчке кичерешләре дә ачык чагыла.

«Бу кадәр моң һәм тырышлыкның чыганагы кайдан килә?» дигән сорау туа. Әлеге сорауны мин аның үзенә дә бирдем. Ә ул, үзенең балачагына алып кайтып, Тукай районындагы Мажын елгасы буена урнашкан Керәшен Мажыны авылындагы туганнары, андагы тормышы белән таныштырды. Галина аннан бүген дә аерылмаган әле. Дүрт баланың иң зур бәхете — нәнәләре Аннук түти шунда яши.

— Җәй көннәрендә энем Юрий да, мин һәм сеңелләрем дә, авылга кайтып, бакчада яшелчәләр үстерәбез,— ди ул.— Аннары, эшләп арыгач, җыйнаулашып, яшел чирәм өстеннән ялан тәпиләп кенә Мажын елгасына су коенырга төшеп китәбез. Хәзер рәхәт ул. Бәләкәй чакта авыргарак туры килде. 4 яшемдә инеш буендагы чишмәдән су ташый башладым. Нишләптер шул нәрсә бик нык хәтердә калган. Хәзер 4—5 яшьлекләр тездә генә утыралар. Үсә төшкәч, чөгендерен дә утадык, бәрәңгесен дә өйдек, борчагын да чаптык, печәнен дә җыйдык, утынын да кистек. Җәйләү урманына барып, төптән дә кисеп алып кайттык. Ни өчен шулай? Чөнки мин баш бала идем. Тәтем (әтием) Санька гомере буена районның алдынгы комбайнчысы булды. Ул бездә һәр эш өчен экстра җаваплылык тәрбияләде. Безне шулкадәр шыкырдатып үстерделәр — хезмәт дисциплинасын тулысы белән үттек. Аллага шөкер!

— Ә җыр? Бу сәләтегез кайдан?

— Монысы бабайдан. Авылда аның җырлавын бүген дә хәтерлиләр. Ул бәрхет баритон тавышлы Кируш Иваны иде. Сугышта булган. Аннан бик нык яраланып кайткан. Полк җырчысы булган.

— Сезгә аны тыңларга туры килдеме?

— Әлбәттә. 60 нчы еллар уртасы иде бу. Үләренә берничә көн калгач, бер ашта бик матур итеп җырлаган иде. Гаиләдә ир бала дөньяга килгәч, бик шатланган иде. Бабай Юраны күреп китте. Хәзер бу энем — минем иң якын ярдәмчем, булышчым. Җыр әнә шул бабайдан. Нәнәм (әнием) дә бик оста җырлый. Бабайның кызы була инде ул. Керәшен җырларын оста башкара. Шул җырларның моңын, аһәңен отып калу өчен мин аны кат-кат тыңлыйм... Гаиләдә мин үземне иң яхшы җырчы димәс идем. Минем сеңлем Мария бик матур тавышлы. Аның тавышы минекеннән моңлырак иде, ләкин артист булып китмәде. Нәнәнең сеңлесе Санук түти дә — бик оста җырлаучы. Миңа караганда түбәнрәк тавышлы...

Г. Казанцева иҗатының иң нечкә урыны — ул керәшен җырлары.

Әйдә, иптәшкәем, киң кырларга
Бүдәнәләр тапсак, бүләрбез.
Әй синеңнәр белән без икебез
Аерылдык исә — үләрбез.

Әкрен-әкрен без җөриек,
Арымасын безнең атыбыз.
Тәмнеләр лә, татлы без сөйләшиек,
Черемәсен безнең затыбыз.

— Керәшен фольклоры — бик борынгыдан килә торган культура катламы,— ди ул, бу хакта сүз чыккач.— 90 нчы еллар башында, зиһенем ачылып киткәндәй, мин шуны аңлый башладым. Җырлап карадым да аһ итеп куйдым. Күрәсең, ул зиһен минең бер почмагында, мин кайчан чыгармын, дип көтеп торгандыр. Керәшеннәрдә җырлау алымы бөтенләй башка төрле. Мин хәзер шул җырлау алымына кайтып, шуны эшләп йөрим, материаллар туплыйм. Һәр халык, әгәр дә аның мәдәнияте бар икән, ул ихтирамга, яклауга, танылуга лаек.

Әйе, Г. Казанцеваның иҗат хыяллары зурдан. Ул дәүләттән таяныч тоеп яши торган җыйнак кына керәшен ансамбле төзү уе белән дә янып йөри. Әйткән сүз үтәлгәндә, хыяллар тормышка ашканда, яшәгән саен яшисе, эшләгән саен эшлисе килә бит ул.

*Александр Филиппов*

## Керәшен сылуына

Чигүле алъяпкычларың
Бик килешә үзеңә.
Мәрҗән муенсаларыңнан
Нур сибелә йөзеңә.

Инсафлы бу нур, мөгаен,

Буыннардан күчкәндер.
Нур шифасы тигәнгәдер,
Буең зифа үскәндер.
Кашларыңны, кыйгач итеп,
Карлыгачлар сызгандыр.
Ирен өстеңдә нәни миң —
Таңнар үбеп узгандыр.

Елмаюлы карашларың,
Йөрәкләрне өзмәле...
Эштә уңган, төскә булган
Ул — керәшен гүзәле!

*Мирһади Разов*

## Тау ягы сандугачы

Лена кечкенәдән үк укытучы булырга хыяллана. Шушы канатлар аны 1986 нчы елда Казан дәүләт педагогия институтына китерә. Аны дөнья халыклары, алар таралып утырган илләр — география киңлекләре кызыксындыра. Әмма… Ни хәл итәсең, конкурс иләге булачак укытучының канатын кисә. Казандагы авылдаш туганнар, дуслар авылына кайтып күренергә кыймый йөргән кызга күн заводында эш табып бирәләр. Авылда чыныгып килгән кызны мондагы авыр хезмәт куркытмый. Ул вакытта Ленаның әнисе белән бертуган апасы Марья Михайловна укытучыларның ветераннар хорында җырлый торган була. Ул сеңлесен эштән соң үз янына хорда җырларга чакыра. Лена «Сәйяр» ансамблендә чыгыш ясый башлый.

Зур һәм чын сәнгать ишекләрен «сим-сим» телен белгән талантлылар гына ачып керә ала. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе, җыр һәм бию ансамблен яшәртү һәм чит илләргә гастрольләргә чыгар алдыннан талантлар белән тагын да баету максатын күздә тотып, хорда чыгыш ясау өчен конкурс игълан итә. 120 кеше катнаша. Сайлап алынган иң бәхетле биш кеше арасына, лаеклы төстә, Лена Бичарина да керә. Менә шуннан соң башлана инде аның үсмер елларында хыялланган дөнья географиясе белән танышу дәресләре. Риваятьләр белән өртелгән, иң борынгы заманнардан грек һәм этрусклар мәдәниятен саклаган Карфаген (Тунис) стадионында чит илләрдән җыелган ун меңнәрчә тамашачы алдында татар җырларын яңгырату — мәңге онытылмаслык хатирә. Италия, Франция, Япония, Германия, Төркия, Финляндия, Ирак, Африка илләре... Аларны берәмләп саный китсәң, кул-аяк бармаклары гына да җитмәс. Күп алар... Лена Бичарина, хор коллективының җәүһәр ташыдай бер солисткасы буларак, шуларның һәркайсында татар җырларын, керәшен моңнарын тамашачы йөрәгенә салып калдыра.

— Мине әнием җырлары рухландыра,—ди Лена Бичарина.— Әле бүген дә туксан яшен узып киткән әнием фатихасы белән яшим.

Ансамбльнең баш хормейстеры, Татарстанның халык артисткасы Венера Гәрәева аның турында:

— Хорда эшли башлаган елында ук аның башкаруында яңгыраган «Чатырлар» җыры татар тамашачысының күңелен җәлеп итте,— ди.

Тамырларын халык күңеленә XVI гасырларда ук җибәргән «Чатырлар» (җырның сүзләрен Зөлфәт язган) көен дә Ленаның моңлы йөрәгенә сөекле әнисе, авылдашлары салып куя. Халкыбызның бәхете бар икән, әгәр Лена зур сәхнәгә күтәрелмәгән булса, бәлки бу җырның да чишмә тамыры ябылган булыр иде.

Далаларда чатыр корыр идем,
Яннарында учак ягар идем…

Халкыбызның көрәшче кызы Фәүзия Бәйрәмованың бу җырны Лена Бичарина башкаруында беренче мәртәбә ишеткәндә, борынгы Болгар тарихы белән кызыксынып, хәрабәләр арасыннан җанына җавап эзләп йөргән чагы була. «Җырлары ничек булды икән соң бу халыкның, дип күңелем белән шул көннәргә, урман-далаларына, Әтил суы буйларына киткән вакытларым иде,— дип яза ул «Тау ягы кызы» исемле мәкаләсендә.— Ленаның җыры шуңа җавап булды… Калын күкрәк тавышы белән, ашыкмыйча, салмак кына килә иде ул моң узган көннәрдән. Зиһенем буйлап томырылып атлар чабып үтте, дала юлы кара урманнарга барып тоташты, озын, кара толымлы кыз баланың моңы, сагышы, җыры, җаным аша үтеп, минем тормышыма күчте».

Лена Бичарина җан фикердәшләрен әнә шулай үзенең горур яңгырашлы бәрхет тавышы, күңелгә якын җырлары аша таба. Аның җырлары озын гомерле. Аларның төбендә кыйммәтләре вакланмый торган тормыш фәлсәфәсе ята. Шуңа күрә аларны тикмәгә генә «Әнием җырлары» дип атамый торгандыр инде.

Лена Бичарина хәзер иҗади эзләнүләр чорын кичерә, репертуарын композиторларыбыз әсәрләре, халык җырлары белән баету өстендә эшли.

— Яңа программада әле бер дә яңгырамаган әнием җырлары да зур урын алырга тиеш,— ди Татарстанның атказанган артисткасы Лена Бичарина.— Бүгенге көнгә кадәр алып килгән байлыкны киләчәк буыннарга тапшырып калдырырга кирәк.

*Александр Филиппов*

* * *

Без урамнан барган чакта,
Карагыз ла ай-һай-һай.
Без җырлашып барабыз ла,
Тыңлагыз ла ай-һай-һай.
Җаңгырасын җырларыбыз,
Җыракка ла ай-һай-һай.
Бу дөнҗага безләр килгән,
Кунакка ла ай-һай-һай.
Әле бер көн сагынырсыз,
Ул көннәрне ай-һай-һай.
Ул чакларда без җөрмәбез
Җырлашып ла ай-һай-һай.

## Керәшен матбугаты тарихыннан

Аны тудыруда 1905—1907 нче елларда Р. П. Даулей һәм Д. Г. Григорьев-Саврушевский күп тырышлык куя. Тик бу идеяне тормышка ашыру мөмкинлеге беренче бөтендөнья сугышы барган елларда, Вятка шәһәрендә П. П. Глезденев, Уфада С. М. Матвеев тарафыннан «Сугыш хәбәрләре» һәм «Дус» газеталары чыга башлагач кына туа. Эстафетаны 1918 нче елның апреленнән чыга башлаган «Керәшен» газетасы кабул итә. Совет власте урнашкач, Алабуга шәһәрендә «Алга барыек!» газетасы чыга башлый, тик аның гомере бик кыска була (редакторы Г. И. Зубков).

Шул ук вакытта Минзәләдә «Хәбәрләр» газетасы чыга башлый. Аның да берничә саны гына дөнья күрә. Кызылармияче керәшеннәр өчен 1918—1919 нчы елларда «Кызыл солдат» газетасы чыга. 1919—1921 нче елларда И. А. Алексеев редакторлыгында «Кызыл әләм» газетасы нәшер ителә. Идел буенда булган ачлык вакытында әлеге газетаны «Белемнек» журналы алыштыра. 1922 нче елдан алып 1930 нчы елга кадәр атналык «Киңәш» газетасы чыгарылып килгән.

### КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН ГАЛИМНӘР

*Абрамов П. В.*— профессор (Мамадыш районының Шеморбаш авылы), *Алексеев И. А.* — фән кандидаты (Чистай районының Ишалькино авылы), *Агачев П. В.*— фән кандидаты (Питрәч районының Янсуар авылы), *Архипов А. М.*— фән кандидаты (Лениногорск районының Федотовка авылы), *Беркутов В. М.* — профессор (Кукмара районының Нырья авылы), *Горохов В. М.* — профессор (Алабуга районының Зур Елов авылы), *Григорьев А. Н.* — фән кандидаты (Мамадыш районының Зур Сәүрүш авылы), *Григорьев В. Д.* — профессор (Зәй районының Баграж авылы), *Ермолаев И. П.* — профессор (Чистай районының Бахта авылы), *Иванов В. В.* — фән кандидаты, *Иванов В. В.* — профессор (Алексеевск районының Югары Кондрат авылы), *Ильин И. Ф.* — фән докторы (Балык Бистәсе районының Иванай авылы), *Капитонов А. А.* — фән кандидаты (Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авылы), *Каргин Н. А.* — фән кандидаты (Кайбыч районының Мәлки авылы), *Кибяков А. В.* — фән докторы (Мамадыш районының Шеморбаш авылы), *Ковалев В. Н.* — фән докторы (Кайбыч районының Мәлки авылы), *Кузнецова З. М.* — фән кандидаты (Зәй районының Сарсаз Баграж авылы), *Толмачев Г. Г.* — фән кандидаты (Чиләбе өлкәсенең Фершампенуаз авылы), *Макаров Г. М.* — музыка һәм этнография галиме (Әлмәт шәһәре), *Макаров П. И.* — профессор, фән докторы (Питрәч районының Кәвәл авылы), *Максимов В. А.* — фән докторы (Мамадыш районының Колыччы авылы), *Максимов Н. В.* — фән кандидаты (Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авылы), *Михайлов М. К.* — фән докторы (Зәй районының Түбән Биш авылы), *Никитин И. З.* — фән докторы (Балык Бистәсе рай-

онының Иванай авылы), *Петров А. Н.* — фән докторы (Балык Бистәсе районының Алан-Полян авылы), *Петров Э. А.* — фән кандидаты, *Петрова А. А.* — фән кандидаты (Чистай районының Наратлык авылы), *Плотников В. П.* — фән кандидаты (Дзержинск шәһәре), *Смолов С. Н.* — фән кандидаты (Кайбыч районының Мәлки авылы), *Яблоков Д. М.* — фән кандидаты (Балык Бистәсе районының Керәшен Казысы авылы).

## Марс Константинович Михайлов

Марс Константинович Михайлов — 1980 нче елдан бирле Татарстан табибларының белемен күтәрү академиясенең ректоры. Ел кешесе.

Ул 1938 нче елның 17 нче июнендә Зәй районындагы Түбән Биш авылында укытучы гаиләсендә туган. Әтисе — Константин, әнисе — Соломия — улының укытучы булуын тели. Әмма Марс табиб һөнәрен сайлый. Чөнки адәм баласына тән һәм җан сәламәтлеге бирү иң изге эшләрдән санала. Егет Казан дәүләт медицина институтына укырга керә, аны уңышлы тәмамлап, табиб-хирург була. Профессор Н. П. Фәйзуллин аны Казан табиблар белемен күтәрү институтына өлкән лаборант итеп эшкә чакыра. Марс Константинович бу тәкъдимне кабул итә. Бирелә ул тирән эзләнүләр, ачышлар ясау мөмкинлекләрен күрә, бай тәҗрибә туплый, рентген нурлары белән диагноз куюның серләрен ача.

Марс Константинович җитәкчелегендә 11 фәнни хезмәткәр докторлык, күпләр кандидатлык диссертациясен яклаган. Аның 260 тан артык фәнни хезмәте бар. Ул — Татарстан һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясе президиумы әгъзасы, Белгород (Югославия) университетының почетлы профессоры.

*Нәкыйп Каштанов*

## Максим Глухов

Максим Степанович Глухов — язучы, тарихчы һәм фәлсәфәче. 1937 нче елда Казанда туган. Казан дәүләт университетында журналист белгечлеге алган. «Ватан тарихы» белгечлеге буенча аспирантура тәмамлаган, тарих фәннәре кандидаты. Ул — берничә әдәби-публицистик әсәр, татар халкының тарихына һәм рухи мирасына караган берничә фәнни китап: «Судьба гвардейцев Сеюмбеки», «Татарика. Энциклопедия» һ. б. китаплар авторы. Озак еллар Татарстан китап нәшриятында өлкән редактор булып эшли.

## «Татарика. Энциклопедия» китабы белән танышкач

Бер танышым әлеге китапны күргәч: «Әллә чит илдә басылганмы бу?» — дип, иң элек, аның искиткеч матур бизәлешенә, кәгазенең югары сыйфатына игътибар иткән иде. Китапның Казанда «Ватан» нәшриятында басылуын, бизәүче рәссамы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рушан Шәмсетдинов икәнлеген белгәч: «Теләсәләр, бездә дә эшли беләләр икән ич! Югыйсә бик күп миллионнар түгеп, китапларны чит илләрдә бастыру модага кереп бара иде»,— дип үзенчә нәтиҗә ясап куйды.

Сүз тарих фәннәре кандидаты, танылган публицист һәм язучы Максим Степанович Глуховның әле яңарак кына дөнья күргән «Татарика. Энциклопедия» дигән китабы турында бара иде. Танышым бик хаклы: ул гаять югары зәвык белән эшләнгән. «Күп еллык хезмәтемнең кулга сокланып тотарлык булуын теләдем»,— диде автор үзе әңгәмә вакытында, бу хакта сүз чыккач.

Әлеге «Керәшен энциклопедиясе» белән танышкан кешеләр авторның гаять зур эзләнүләр алып баруын, киң мәгълүматлы булуын, керәшеннәрнең танылган шәхесләрен, гореф-гадәтләрен, үзләренә генә хас милли бәйрәмнәрен җентекләп өйрәнүен билгеләп үтте.

Без автор белән әлеге фикерләргә карата аның үз сүзен ишетергә теләп очраштык.

* * *

— Әйе, Октябрь революциясеннән соң керәшеннәргә күпмедер дәрәҗәдә мөстәкыйльлек бирү булган. Өлкә һәм өяз Советлары каршында керәшен бүлекләре эшләгән, керәшеннәр өчен аерым газеталар басылган, махсус нәшрият булган, китаплар чыгарылган. Моннан тыш, керәшен театры һәм педагогия техникумы эшләгән әле,— ди Максим Степанович.— Әмма мин «боларны кабат кайтарырга кирәк» дигән максат куймадым. 1997 нче елның Бердәмлек һәм килешү елы дип игълан ителүен яхшы беләм. Әгәр керәшенне татардан аерып карарга чакырсам, бу Татарстан халыклары татулыгына кизәнү булыр иде. Сүз

уңаеннан ике киленем дә татар кызлары икәнлеген әйтим әле. Безнең гаиләдә «син татар», «син керәшен» дигән сүз кузгалганы юк. Бер-беребезне бик хөрмәт итеп яшибез.

— Шулай да керәшеннәргә багышлап шундый китап чыгарудан максатыгыз нинди соң?

— Мин, барыннан да элек, керәшен дигән бик үзенчәлекле этник төркем барлыгына игътибарны юнәлтергә теләдем. Аның теле, гореф-гадәте, йолалары борынгы төркиләрдәге шактый үзенчәлекләрне саклап калган. Керәшен теле гарәпләр йогынтысыннан да саф килеш сакланган.

— Максим Степанович, Сез керәшеннәрнең руслар тарафыннан чукындыру сәясәте алып бару нәтиҗәсе икәнен бөтенләй танымыйсызмы әллә? Бу ачы хакыйкатьтән качып булмый бит.

— Христианлык безнең борынгы бабаларыбызга русларга караганда да элегрәк таныш булуын әйтим. Ләкин X гасырда алар әле православный булмыйча, христиан-несторианлыкта торганнар. Бу хакта күп тарихи чыганакларда теркәлгән. Аны күренекле галим-филолог Рифкать Әхмәтьянов та язып чыкты.

Чукындыру процессына килгәндә, Казанны яулап алгач,
тарихта әлеге трагедия белән бәйле бик күп вакыйгалар бил-геле. Чукындырылган татар авылларының исемлеге дә бар. Кире мөселманлыкка кайтканнары да ачыкланган. Шулай да бу күренеш массакүләм характерда булмаган. Көчләп тагылган дин һәм гореф-гадәт озак яши алмый бит ул. Шул ук нәрсәне әнә үз тормышыбызда идеология өлкәсендә дә күрергә мөмкин.

— Керәшен фән һәм сәнгать эшлеклеләреннән: «Безнең ерак бабаларыбыз арасында христиан динендәге төркиләр дә күп булган»,— дигән фикерне кистереп әйтү соңгы вакытта аеруча еш яңгырый башлады. Ул Сезнең китапка да кергән...

— Борынгы Хазар каганлыгында, Кавказ таулары итәгендә һәм Азов диңгезе буйларында зур территорияне алып торган Бөек Болгар дәүләтендә, аннан соңрак Алтын Урдада диннәр иреге булган бит! Әлеге төрки дәүләтләрдә ислам, яһүд, христиан диннәре, шулай ук мәҗүсилек янәшә яшәгән. Шунысы кызыклы: Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә беренче мәчетләрне төзеткән Үзбәк ханның (1312—1340 нчы елларда хакимлек итә) мондый указы билгеле. «Православие чиркәвенең барлык даирәләре һәм монахлар бары тик православие митрополиты хөкеменә генә буйсыналар. Урда хакимнәре
һәм кенәз суды аларга кагыла алмый. Православие диненнән көләргә яки чиркәү, монастырь, часовняны мыскылларга батырчылык иткән һәр кешене, рус яки монгол булуына карамастан, үлем җәзасы көтә!» — диелгән анда.

Мондый эчтәлектәге указны игълан итәргә, үзенең православие диненә карата битараф булмавына, мөгаен, Үзбәк ханның христиан динендәге төрки гаиләдә тууы һәм үсүе дә этәргеч биргәндер.

— Болар бик кызыклы фактлар. Әмма Урта Идел буендагы, Урал төбәгендәге бүгенге керәшеннәр белән ул чордагы христиан төркиләр арасында нинди бәйләнеш бар соң?

— Безнең тюркологлар һәм тарихчылар, борынгы бабаларыбыз Төньяк Кавказдан, Иделнең түбәнге төбәгеннән күтәрелгән, диләр бит. Менә бәйләнеш шунда! Алар Урта Идел буена үзләре белән христианлыкны да алып менгәннәр. Димәк, Казан ханлыгын яулап алганнан соң үткәрелгән көчләп чукын-дыруга кадәр үк озак еллар элек безнең якларда христиан динендәге төрки халыклар яшәгән булып чыга.

— Энциклопедиягезгә татарның күп кенә күренекле шәхесләрен дә керткәнсез. Аларны сайлап алу принцибы ничек булды?

— Болар — үз иҗатларында халыклар дуслыгына дан җырлаучы язучылар, җырчылар, галимнәр, сәнгать эшлеклеләре, журналистлар... Чөнки минем максатым изге — халыклар дуслыгын ныгыту.

— Китабыгыз ахырында бик күп гыйльми чыганаклар күрсәткәнсез. Сез аларның барысы белән дә танышмы?

— Татар халкының килеп чыгышына, аның тарихына карата төпле фикер әйтергә теләгән һәр галим өчен бу танышлык мәҗбүри шарт. Мин Ибне-Фазлан һәм Ибн-Рустә, Шиһабетдин Мәрҗани язмаларыннан башлап, бүгенге көндә үзем бик хөрмәт итә торган татар галимнәре Равил Фәхретдинов, Дамир Исхаков, Марсель Әхмәтҗанов, Фирдәвес Гарипова һәм башкаларның хезмәтләре белән якыннан таныш.

— Максим Степанович, инде китабыгызның киләчәктә тулыландырылырга тиешле бер ягы турында да әйтим. Сез керәшеннәр күп таралган төбәкләрне картада күрсәтеп бирмәгәнсез...

— Әйе, бу кирәк булгандыр. Мин керәшен авыллары исемнәрен төркемләп күрсәтеп санап чыктым чыгуын. Безнең Татарстанда алар Питрәч, Теләче, Балык Бистәсе, Мамадыш, Менделеевск, Зәй, Алабуга районнарында күп яши. Минзәлә, Әлмәт, Яңа Чишмә, Кайбыч, Сарман, Чистай, Арча, Лениногорск, Кукмара районнарында да бар. Күрше Урал төбәген-
дә, Чиләбе өлкәсендә, Удмуртиядә дә шактый таралып яши алар. Башкортстанның Бакалы районында исә аеруча күп.

*Нургали Булатов*

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН АРТИСТЛАР**

*Вера Минкина* (Чистай районының Бахта авылы), *Раиса Тимофеева* (Тукай районының Борды авылы), *Николай Дунаев* (Зәй районының Әхмәт авылы), *Георгий Ибушев* (Мамадыш районының Владимир авылы), *Галина Казанцева* (Тукай районының Керәшен Мәҗыны авылы), *Анастасия Васильева* (Теләче районының Субаш авылы), *Елена Бичарина* (Кайбыч районының Иске Курбаш авылы), *Аграфена Васильева* (Түбән Кама районының Келәтле авылы), *Зоя Борисова* (Балык Бистәсе районының Алан-Полян авылы).

## Раиса Тимофеева

Раиса Тимофеева — керәшен көйләрен беренчеләрдән булып профессиональ сәхнәгә чыгарган ветеран җырчы. Ул — үзешчән сәнгатьтән профессиональ җырчылар сафына баскан кеше.

Аның хезмәт юлы Татар дәүләт филармониясендә үткән. Иҗат юллары Раиса Тимофееваны Европа илләренә, Кытайга кадәр илткән.

1950 нче елда үзешчән сәнгать көчләренә республика күләмендә смотр уздырыла. Бик күп яшь талантлар арасында Чаллы районындагы Борды авылыннан килгән матур тавышлы җырчы кыз Раиса Тимофеева аеруча уңыш казана. Бу вакытта ул сары чәчле, зәңгәр күзле, тулы йөзле 21 яшьлек матур кыз була. Ул «Гөлләр үсә» җырын зур күтәренкелек белән башкара. Җыр аның җиңел кулы белән концерт эстрадаларына да күтәрелә.

«Җыр капчыгы» Раисаны Казаннан килгән композитор Җәүдәт Фәйзи эзләп тапкан. Үзенең бу зур табышы турында композитор «Халык җәүһәрләре» дип аталган китабында да язып калдырган:

— Менә ул «Гөлләр үсә» көе чыккан Борды авылы. Монда керәшеннәр яши. Авыл зур гына. Кечкенә генә уку йорты һәм ике катлы җидееллык мәктәбе бар. Раиса, мине күргәч, бераз каушабрак калды. Беренче сүзе:

— Озакка килдегезме, абый? — булды.

— Җырларыгызны язып алу белән китәм,— дидем...

— Мин болай гына сорыйм. Бездә сезне кабул итәрлек затлы урын юк шул,— дип әйтеп куйды. Күрәсең, урын тарлыктан уңайсызланадыр. Шулай да ул үз өйләренә алып китте. Әти-әнисе мине бик хуплап каршы алды һәм беркая да җибәрмәскә булдылар.

«Мин Раиса Тимофеева янына килүемә шатланып бетә алмыйм. Берсе артыннан икенче көйне җырлап кына тора ул миңа. Күңелең нинди эчтәлекне тели — шунысын әйтә дә бирә. Уен җырымы? — Рәхим итегез! Такмакмы? — Була ул. «Рамай»ныммы? — Анысын да белә. Романска тартым көй кирәксә — Әхмәт Ерикәй, Фатих Кәрим сүзләренә чыккан яңа көйләр дә бар…

Кыскасы, егермегә якын көй язылган. Шуларның үндүрте хәзерге заман халык көйләре. Калганнары керәшеннәрдә генә сакланган туй-йола җырлары...

Яшермим. Раиса Тимофеевадан язылып алынган көйләрнең кайберсен үзе чыгарган, кайберләрен минем алда, минем киңәшләремне истә тотып, җайландырып җырлады.

Минем бу чын күңелдән势 тануым кайбер фольклорчыларга ошап та бетмәс. Янәсе, «Тимофеева чыгаргач, нинди халык көе булсын инде ул?»

Ә бит «Тәзкирә», «Гөлҗамал», «Тәфтиләү»ләр дә үзләреннән-үзләре тумаган. Аларны кем дә булса берәү башлап җырлаган, үз күңелендә булган кичерешләрен көй аша халыкка җиткергән, димәк, көй чыгарган. Ләкин ул автор буларак билгесез калган.

Ә без халкыбызның культурасы гөрләп торган чорда яшибез. Шулай булгач, көйләрнең авторлары билгеле булу
гаҗәпмени? Тимофеева кебек, безгә матур җырлар бүләк
иткән иптәшләр «билгесез» булып калырга тиеш түгел. Чөнки алар — халык иҗатының традициясен дәвам иттерүчеләр. Аларны халыктан аерып булмый һәм аларның иҗаты —халык иҗаты.»

## Вера Минкина

1950 нче ел — Татарстанның атказанган артисткасы.
1968 нче ел — Татарстанның халык артисткасы.
1972 нче ел — РСФСРның атказанган артисткасы.
1977 нче ел — РСФСРның халык артисткасы.

Вера Минкина 1918 нче елда Чистай районы Бахта авылында туган. 1934 нче елда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан театр техникумына укырга керә. Техникумнан 1938 нче елда 4 кешене — Вера Минкина, Сәет Шәкүров, Гамир Насрый, Хәй Вахитны — Академия театрына эшкә алалар. Соңгылары бүгенге көндә мәрхүм булсалар да, күренекле язучы буларак, исемнәре халык күңелендә яши.

Яшь артистлар шул елдан Академия театрының күчмә филиал группасында эшли башлый. Группаның директоры һәм баш режиссеры Татарстанның атказанган артисты Әсгать Мәҗитов була. Яшь артистларның беренче спектакле «Шәмсекамәр»дә Вера Минкина Разия ролен башкара.

Айлар үтә... Әсгать Мәҗитов белән Вера Минкина, бер-берсен яратып, гаилә корып яши башлыйлар. Бер ул һәм кыз дөньяга килә.

Шулай матур гына яшәп, эшләп йөргәндә, Бөек Ватан сугышы башлана, Әсгать Мәҗитовны һәм театрга эшкә Вера Минкина белән бергә килгән егетләрнең өчесен дә сугышка алалар. Сугыштан исән кайткан Әсгать Мәҗитов 1946 нчы елны каты авырудан үлеп китә. Вера Минкина кечкенә балалары белән ялгызы кала.

1952 нче елда аны күчмә театрдан Академия театрына эшкә чакыралар. Монда аны Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская, Галимә Булатова, Гөлсем Камская, Хәлил Әбҗәлилов, Хөсәен Уразиков, Камал III, Хәким Сәлимҗанов һәм башка танылган артистлар бик матур итеп, үз итеп каршы ала, ярдәм итә. Артистка аларга гомере буе рәхмәтле булып яши. Эшләү дәверендә дистәләгән спектакльләрдә катнашып, онытылмас образлар тудыра.

Вера Минкина бүгенге көндә Казанда яши. Ул — бәхетле ана һәм әби. Кызы Диләрә доцент, Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында чит телләр кафедрасы мөдире булып эшли. Улы Марсель — Казандагы 56 нчы һөнәр училищесы директоры. Вера Минкинаның өч оныгы бар.

*Николай Максимов*

## Николай Дунаев

1961 — академия театры артисты.
1972 — Татарстанның атказанган артисты.
1973 — А. Н. Островскийның тууына 150 ел тулу уңаеннан үткәрелгән Бөтенроссия смотрының I дәрәҗәле дипломанты.
1978 — Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты.
1982 — Татарстанның халык артисты.
1992 — Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе доценты.
1996 — Россия Федерациясенең атказанган артисты.
1998 — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

26 нчы апрель көнне Казанда Тукайның тууына 112 ел тулуга багышланган тантаналы митингта Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең 1998 нче елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указы нигезендә, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Наил (Николай Иванович) Дунаевка Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты дигән исем бирелде. Премия драматург Туфан Миңнуллинның «Хушыгыз!» спектаклендә башкарылган рольләр өчен бирелеп, шундый ук бүләккә режиссер Фәрит Бикчәнтәев һәм артистлар Нәҗибә Ихсанова белән Әзһәр Шакиров та лаек булдылар.

Зәй районының Әхмәт авылында умартачы Дунай Иваны белән җыручы Үлҗәнә түти семьясында туып үскән керәшен егете татар, рус, чит ил классикасындагы геройлар язмышы белән яшәп, дистәләрчә образлар тудырды. Шуларның иң матур, иң яктыларыннан берсе — Т. Миңнуллинның «Гөргери кияүләреннән» Гөргери образы. Акыллы да, хәйләкәр дә, шаян да булган Гөргери ролендә бүтән артистны күз алдына да китерү кыен. Әлеге спектакльдә аның режиссер ярдәмчесе дә булуын әйтеп китү кирәктер.

Николай Иванович бүген үзенең уй-фикер, карашлары белән уртаклаша.

— Безнең Әхмәт авылында мәчет тә, чиркәү дә бар иде. Чиркәү, агач булуы аркасында, череп ишелде, ә таш мәчетне яңарттылар. Авылның яртысы — керәшеннәр, яртысы татарлар. Ярдәмләшеп, кунакка йөрешеп яшәделәр. Дөрес, элегрәк үзара өйләнешү юк иде, хәзер күп инде.

* * *

Артистлык каян килә, дигәндә, каннан, мөгаен. Безнең керәшен җырга, уенга оста бит ул. Бездә «рәт эчү», дип йөртелә торган йола бар. Берничә гаилә берләшә дә көннәр буена берсеннән-берсенә «рәт эчеп» йөриләр. Бүген Метридә булса, иртәгә Иванда, аннан Микулайда... Озакка сузыла. Атна буена эчеп, ничек юкка чыгып бетмиләрме? Юк, чөнки «рәт эчү» ул — театрлаштырылган бер бәйрәм: бер тустаганны түгәрәк буенча йөртеп, кеше саен дүртәр-бишәр җыр җырлап бирәләр. Тустаган түгәрәкне әйләнеп чыкканчы төш җитә (әгәр иртәдән үк утырсаң). Эчү үзе түгел, ә аралашу, җырлашу мөһимрәк. Шул бәйрәмнәрдә әни башлап җырлаучы була торганые. Тутасы, сеңлесе белән өчәр тавышка да җырлыйлар иде.

Аннары безнең якның уеннары. Күрше авыллардагы яшьләр — Җәйләүлеләр, Бордылар, Бишавыллар килә иде кичке уеннарга, һәр авылның үз көе була торганые.

* * *

Керәшеннәр совет бәйрәмнәрен дә бәйрәм иттеләр, үз дини бәйрәмнәребезне дә ким-хур куймадылар. Әле тагын мәҗүсилектән үк калган бәйрәмнәр дә бар иде. Мәсәлән, Симет бәйрәме. Аны бездә Бишавыл бәйрәме дип йөртәләр. Ул Тройсынга, ягъни җапрак бәйрәменә туры килә, капкаларны яфраклар белән бизиләр. Һәр авыл үзе бер бәйрәмне яратарак төшә:

Мәләкәсләр — Питрауны, Әхмәтләр — Элҗенне (Ильин день)...

* * *

Ачрак заманда үскәнгәме, бүтән сәбәптәнме мин Покрау бәйрәмен (Покров) сагынып искә алам. Бу бәйрәмгә пыкрау тәкәсе суела иде. Әни берьюлы дүрт төрле бөккән (бездә аны тәкә диләр) пешерә: чөгендер кушылган киндер орлыгыннан, тары белән кабактан, ит белән эчәгедән, ә берсен иттән генә. Иң тәмле бәйрәм булып истә калган ул.

* * *

Берничә ел элек аерым театр — керәшен театры төзү идеясе бар иде. Җыелышка мине дә чакырдылар. Каршы чыктым. Керәшен театрын күрәсем килмәгәнлектән түгел, сәбәбе — андый театрның базисы юк. Аннары драматургиясе юк. Актерларын әле табарга да булыр иде, әмма бу гына җитми. Ярый, бер спектакль чыгардык, ди. Ә аннары? Барыбер этногра-
фик рухтагы кечкенәрәк нәрсәгә кайтып калачакбыз. Ә менә керәшеннәрнең этнографик җыр-бию төркемен оештырып булыр иде. Сакланып калган киемнәребез, йолалар, уен кораллары, җыр-биюләр белән. Төрле милләт кешеләре бер-берсенә кызыклы булган кебек, бер милләт эчендәге төрле төркемнәр дә шулай ук. Керәшеннәр турында пьеса язылгач, аны академия театры куйды. «Гөргери кияүләре»н Туфан зур хөрмәт белән язган. Ул киң күңелле, мәгълүматлы кеше буларак, күрә: халыкны сәнгать телендә чын күңелдән ачып бирергә кирәк. Шушы нәрсә баш режиссер Марсель Сәлимҗановның күңеленә дә үтеп керде. «Гөргери кияүләре»н караган халык керәшеннәрне яратып калды, дип уйлыйм.

* * *

Спектакльне әзерләгәндә, мин уен азып-тузып китмәсен иде, дип сагаеп йөрдем. Чөнки спектакль буенча иркенәергә мөмкинлекләр күп, артистларны тыебрак та торырга кирәк иде. Сәхнәгә чиреге белән самогон чыга, шул вакытта болганыбрак йөри башласаң, халык турында дөрес булмаган образ туарга мөмкин. Әле алай да элек бергә укыган керәшен якташым үпкәләп хат язды: безнең түтиләр болай киенеп йөрмәделәр, алай итмәделәр, болай итмәделәр, дип. Ул театральлекне тормыш белән турыдан-туры чагыштырган, уенны аңлап җиткермәгән, ахры. Аннары кием дигәннән. Без сатин күлмәкләр, резин галошлар заманында үстек. Ә спектакльдә —шакмаклы, каешлы чигәчеләр, җаңаксалар, сүрәкәләр. Вера түти, Нәҗибә анда Питрәч ягы керәшеннәренең сандыкларыннан чыгарылып сатып алынган чын киемнәрне киеп уйнадылар. Минем Мәтүрнә әбиемнең дә ука белән чигелгән җаңаксалары, чәчкаплары бар иде.

* * *

Минем татар культурасына береккәнлегем тел, моң аша килә. Гомерем татар театрында үтә. Иманым, йолаларым бераз гына аерылса да, мин — генетик хәтерем белән татар. Әйтик, Илһам Шакировсыз мин ничек яши алыйм, ди? Зыкинаны тыңлап алай ләззәтләнә алмыйм бит мин, никадәр генә бөек булса да, рус җырчысы минем җаныма Илһам кебек үтеп керә алмый...

Менә хәзер күп кенә җырчылар үз репертуарына керәшен җырулары ала башлады. Ул көйләр, күнегелгән пентатоник яңгыраштан аз гына читкәрәк чыгып, җыр кысаларын киңәйтеп җибәрә икән, бу уртак байлыкка әйләнмимени?!

## Керәшеннәргә мәхәббәт турында

Зал егылып көлде. Зал моңайды. Зал гашыйк булды. Керәшеннәргә...

Болар бөтенесе дә Камал театрының сезонны яба торган спектакле барышында булган халәтләр. Алай да, әгәр «Гөргери кияүләре»н Туфан Миңнуллинның иң уңышлы пьесасы дисәк, моңарчы язган һәм сәхнәгә куелган дистәләгән әсәрләрен бетереп ташлау булачак. Әлбәттә, иң көчле әсәре түгел бу күренекле драматургның. Хәтта спектакльнең материалын пьеса түгел диярге дә җөрьәт итәм әле мин. Ләкин авторны тәнкыйтьләү җәһәтеннән түгел (Туфан хәтле Туфан абыйны тәнкыйтьләргә хакым да юк минем), ә бары театр дигән зур сәнгать төренең хикмәтле, котелмәгән яклары хакында уйлану җәһәтеннән генә бу.

«Гөргери кияүләре»нең сюжеты исә бик гади... Гөргери абзый һәм Кәтернә тутинең төпчек кызы Үринә артыннан берьюлы өч егет йөри. Зур кызларының ир белән рәтле яши алмавының сәбәпләрен ата кеше «җола бозудан» күрә. Һәм төпчек кызын йолаларны төгәл үтәгән егеткә генә бирергә карар кыла. Менә шуннан китә инде «җола» белүче әбиләрне эзләү, характер, ягъни холык-фигыль күрсәтүдән дә бигрәк, йола белүне һәм булганлыкны күрсәтүдә ярышу, көрәшү, җырлашулар!

Керәшеннәрнең берсеннән-берсе матуррак борынгы киемнәре, тәңкәле калфаклары, хәситәләре, чүпләмле сөлге-
ләре һәм, әлбәттә инде, нәкъ керәшенчә, нәкъ үзләренчә җырлары һәм биюләре! Үзенә бер фольклор тамашасы инде бу! Вера апа Минкинаның тыпырдап җырлавы, Әсхәт Хисмәтнең бераз гына мөселманча татарлык кушылган моңнары, Рамил һәм Илсөяр Төхвәтулланың Салаватларга биргесез итеп җырлаган булып кыланулары, Нәҗибә Ихсаниның «түрлә-түрлә» итеп, кадерле керәшен әбие булып кулда гына йөрүләре, Дания Нурлының «боксы»... кыскасы, болар барысы да тамашачыны һәрдаим җанландырып торды. Рамил Төхвәтулла, Фирдәвес Хәйруллина, Дания Нурлы, Фәридә Минхафизат, һәркайсы үз роленнән «кәнфит» ясый. Яшь актер Искәндәр Хәйруллин үзенең Микушына үзенчәлекле төсмер салырга тырышты. Ә сөйләш! «Җаратмыйм дигәнем жук бит әле», «Җакшы торасызмы», «Кәтернә тутаң җанына килдеңме», «җәши-җәши җаратырсың», тагын әллә күпме тәмле, колоритлы сүзләр. Әһә, менә шушы матурлыкны күрсәтер өчен укмаштырган түгелме соң Туфан Миңнуллин әлеге тамашаны?

Безне керәшеннәрнең күңел дөньясына, эстетикасына алып керер өчен, әлеге татар телле, ләкин бүтәнчәрәк рухиятле халыкны безгә,— галимнәрчә әйтсәк, үзгә менталитетлы, үзгәрәк психологияле татар күпчелегенә якынайтыр өчен уйлап чыгарган түгелме соң ул әлеге «җолалы җәрәшүне»? Марсель Сәлимҗанов та шундый фикердән чыгып эш иткән — тамашачыга этнографик рухтагы тормыш күренеше күрсәтергә алынган. Ике кызыклы рольгә нәкъ менә керәшеннәрне — Вера апа Минкинаны һәм Наил (Николай) Дунаевны куйган. Моңарчы «чын безнеңчә милли» керәшен тамашасын зур сәхнәгә алып чыгу бәхетен күрмәгән шәхесләр өчен җан рәхәте булгандыр ул «Гөргери кияүләре».

Балетмейстер Сәлимә Әминованың гаҗәп зәвыклы, нәфис биюләрен «Биюче»дә (Лопе де Вега) күреп бер соклансак, әлеге халыкчан тамашада тагын бер тапкыр сөендек. Барыбызга да таныш керәшен көйләрен әлеге спектакль тукымасына чиккән оркестр һәм аның җитәкчесе Фуат Әбүбәкер, гомумән, уенда үзе бер роль уйный кебек. Ә рәссам! Таң Еникеев исеме бүген Башкортстанда гына түгел, бездә дә еш ишетелә. Дөресрәге, күренә («Идегәй», «Кишер басуы»h. б.). Бер танышым әйтмешли, рәссамның соңгы спектаклендәге йортының һәр тактасын сыйпап, иснәп карыйсы килә. Бу йорт — татар-керәшен дөньясының эчке бөтенлеге символы. Вакыйганың йорт эчендә түгел, ә йорт алдында, урам якта баруының да бер мәгънәсе бар кебек: бу очракта керәшеннең дине, иконасы, ягъни бездән, мөселманнардан, аермасы түгел, ә киресенчә, безгә якынлыгы, күңелчәнлеге үзәккә алынган кебек. Икенче төрле әйткәндә, халыкның эчендә — өендә, мич алдында, почмагында казынуның әсәре дә юк биредә. Керәшеннең үз-үзен тотышы, ачыклыгы аша чайпалып чыга торган сыйфатларын тану галәмәте бар.

Кыскасы, театр белгече булмасам да, мин моның стилизация икәнен чамаладым. Фольклористик, этнографик тирәнлеккә дәгъва итми торган җиңел бер стилизация. Шуңа да әгәр сезгә берәрсе пьеса интригасын кору, мотивация, фабуланың юри-мырыйлыгы дип сөйләнә икән, тыңламагыз. «Карарга күңеллеме?» — дип кенә сорагыз. Ә менә анысын — бик күңелле, бик рәхәт икәнен сезгә иң мүкләнгән театр белгече дә инкарь итмәс.

*Гадел Низам*

## Рух ныклыгы — бердәмлектә

Фронттагы бер хәлне исемә төшердем. 1942 нче елның 5 нче декабрендә, каты яраланып, госпитальгә эләктем. Анда миннән: «Син нинди милләттән?» — дип сорадылар. Мин: «Керәшен»,— дип җавап бирдем. Санитар: «Андый милләт бармыни?» — дип

гаҗәпләнде. Чынлап та, керәшеннәрнең Башкортстанның Бакалы районында бергә тупланып яшәве хакында бөтенесе дә белеп бетерми. Алар 9500 кеше исәпләнә, һәрьяклап сак бу халык хезмәт сөючән, горур, ышанычлы һәм намуслы. Кем дә булса бәлагә тарыса, һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер. Табигый, мин керәшен булуым белән горурланам. Тәүге пьеса-комедиямне 1954 нче елда, Уфада Башкорт академия драма театрында куйдылар. Афишага зур хәрефләр белән авторның исеме Николай Асанбаев дип язылган иде. Ул чакта мин исемем аркасында аңлашылмаучылык килеп чыгар дип көтмәгән дә идем. Эш шунда: башкорт һәм татар тамашачылары театрга килмәде, башка телдән тәрҗемә ителгән дип уйлаганнар. Шул чакта бер төркем артистлар миңа Нәҗиб Асанбаев дигән псевдоним алырга киңәш итте. Бер төн эчендә белдерүләрне яңадан язып элделәр һәм халык комедиягә ябырылып килә башлады. Шул вакыттан алып бөтен әсәрләрем Нәҗиб Асанбаев исеме белән чыга. Әмма якташларым мине керәшеннәргә хыянәт итүче дип атап, нахакка гаепләү белән чыгыш ясады. Бу инде ул чордагы хәлләргә үзенчә бер каршы тору иде. Чөнки керәшеннәргә этнос буларак үсү мөмкинлеген бирмәделәр. Алга таба беркайчан да хыянәтче түгеллегемне һәм ул адымга бармаячагымны, керәшен булуым белән горурлануым хакында сабырлык белән аңлатырга туры килде. Алар мине гафу итте. Әйе, мин башкорт телендә язам, башкорт телендә фикер йөртәм. Башкорт теле минем икенче туган телем һәм мин моның белән чын күңелдән горурланам.

Бөтенесен дә бер калыпка иңдерергә, тере адәм балаларын инкубатор чебешләренә әйләндерергә ярамый. Табигать кануннарын көч кулланып үзгәртеп булмый. Кеше әнисенең карынында яралган вакыттан ук үз халкының, үз милләтенең вәкиле булыр өчен туа. Үз милләтенең баласы булу — табигатьтән бирелгән изге, кадерле тойгы. Бу — якыннарыңа, ата-анаңа, халкыңа, туган илеңә сөю хисе, гасырлар төбендәге ата-бабаларыбыз авазы ул.

*Николай Асанбаев,*
драматург, Салават Юлаев
исемендәге премия лауреаты

* * *

Гел изгелек булсын бөтен кылганың,
Әй керәшен— асыл заты дөньяның.
Күпме кагу-сугу кичеп бу җаның,
Ару, имин саклый алдың иманың?!
Зирәк акыл, сабыр тоттың чыдады,
Кара каның, түкерергә кыймадың...

Барлыгың — хак, юлың— изге, динең—чын.
Табынганың — Ата, Ул һәм Изге Тын.
Шул халәттә мәңге сакла затыңны,
Тот изге ата-баба васыятеңне.

Әй керәшен — асыл заты дөньяның,
Гел изгелек булсын бөтен кылганың!
Гомер буе шушы ару юравым
Юлдаш булсын берүк сиңа, туганым.

*Ямаш Игәнәй*

## Һәрчак заманча яңгырар

«Керәшен халык җырлары» дип аталган яңа пластинка белән танышу кичәсенә дип Г. Тукай музеена чакырылгач, мин моңа бераз гаҗәпләнеп тә калдым. Керәшеннәр? Пластинка? Минем өчен бу бик зур яңалык иде. Шул чакта музыка белгече Геннадий Макаровтан ишеткән: «Татар халкы ул — чәчәк бәйләме»,— дигән сүзләр исемә төште. Чыннан да, шулай икән бит. Казан татарлары, Себер, Әстерхан татарлары, нугай, мишәр...

Кайларга гына сибелмәгән син, татарым! Бу чәчәк бәйләмендә керәшеннәрнең дә зур урыннары бар һәм аларсыз татар халкын күзалдына китерүе дә кыен.

Ләкин, кызганычка каршы, безгә алар турында еш ишетергә туры килми. Ә бит керәшеннәр ничәмә гасырлар буена борынгы гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен саклап кала алган. Аларның килеп чыгышын күпләр рус патшасы белән бәйли. Мин дә шундый фикердә идем…

Әлеге пластинкада язылган җырларны Г. Тукай музеенда танылган артистка Раиса Тимофеева һәм Татарстанның атказанган артисты, С. Сәйдәшев исемендәге беренче республика конкурсы лауреаты Георгий Ибушев кабат җырладылар, тамашачыларга керәшеннәрнең гореф-гадәтләре, йола-уеннары турында сөйләделәр.

Пластинкага язылган җырларны тыңлаганда, керәшен егетләре һәм кызларының дәртле һәм үзенчәлекле биюләре күз алдына килә. Һәрбер авыл кызы бу биюләрне кечкенәдән белә икән. Гүя тирә-юньне яңгыратып, талир тәңкәләр чыңына керәшен җырлары кушыла. Бу җыр-көйләрдә, биюләрдә — халыкның тарихы, хыяллары, уй-кичерешләре. «Керәшен җаны — җыр ул. Бу мәгънәдә алар уникаль»,— диде кичәне оештыручы һәм алып баручы Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, музыка белгече Клара Таҗиева.

— Мин бу җырларны кечкенәдән күңелемә сеңдереп калдым,— ди Г. Ибушев.

Шуңа, ахры, аеруча озын көйләр аның башкаруында бөтенләй яңа төсмер ала һәм аның моңлы тавышы күңелдә нечкә хисләр уята. Ә күпме тирән мәгънә, тойгы һәм кичереш Раиса ханым җырлавында. Шундый башкаручылар күбрәк булсын иде, диясе килә.

* * *

Ниһаять, пластинка турында берничә сүз. Керәшеннәр мәдәнияте тарихында ул — беренче пластинка. Анда Галина Казанцева, Нәфисә Василова, Георгий Ибушев, Раиса Тимофеева һәм башкалар башкаруындагы керәшен халык җырларының энҗе-мәрҗәннәре тупланган. Ул музыка белгечләре генә түгел, ә шагыйрьләр, фольклорчылар тарафыннан да югары бәяләнде. Алар арасында язучы Кояш Тимбикова, танылган фольклорчы Галина Чугунова, баянчы Геннадий Васильев һәм башкалар бар иде.

Әлбәттә, бер пластинка белән генә чикләнергә ярамый. Киләчәктә керәшеннәр мәдәнияте һәм тормыш-көнкүреше турында яңа әсәрләр, язма пластинкалар дөнья күрсеннәр иде.

Бу мәкаләмне музыка белгече Мәхмүд Нигъмәтҗановның «Татар халык җырлары» (1976 ел) дигән китабындагы сүзләр белән тәмамлыйсы килә: «Бөек Тукаебыз васыять итеп калдырган, халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә, аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһат итәргә кирәк». Бүген дә заманча яңгырый бу сүзләр!

*Гөлназ Мөбарәкова*

## Георгий Ибушев

Ибушев Георгий Мифодиевич 1957 нче елның 20 нче сентябрендә Мамадыш районындагы Владимир авылында колхозчы гаиләсендә туган. Гаиләдәге биш бала кечкенәдән үк керәшен җырларын яратып тыңлый һәм җырлый торган була.

Мәктәптә укыганда, 1974 нче елда Георгий «Яшь ленинчы» газетасының 50 еллык юбилеенда катнаша һәм җиңүче була, 1975 нче елда Казанда уздырылган «Комсомол җыры» конкурсында катнашып, диплом белән бүләкләнә. Усали авылындагы урта мәктәпне тәмамлагач, хәрби хезмәткә алына, аннан соң Түбән Кама шәһәрендә заводта эшли. 1978 нче елда Казан дәүләт консерваториясенең 2 еллык әзерлек курсларына укырга керә. Аны тәмамлагач, студент итеп укырга кабул ителә. Танылган укытучылар М. Ф. Кольцов — Чувашиянең атказанган артисты, Ә. Г. Заһидуллина — Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты егетнең тавыш мөмкинлекләрен, эчке тойгыларын аңлап, аңа җырлау серенең бөтен нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итәләр. 1985 нче елда Георгий Ибушев, консерваторияне уңышлы тәмамлап, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә билгеләнә. Шул ук елны Мәскәүдә уздырылган халык җырларын башкаручыларның Бөтенроссия конкурсында катнашып, дипломант исемен ала. Аннан соңгы елларда да ул Мәскәүнең данлыклы «Колонналы залы»нда иң югары дәрәҗәдәге дәүләт эшлеклеләре алдында өч тапкыр чыгыш ясый һәм югары бәяләнә.

* * *

Георгий Ибушев халык җырлары белән беррәттән композиторларыбызның җыр һәм романсларын, рус, чит ил композиторларының арияләрен, романсларын һәм җырларын яратып башкара. 1989 нчы елда «Татар җыры» конкурсында катнашып, лауреат исемен ала. 1990 нчы елда ул Салих Сәйдәшев исемендәге Республика конкурсының беренче лауреаты, 1995 нче елда Сәйдәшев музеенда, татар артистларыннан беренче булып, «Татар җыры» сәнгатенә тугры калган өчен «Ак бүлмә» ритуалын үтә. Татар җырын башкарудагы уңышларын искә алып, Георгий Ибушевка 1991 нче елда Татарстанның атказанган, 2000 нче елда Татарстанның халык артисты исеме бирелә.

Ибушев — артист кына түгел, шигырьләр дә яза. Аның шигырьләрен «Казан утлары», «Идел» журналларыннан, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Керәшен сүзе» газеталарында еш очратырга мөмкин. Күп кенә керәшен җырлары аның язмасында радио фондына алынган. Бүгенге көндә Георгий Ибушев филармониянең «Опера, камера» бүлегендә солист булып эшли. Тавышы тенор-альтино, ирләрдә бик сирәк очрый торган югары тавыш.

*Николай Максимов*

* * *

Георгий Ибушев шагыйрь булачак егет иде. Мәктәп елларында әйбәт шигырьләр язды да каядыр юкка чыкты...

Кинәт кенә таң вакытында илаһи бер көй ишетәм. Зәй керәшеннәренең туй җырлары дисәм — Ибуш җырлый икән. Әле бүген дә шигырь язуын белеп сокландым. Шигырьләре дә гасырлар катламыннан күтәрелгән керәшен моңына ияргән. Ходай аңа ярдәм һәм илһам бирсен.

*Мөдәррис Әгъләм*

## Әни янына

Син иртәгә мине уят, әнкәй,
Уят үзең торып килешкә.
Казларыңны куып төшәрмен мин
Җиңел томан сарган инешкә.

Һәм китәрмен чыклы сукмак буйлап
Инеш аръягына, болынга.
Тәрәзәдән күзләп борчылма син,
— Бу балага, диеп, ни булган?

Уйлама, бу барып зур калага
Ялгызлыкка, диеп, юлыккан.
Һәм эзләмә зәңгәр киңлек буйлап
Йөзеп барган ялгыз болыттан.

Нәрсә болыт? Аңа җилләр хуҗа,
Ул давыллап, күкрәп ала да,
Тагын ага ерак киңлекләргә
Көч җыярга, шаулап яварга.

Болыт түгел лә мин буйсынырга,
Бирелергә җилләр иркенә...
Тик күңелгә нидер җитми, әнием,
Нидер эзли җаным — җилкенә.

Нишләргә соң? Минем ярсу күңелем
Әллә тапты, әллә югалтты? —
Шаулы заллар үзенә тартты мине,
Җыр җылатты мине, юатты.

Сүзсез генә миңа үпкәләмә,
Әллә ниләр уйлап борчылма.
Теләсәм дә бөтен тормышымны
Сөйләп бирә алмыйм мин сиңа...

Иртән иртүк мине уят, әнкәй,

Уят үзең торып килешкә.
Казларыңны иртән мин куармын
Җиңел томан сарган инешкә.

## Музыка

Шундый йомшак, җылы сагыш булып,
Моң агыла — бу кем сагышы?
Айкап ала канны, чеметтереп,
Скрипканың уйчан тавышы.

Әнә, нидер әйтеп, вәгъдә итеп,
Әй биешә өлгер клавишлар
Алар сөйли, алар ышандыра:
— Җирдә олы сөю, бәхет бар!

...Һәм виолончель, үткәннәрдән килеп,
Сәлам әйтә миңа яшьлектән.
Яңагымны яндырып нәрсә узды? —
Шул музыка биргән яшь икән...

## Дустыма

Тормыш — диңгез, ә син нәни көймә,
Чайкалучы шушы диңгездә.
Күңелең синең ап-ак киндер җилкән,
Җилкәннәрне җилләр киерә.

Җил көймәне диңгезләргә куа,
Җилләр — язмыш, шуны онытма.
Җилкәннәрне керләнүдән сакла,
Давылларга омтыл, курыкма!

Тик ялгышма, җирдә ялгыз башка
Давылларга керү куркыныч.
Ак җилкәнле дусны юлдаш ит син,—
Юлдашсызны җиңә ул тормыш.

*Георгий Ибушев*

## Җырларында киек казлар моңы

Синең көйне бер тыңлаганнарның
Гомерлеккә өзелә үзәге.

*(Гәрәй Рәхим)*

Әлеге шигъри юллар Татарстанның халык артисты, Бөтенроссия смотры лауреаты, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисткасы Нәфисә Василовага багышланган сыман. Чыннан да, аның йөрәк түреннән ташып чыккан матур, бай, көчле тавышы кемнәрне генә сокландырмаган. Ул — Урал таулы, киек казлы, кәккүкле Җир-анабызның моңлы тавышыдыр кебек тоела. Моңа туган авылының табигате, җыр сөюче халкының, авылда иң оста җырчыларның берсе — әнисенең йогынтысы бәяләп бетергесез, әлбәттә.

Анастасия Петровна Васильева (Нәфисә Василова) Теләче районы Субаш авылында гаиләдә бишенче бала булып дөньяга килә. Әтисе сугышта үлеп кала. Гаиләнең бөтен йөге әнисе өстенә төшә.

Настя мәктәп елларында ук үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөри. Казанга күчеп килеп, шәһәрнең 13 нче татар мәктәбендә укый, төзелеш училищесын тәмамлый, үзешчән сәнгать түгәрәкләренә йөрүен дәвам иттерә. Нәфисә Василова керәшен җырларын йөрәгеннән чыккан моңнары белән башкарганда, тыңлаучы үзен сихри бер дөньяда итеп хис итә. Аңарда керәшен җырларына карата ихтирам, соклану хисләре туа, аларны тагын да тыңлау теләге уяна. Нәфисәнең сәләтен тиз күреп алалар. Республика үзешчән сәнгать

смотрында катнашып, лауреат исеменә лаек була. Нәфисә Василованы Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә чакыралар. Конкурста халкыбызның «Кара урман аша» дигән җырын башкара һәм бертавыштан ансамбльгә кабул ителә.

Нәфисә Василова башкаруында «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Беләзегем-йөзегем», «Кәккүк» һ. б. халык җырлары, Сара Садыйкованың Гөлшат Зәйнашева шигыренә язган «Үз илемдә», Мансур Шиһапов шигыренә язган «Яшьлегем эзләре» дигән җырлары кабатланмас яңгыраш алды. Халык җырларының асылына төшенеп, аларны үзенчәлекле итеп башкаруы тыңлаучыларны сокландыра.

Нәфисә Василова ансамбльгә килгәндә композитор Марс Макаров анда баянчы булып эшли һәм шул ук вакытта халык уен кораллары оркестры белән дә җитәкчелек итә. Шул чорда Нәфисәнең тавышын күздә тотып, ул Хәсән Туфан шигыренә язылган «Киек казлар» җырын иҗат итә. Җыр тамашачыга көчле тәэсир итә, концертларда бу җырның яңгырамаган чаклары сирәк була. Бу җырда Хәсән Туфан кичергән фаҗигаләр чагыла. Нәфисә Василова башкаруында әлеге җыр тыңлаучының күңелен тетрәндерә. Дөньяның нинди илләрендә генә яңгырамый ул.

Композитор Александр Ключарев бу җырны ансамбль хоры өчен эшкәртә, һәм ул ансамбль репертуарына да кертелә.

Нәфисә Василова татар, рус, казакъ, башкорт һәм башка халыкларның җырларын да зур осталык белән башкара, аны илебез шәһәрләре һәм республикалары тамашачылары гына түгел, Япония, Италия, Тунис, Мальта, Көнбатыш Африкада да алкышлыйлар.

*Елизавета Антонова*

## Киек казлар

*Марс Макаров* көе
*Хәсән Туфан* сүзләре

Яңгырларда, явымнарда,
Давылларда-җилләрдә
Киек казлар кыйгылдаша
Мин белмәгән телләрдә.

Киек казлар кыйгылдаша,
Җырлашалар микәнни?
Туган илләр кала бит, дип
Елашалар микәнни?

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.
Киек казлар кыйгылдаша,
Сау бул, якташ, диләрдер;
Әллә кайтыр, әллә кайтмас
Безнең башлар, диләрдер.

Казлар кебек очасылар —
Китәселәр юк минем;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дияселәр юк минем.

Кыйгылдашып болытларда
Мин белмәгән телләрдә,
Киек казлар китеп бара
Мин күрмәгән илләргә.

## Лидия Әхмәтова

Лидия Әхмәтова 1962 нче елның 17 нче октябрендә Кайбыч районындагы Соравыл авылында туа, шунда ук урта мәктәпне тәмамлый. 1981 нче елда Казан музыка училищесына, аны 1985 нче елда

тәмамлагач, шул ук елны Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә. 1992 нче елда аны Казан дәүләт педагогика университетының музыка факультетына эшкә чакыралар.

1989 нчы елда «Татарстан тавышы» конкурсында катнашып, ул лауреат исеменә лаек була. 1991—1992 нче елларда «Татар җыры» конкурсында катнашып, дипломант исемен ала. 1994 нче елда Салих Сәйдәшев исемендәге вокалистлар конкурсында лауреат исеменә лаек була. 1992—2002 нче елларда В. Деринг җитәкләгән оркестр составында аерым программа белән катнаша, Татарстанның һәм Россиянең күп кенә шәһәрләрендә, чит илләрдә — Австрия, Финляндия, Германия, Төркия дәүләтләренең концерт залларында чыгышлар ясый. 1992—1994 нче елларда төшерелгән «Галиябану» телефильмында төп рольне башкара. 1995 нче елда «Борынгы Болгарның җылы җилләре» исемле фильмда Ак бүре ыруындагы шаман ролен уйный. 1996 нчы елда татар җыры сәнгатенә керткән хезмәтен олылап, Лидия Әхмәтовага Татарстанның атказанган артисты исеме бирелә. Аның репертуарында татар композиторларының (Р. Яхин, М. Мозаффаров, А. Монасыйпов һ. б.) әсәрләре, «Керәшен моңнары» вокал циклы, чит ил композиторлары арияләре бар. Ул татар халкының фольклор җырларын җыю, эшкәртү һәм яңадан халыкка кайтару белән дә актив шөгыльләнә. Соңгы елларда аның репертуарына керәшеннәр арасында яратып башкарыла торган «Ай Биби», «Әкрен-әкрен без бараек», «Соравыл көе», «Ал да гөл булып кына», «Кыр үрдәге», «Түгәрәк күл» кебек җырлар да өстәлде.

*Николай Максимов*

### Авылга кайтып киләм

*Л. Әхмәтова* көе
*Г. Рәхим* сүзләре
Шатлыгымнан, сагышымнан
Бер җырлыйм да бер көләм.
Сагындым туган ягымны:
Авылга кайтып киләм.

Кушымта:

Кайтып киләм мин авылга
Таныш сукмаклар буйлап.
Яшьлегемдә өзелеп сөйгән
Мәхәббәтемне уйлап.
Чит җирләрдә озак йөрдем
Аерылып туган җирдән.
Сагынуларга түзмәдем —
Авылга кайтып киләм.

Кушымта.

Исәнмесез, ак каеннар,
Исәнме, ялгыз имән?
Барыгызны да сагынып,
Авылга кайтып киләм.

### Ай Биби

Җырларга кушсагыз, мин җырлыймын
Берне генә түгел, ди, ай Биби, икене.
Җырламас ла идем мин икене,
Сөям, дигән сүзегез, ай Биби, сөйкемле.

Кушымта:

Ай Биби, Биби, Биби,
Мин саргайдым сез ди-ди.
Сезнең йөзегезне безнең күзебез
Күреп туймый көнозын.
Ашасыгыз килсә, аша шикәр,

Түләүләрен үзем, ди, ай Биби, түләрмен.
Әҗәлегез җитсә, әйт үземә,
Сезнең өчен үзем, ди, ай Биби, үләрмен.

## Каратай буе

*(Керәшен җыры)*

Каратай буена, әй яшьләр төшкән
Түгәрәккәй уен уйнарга.
Каратай буе, әйдәгез, җырлашыйк әле.
Түгәрәккәй генәй уйнаганда,
Уртага кем чыгар җырларга.
Каратай буе, әйдәгез, җырлашыйк әле.
Каратай сулары — агым су,
Комнар белән катыш агадыр.
Каратай буе, әйдәгез, җырлашыйк әле.
Җырлашканнар, безнең бу гөрләшкәннәр,
Истәлекләр булып, әй, калыр.
Каратай буе, әйдәгез, җырлашыйк әле,
Гөрләшик әле.

## Зоя Борисова

Зоя Борисова — яшь буын артистлардан. Ул 1972 нче елның 27 нче маенда Балык Бистәсе районындагы Алан-Полян авылында туган. Күрше Шеморбаш авылындагы урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килеп, заводка эшкә урнаша. Анда өч ел эшли. 20 яшендә Казан музыка училищесына укырга керә. Анда дүрт ел дәвамында Ания Туишева классында укый. Аны бетергәч, лирико-сопрано тавышлы кызны Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә солистка итеп эшкә чакыралар. 2000 нче елда ул, Салих Сәйдәшев исемендәге вокалистлар конкурсында катнашып, икенче премияне ала, лауреат исеменә лаек була. Җыр һәм бию ансамбле составында чит илләрдә — Ирак, Төркия, Франция, Испания, Германия, Париж, Финляндия һәм башка дәүләтләрнең концерт залларында күрсәткән тамашаларда катнаша. Киләчәктә, музыкаль белемен күтәрү максатыннан, укуын Сәнгать академиясендә дәвам итәргә уйлый.

*Николай Максимов*

## Безнең Валя-Валентина

Мәкаләмнең исемен башта мин Кәләй сандугачы дип атарга уйлаган идем, аннан соң күңелемә Керәшен сандугачы, Әлмәт сандугачы дигән фикер дә килде. Ләкин Сандугач дип кемне дә булса атыйбыз, зурлыйбыз, хөрмәтлибез икән, аны артык конкретлаштыруыбыз белән без бу иҗатның тәэсир итү колачын тарайтабыз, әһәмиятен чиклибез түгелме? Сандугач — җырчылар патшасы, Сандугач икән — бу мәртәбәле исемгә лаек булган зат бөтен халыкныкы һәм вәссәлам! Артык та түгел, ким дә түгел.

* * *

Валентина Исламованың алтын юбилее якынлашып килгән көннәрдә үзем өчен әнә шундый ачыш ясадым да язмама үз итеп, якын итеп, «Безнең Валя-Валентина» дигән исем куйдым. Безнең дияргә хакым да бардыр кебек — юк, дустым, якташым, замандашым Илфат Исламов хатыны булган өчен генә түгел, Әлмәт районының Кәләй авылында туып-үскән Валентина Георгиевна Брагина-Исламова — җыр өлкәсендәге минем тыйнак иҗатымның шактыен халыкка җиткерүче иҗатташым да бит әле ул.

Әйе, Валентина Исламованың һәм, гомумән алганда, Илфат, аның абыйсы Инсаф һәм Инсафның җәмәгате Розалия — гомумиләштереп әйткәндә — Исламовларның сәхнә фидакарьлеге каршында баш иючеләр, рәхмәт әйтүчеләр мин генә түгел, алар күп. Һәм кара алтын төбәгендә генә дә түгел, Исламовларны татарлар яшәгән бик күп җирләрдә беләләр, алкышлыйлар. Валентина да бергә-бергә дә, аерым

да Болгария, Казакъстан, Балтыйк буе республикаларында, Мәскәүдә, Башкортстанда күпме тапкырлар чыгыш ясады, тамашачыларга җыр-моң, кабатланмас шатлык мизгелләре бүләк итте.

Талантны ясап та, сатып алып та булмый, ул — Аллаһы Тәгаләдән. Ул яки бар, яки юк. Талантны бары тик ачарга һәм үстерергә мөмкин. Валентинаның таланты — тумыштан. Ул үзен белә-белгәннән бирле җырлый.

Татар халкы җыр ярата, уен-көлке ярата, кунаклар җыйса, өстәлдәге сый белән генә канәгатьләнми, күңеле хәзинәсендә барын да юмарт өләшә. Күңеле нечкәреп киткән ата-ана моның ише чакта үзенең балалары белән дә, җаен табып, мактанып алырга онытмый. Менә шундый вакытларда Георгий дәдәй дә, кечкенә Валяны җырлатып, кунакларын сокландырудан рәхәт минутлар кичерә. Тик Валя үзе генә бик кыргый, җырлаганда кешеләргә күренергә ояла, өстәл астына кереп җырлый. Өстәл астын «сәхнә» иткән вакытлар уза, Валя инде мәктәптә укый, мәктәптәге бер генә кичә дә аның катнашыннан башка узмый.

— Бигрәк тә «Юлларым» җырын яратып башкарганымны хәтерлим,— дип искә ала ул үзенең кояшлы бала чагын.

Җырны ярату үсмер кызда музыка белән тирәнрәк танышу теләге тудыра һәм ул Кәләй мәктәбендә оештырылган баян түгәрәгенә йөри, ярыйсы ук уйнарга да өйрәнә. Мәктәпне тәмамлаган вакытка ул инде төпле фикергә килеп өлгергән була: җырчы булам!

Шушы максат аны, сигезенче сыйныфны тәмамлаганнан соң, Лениногорскидагы педагогия училищесына алып килә һәм Валентина анда педагог Р.Н.Вәлиуллин классында укып, музыка серләренә төшенә: баянда уйнавын камилләштерә, аккордеон, фортепьянода уйнарга өйрәнә, тавышын чарлый. Укып бетергәннән соң туган төбәгенә кайтып, Урсала, Түбән Мактама мәктәпләрендә, Әлмәтнең 2 нче мәктәбендә балаларга музыка нигезләрен өйрәтә. Хәзер, чирек гасыр инде, ул балалар бакчасында, шуның соңгы 15 елын — «Ямашнефть» идарәсенең прогимназиясендә. Нәниләрдә җыр-моңга мәхәббәт тәрбияли, аларның уңышлары өчен куана. Быел ул тәрбияләгән беренче сыйныф укучысы Наташа Шулина «Сандугач сайрар илем» фестивалендә Казаннан лауреат исеме алып кайтты.

Лауреат дигәннән, андый исемнәр Валентина ханымның үзендә дә буа буарлык: Татарстанда, Башкортстанда уздырган кайсы гына конкурс-фестивальдә катнашмасын, ул йә Гран-при, йә лауреат исемен алып кайта. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Валентина Исламовага Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия дә бирелде.

Талантлар белән очрашканнан соң, мин еш кына, талантның башы, чишмәсе кайда соң әле, дигән уйга калам. Валентиналар нәселендә дә моңа кадәр сәхнәгә менеп җырлаучы булмаган. Ләкин әтисе Георгий дәдәй матур итеп гармунда уйнаган, ә әнисе Татьяна түти, банкага калаклар салып, җырчыларга көч биреп торган булган. Ә, бәлки, чишмә башы тугач та тыңлап үскән керәшен җырларындадыр?

Җырчы Илфат белән җырчы Валентинаның дәвамчылары бу мәсьәләдә ничегрәк соң? Кызлары музыка мәктәбендә укыган, шулай ук бию белән мавыгалар. Ләкин җырда әниләре белән ярышырлык түгел.

— Оныкларым Алена белән Алина җырларга яраталар, бигрәк тә 4 яшьлек Алинаның тавышы матур,— дип куанычын уртаклаша Валентина әбиләре.— Улыбыз Айдар да сәхнәгә еш күтәрелә, ул җырлый.

Валентина халык көйләрен дә, композиторлар җырларын да яратып башкара. Ә инде керәшен җырларына килгәндә, бигрәк тә «Кәләй урамнары» кебек үз авылларында туган җырны башка берәү дә аның кебек моңлы һәм ягымлы итеп башкармый кебек тоела миңа.

Аның Әлмәт композиторларына, бигрәк тә Рәис Нәгыймовка хөрмәте-ихтирамы зур. Бу ихтирам нигезендә озак еллар бергә иҗади хезмәттәшлек, бер-берсенә карата олы ихтирам ята. Сәхнәгә Валентинаның Рәис Нәгыймовтан башка чыгып җырлаган чаклары бик сирәктер.

50 яшен тутырган Валентина Исламова үзенең керәшен кызы булуы белән горурлана. «Керәшен сүзе» газетасына берничә ел элек биргән интервьюсында ул болай ди:

— Керәшеннәр үзләренең керәшен икәнлекләреннән оялмасыннар... Беркайчан да үземнең чыгышымнан, керәшен булуымнан гарьләнмәдем. Мин керәшен кызы, дип курыкмыйча әйтәм, яратып әйтәм, ышаныч белән әйтәм. Чөнки безнең керәшеннәр — яхшы күңелле, бертуганнар кебек ярдәмчел, бердәм халык...

*Нур Әхмәдиев*

### Кәләй авылы җыры

Кәләй урамнары ла озын урам,
Баш-башларында тимер лә,

Ай-һай ла кулиса.
Эндәшәм, эндәшәм, ауаз бирми
Кәләй урамнарында
Ай-һай ла, җугалсам.
Кәләй урамнары ла — озын урам,
Җөрсәң, сусарлар ла
Ай-һай ла тотарсың.
Кәләй җегетләре лә бигрәк матур,
Сулы кашык белән лә
Ай-һай ла җотарсың.
Эзей буйларына ла без төшәрбез,
Колачларны җәеп лә
Ай-һай ла җөзәрбез.
Кычкырыр күке лә, сайрар былбыл,
Шул чакларда ничекләр,
Ай-һай ла түзәрбез.

## Аграфена Васильева

Аграфена Васильева 1956 нчы елның 13 нче ноябрендә Түбән Кама районының Келәтле авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, 1974 нче елда Казан театр училищесының актерлар әзерләү бүлегенә керә, 1978 нче елда Кәрим Тинчурин исемендәге театрга эшкә билгеләнә. Бу театрда эшләү елларында Ю. Сафиуллинның «Әллә өйләнергә инде?» дигән әсәре буенча эшләнгән спектакльдә — Гөлли, И. Юзеевның «Командировка»сында — Сайра, М. Гафуриның «Кара йөзләр»ендә малай образларын иҗат итә.

Артистканы, талантын күреп, 1981 нче елда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына эшкә чакыралар.
Ул монда эшләү елларында К. Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә — Сәҗидә, «Зәңгәр шәле»ндә — ишанның дүртенче хатыны һәм малай, Л. Леоновның «Ябырылу»ында — Аниска, И. Юзеевның «Улыбыз өйләнә — без аерылышабыз»ында — Чикерткә Нәзнинәсе, Ю. Сафиуллинның «Ләйсән ире Хә-сән»ендә — авылдан килгән кыз, Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй» спектаклендә — кыз бала, М. Горькийның «Һаваларда йолдыз»ында — кыз, М. Кәримнең «Ай тотылган төндә» спектаклендә — Ишморза, Н. Исәнбәтнең «Зифа»сында — Гөлли, Лопе де Веганың «Белиса маҗаралары»нда — хезмәтче кыз, «Ике хуҗаның хезмәтчесе»ндә — йомышчы һәм пешекче малай, Т. Миңнуллинның «Алай түгел — болай ул» сәхнә әсәрендә берьюлы дүрт образны уйнаган.

Аграфена Васильеваның балалар өчен язылган әсәрләрдәге образларны тудыруы бигрәк тә уңышлы булгандыр: Т. Миңнуллинның берничә өлештән торган «Акбай маҗаралары»нда — Тәкә, Чарли, Бүре кызы һ. б.

Аграфена Васильева хәзерге көндә үсеп килүче яшь буынга мәктәпләрдә театр дәресләре укыта, Татарстан радиосында «Арумысез, керәшен карендәшләр!» дигән тапшыру алып бара, күп кенә башка төр эшләрдә актив катнаша.

*Николай Максимов*

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН КОМПОЗИТОРЛАР**

*Марс Макаров* (Норлат районындагы Чура Батыр авылы), *Марсель Иванов* (Минзәлә районындагы Чулпан авылы), *Геннадий Максимов* (Зәй районындагы Федоровка авылы), *Роберт Андреев* (Сарман районындагы Баткак авылы).

## Марс Макаров

Марс Макаровка табигать күпкырлы музыкаль сәләт биргән. Ул — виртуоз оста баянчы-башкаручы; шул ук вакытта күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтерлек серле аһәңгә ия булган музыкаль әсәрләрнең авторы да.

Марс Макаров 1939 нчы елның 28 нче октябрендә Норлат районы Чура Батыр авылында туа. Кечкенәдән ул халык музыкасын, аның нечкә моңын күңеленә сеңдереп үсә. Композитор үзе бу хакта «Татар баянчылары» дигән китапта болай искә ала: «Музыкага омтылышым, булган кадәр сәләтем биш-алты яшьләремдә ачыла башлаган булса кирәк. Авыл халкы сөйләве буенча, минем әтием гармунда матур

уйный торган булган, ә әниемнең әкрен генә җырлап утыруын мин әле дә хәтерлим, сагынып искә алам... Минем көйгә-моңга, музыка дөньясына тартылуым, һичшиксез, әниемнең җырлавы һәм әтиемнең гармунда уйнавы белән бәйле. Әнидән отып алган көйләр, әнидән ишеткән ул җырлар, яшермичә генә әйткәндә, бүгенге көндә дә минем иң яратып уйный торган әсәрләрем».

Әнисе турындагы хатирәләр, аңа булган рәхмәт сүзләре Марс Макаров күңелендә әнә шулай тирән мәхәббәткә әверелеп яши. «Бала йоклату» җырының дөньяга килүе, аның сүзләрендә һәм көендә ана назы белән өретелгән чиксез кадерле ерак балачак тойгыларының гаҗәеп бер нечкәлек, төгәллек белән тасвир ителүе дә һич очраклы түгел, әлбәттә.

Әниләргә багышланган җырлар арасында Макаровның тагын бер җырын билгеләп үтәсе килә. Бу җыр — Зиннур Насыйбуллин шигыренә иҗат ителгән «Кара шәле килә сөйрәлеп» әсәре. Аның үзәгендә — сугыш кырыннан килгән аяныч хәбәр ишетеп, югалту һәм эчке тетрәнү белән авыр атлап баручы ана образы. «Кара шәле килә сөйрәлеп» җыры аналарга багышланган күп санлы лирик җырлардан образның яңача ачылышы белән аерылып тора. Ул — көчле ихтыярлы, нык, авырлыкларга туры карый белүче каһарман ана образы.

М. Макаров әсәрләренең тәэсир итү көче темаларының автор тормышы белән нык бәйле булуындадыр, күрәсең. Белүебезчә, аның әтисе 1942 нче елны вафат була. Бөтен тор-мыш авырлыгы аның әнисе җилкәсенә төшә. Әлбәттә, моны бәләкәй Марс һәрдаим күреп һәм тоеп үсә. Бүген бу хакта поэтик сүзләрнең килеп очравы белән аның күңелендә музыкаль образның да кичекмәстән балкып, яктырып китүе һич очраклы түгелдер. Аның Чечняда һәлак булган улларга багышланган «Югалган солдат» дигән җыры белән дә нәкъ шулай була.

Композиторның яратып тасвирлаган темалары күптөрле. Соңгы елларда ул иҗат иткән әсәрләр арасыннан Габдулла Тукайның мәшһүр «Шүрәле» поэмасына нигезләнгән «Кырлай» вокаль-поэтик композициясе, безгә калса, аерым игътибарга лаек. Бу нисбәттән аның башка җырлары да игътибарга лаек, әйтик, «Мәк чәчәге» җыры һ. б.

60 нчы еллар башында, Хәсән Туфан халыкка кайткач, аның шигырьләре радиодан яңгырый башлый һәм композитор әлеге шагыйрь сүзләренә «Киек казлар», «Агыла да болыт агыла» җырларын иҗат итә. Бу әсәрләр радиодан яңгырагач, аларны Хәсән ага ишетә һәм үзе, Макаровның өенә килеп, зур рәхмәтен белдерә. Шагыйрь үзенең шигырьләр китабына җылы хисләрен, теләкләрен: «Марс энем, «Киек казлар» кебек күркәм җырларың тагын да өстәлеп торсын иде»,— дип язып калдыра, һәм, моның нәтиҗәсе буларак, тиздән радиодан хисләрнең нечкәлеге һәм эчке тирәнлеге белән таң калдырырлык «Юксындырсаң нишләрмен?» җыры яңгырый.

«Киек казлар», «Агыла да болыт агыла» — Хәсән Туфан шигъриятенең иң югары музыкаль гәүдәләнеш үрнәге. Аларны хор өчен поэма дип атарга мөмкин.

Марс Макаровның хор һәм оркестр өчен бер әсәрен искә төшерик. Ул — 1968 нче елда үткәрелгән «Иң яхшы җыр» республика бәйгесендә премиягә лаек булган, Гамил Афзал сүзләренә иҗат ителгән «Татар-стан таңнары» җыры. Әлеге әсәр үз вакытында Марс Макаровның «Каз канаты» фантазиясенә югары бәя биргән һәм аны «Баян өчен симфония» дип атаган танылган композитор А.С.Ключарев белән очрашу тәэсирендә туган.

Марс Макаровның шулай ук «Көмеш тояк тулпар атым» (халык сүзләре), «Язгы ташу» (Рәдиф Гаташ шигыре), «Кыңгырау чәчәкләре» (Клара Булатова шигыре) һәм башка җырларын билгеләп үтәсе килә. Һәрбер әсәрдә туган якка, аның матурлыгына чиксез мәхәббәт ярылып ята. Композиторның музыкасы йөрәккә тирән үтеп керә. Бу музыка гади дә, якын да кебек һәм шул ук вакытта ерак та кебек, чөнки ул һаман да сине үзенә тарта, һаман аның тирәнлегенә үтеп керү теләге арта. Аның әсәрләрен башка композитор әсәрләре белән бутап булмый.

*Клара Таҗиева,*
музыка белгече

## Геннадий Максимов

Радиодан безнеңчә матур, моңлы җыр агыла: «Моңлану», «Үпкәлимсез миңа, якташларым...» Җыр күңелләрне үзенә җәлеп итә, дулкынландыра, сагышландыра...

Шушындый матур җырлар туганга, шундый җырлар иҗат итүчеләребез булганга куана-куана, тизрәк аның авторын беләсе килә...

Яңа җыр, яңа исем... Геннадий Максимов. Баянчы Геннадий Максимов.

Моңлы да, дәртле дә, саф, аһәңле көйләр... «Әнкәмнең туган ягында», «Уйларым — ак челтәр», «Оч син, җырым».

Еллар үткән саен, бу исем белән яңгыраган җырлар арта барган саен («Тургайлар», «Килерсең әле, килерсең», «Зәй гүзәле» һ. б.) композиторның үзе белән якыннанрак танышу теләге дә арта бара. Һәм менә «Зәй гүзәле»нең авторы үзе дә Зәй төбәгенең Сармашбаш елгасы буенда яшеллеккә күмелеп утырган Федоровка авылында туып үскән моңлы бер җан икән бит! Ул — татар мәдәниятен, музыкасын кечкенәдән яратучы, аның өчен җан атып яшәүче Геннадий Григорий улы Максимов.

Гармунчы Григорий белән җырчы Ксения гаиләсендә туган һәм, кечкенәдән әнисе белән тутасы Светлананың матур моңлы җырларын тыңлап, туган авылының саф һавасын сулап үскән бала ничек итеп җыр-моңнан читтә кала алсын соң?!

Моңлы бала булу өчен, язмышы да үз өлешен кертә тора: Геннадийга өч яшь тулганда, әтисе вафат була.

Әтисенең улы турында: «Эх, гомерем булып, әгәр малаем туса, соңгы телем икмәгемне сатып булса да гармун алып бирер идем...» — дигән сүзләрен исендә тотып, ана ничек итсә итә, әмма кечкенә улына гармун алып бирү теләгенә ирешә.

Кечкенә Геннадий кулында гармун, тирә-ягында моңлы җырлар, музыка... Малай үскән саен күңелендә җыр-моңга булган мәхәббәт тә арта. Егет инде үзе дә яңа көйләр иҗат итә башлый.

Музыка буенча махсус урта белемле, ә электроника буенча югары белемле булган Геннадий, җырлар иҗат итү белән бергә, танылган артистларга аккомпаниаторлык итү белән дә шөгыльләнә.

*Николай Максимов*

## Кемең бар?

*Геннадий Максимов* көе
*Егор Уткин* сүзләре

Карашларың калган
Якты кыр бар.
Көлүләрең калган
Болын бар.
Синең кебек
Зифа тирәкләр бар.

Тирәкләрдә —
Яшел толымнар.
Елмаюың калган
Якты күл бар.
Кошлар отып калган
Көең бар.
Күңелемдә
Мәңге сыза торган,
Син калдырган
Утлы төен бар.
Карашларың калган
Якты кыр бар.

Елмаюың калган
Күлең бар.
Сине хәтерләткән
Тирәкләр бар.
Синең анда,
Синең кемең бар?

## Керәшен такмаклары

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре
Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөргөри.
Гөргөри дигән керәшен
Чибәр, пычак кергери.

Гөргөри кем ул, дисәгез,
Гөргөри ул — керәшен.
Көндез уйлап та карамыйм,
Төнлә төшкә керәсең.
Анда чаба Гөргөри,
Монда чаба Гөргөри.
Эш эшләргә вакыты юк —
Кызлар артыннан йөри.

Уйна, дустым, гармуныңны
Керәшен көйләренә.
Уф йөрәгем, гашыйк булдым
Керәшен чибәренә.

## Роберт Андреев

Роберт Андреев 1955 нче елда Сарман районындагы Баткак авылында туган. Бүгенге көндә композиторның йөзгә якын җыры бар. Шулар арасында, төрле буын артистлары һәм үзешчәннәр башкарып, халык күңеленә кереп алганнары да аз түгел: «Гармун моңы булып» (Ш. Маннапов сүзләре), «Гомер юлдашың булыйм», «Күңелемә язлар кайтты», «Су буенда кыяк үлән» (К. Булатова сүзләре), «Кайтарыгыз», «Төшләремә керәсең» (А. Минһаҗева сүзләре), «Мин яратам сине, Татарстан» (Р. Рәкыйпов сүзләре), «Күңелем һаман сиңа ашкына» (Ә. Фәтхи сүзләре), «Шаулый урман» (Г. Зәйнашева сүзләре) һ. б. Хәзерге вакытта Роберт Андреев Әлмәт шәһәрендә яши һәм актив иҗади эш алып бара.

*Николай Максимов*

## Мин яратам сине, Татарстан

*Роберт Андреев* көе
*Роберт Рәкыйпов* сүзләре

Мин яратам сине, Татарстан,
Ал таңнарың өчен яратам.
Күк күкрәп, яшен яшьнәп яуган
Яңгырларың өчен яратам.

Мин яратам сине, Татарстан,
Горур халкың өчен яратам.
Җан эреткән әнкәм теле өчен —
Татар телең өчен яратам.

Арыш кырың, урманнарың өчен,
Җәйләүләрең өчен яратам.
Тукайларың, Сәйдәшләрең өчен,
Җәлилләрең өчен яратам.

Мин яратам Әлмәт, Яр Чаллыны,
Киң күңелле Казан каласын.
Илем бакчасында, Татарстан,
Ал канәфер булып янасың.
Татарстан, сине яратам!

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН РӘССАМНАР**

*Капитонов И. К.* (Кайбыч районы Хуҗа Хәсән авылы), *Комаров В. И.* (Менделеевск районының Иске Гришкино авылы), *Красильников Д. Н.* (Минзәлә районының Урта Пенәче авылы), *Краснов П. Ф.* (Балык Бистәсе районының Үри Чаллысы авылы), *Максимова В. П.* (Актаныш районының Киров исемендәге поселогы), *Тюкенеев Н. Н.* (Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк районы).

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН ТАНЫЛГАН СПОРТЧЫЛАР**

*Альметов А. Д.* (Киев шәһәре), *Бәширов И. А.*, *Золин А. П.* (Питрәч районының Кибәч авылы), *Канашев Г. И.* (Питрәч районының Янсуар авылы), *Кибардина Н. Н.* (Чаллы шәһәре), *Князева О. Н.* (Казан шәһәре), *Колесников Н. А.* (Бөгелмә районының Наратлык авылы), *Симашев Ф. П.* (Зәй районының Югары Баграж авылы), *Степанов Н. В.* (Питрәч районының Янсуар авылы), *Тимофеев С. Ф.* (Казан шәһәре), *Чернов М. П.* (Питрәч районының Талкыш авылы).

**КЕРӘШЕННӘРДӘ КӨРӘШЧЕЛӘР ДӘ КҮП**

Туган якларын көрәшчеләр ягы итеп таныткан, Сабан туе мәйданнарында, татарча көрәш буенча төрле ярышларда бил алышып, тамашачыларны сокландырган батырлар арасында керәшен ир-егетләре дә байтак. Заманында Сабантуйларда берничәшәр мәртәбә баш батыр булып калган *Эрнст Федотов* һәм *Петр Марков*, танылган көрәшчеләр *Михаил Минеев* (хәзер Ютазыда яши), *Павел Марков, Иван Куляев, Виталий Ионов, Григорий Назаров, Яков Тазов, Иван Усачев, Михаил Сергеев, Данил Филиппов, Андрей Демидов, Юрий Иванов, Виталий Кузнецов, Иван Бәширов, Михаил Чернов* һәм башкалар (биредә исемнәре телгә алынмый калганнар гафу итсен, барысын да санап чыгу мөмкин түгел) — әнә шундыйлардан.

## Җиңелү белмәс Виссарион

Татарстан Республикасының Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт комитеты һәм Татар-башкорт спорт көрәше федерациясе 60—70 нче елларның иң танылган ун көрәшчесенә Республиканың атказанган спорт мастеры дигән мактаулы исем бирелү турында таныклыклар тапшырды.

Диктор аларның төрле елларда octкан дәрәҗәле ярышларны санады һәм спорт ветераннарын зур зал уртасына таныклык алырга чакырды. Көрәш сөючеләр һәр батырны бик җылы каршылады. Ә менә Виссарион Канашев исеме әйтелүгә, зал аеруча көчле алкышлар белән тулды. Гүя җырга гашыйк тамашачылар үзләренең иң яраткан эстрада йолдызын сәламли иде...

Виссарион Канашевны олырак яшьтәге көрәшче көндәшләре үзләре өчен иң зур үрнәк итеп санадылар. Танылган көрәш осталары Габдрахман Галиев, Гайнетдин Мөхәммәдиев, Фәрит Әхмәдиев аның көрәшенә һәм мәйдан уртасында үз-үзләрен тотышына әлегә кадәр соклануларын әйтәләр.

Аның яраткан алымнары — уң кулның терсәге белән көндәшенең сул кулын кинәт күтәреп җибәрү, көндәшен күтәреп екканда, уң аяк белән булышу — үз авырлык үлчәвендәге яки авыррак үлчәүдәге бер генә көрәшчегә дә җиңүгә өмет калдырмады.

Урта үлчәүдәге төз гәүдәле, нык чибәр керәшен егете халыкның яраткан көрәшчесе иде. Аның катнашуы һәртөрле дәрәҗәдәге ярышларны һәм Сабантуйларны бизәде, аларның абруен күтәрде. Әтием, үзе стажы булган көрәш остасы, төрле елларда халыкны шаккатырган өч пәһлеванны еш искә ала. Болар — Курса Корыгы (кушамат), Наласа Әхәт һәм Виссарион Канашев.

Виссарион Канашев 1949 нчы елның 18 нче декабрендә Питрәч районының Ыксуар авылында тугыз балалы ишле гаиләдә туган. Авыл малайлары кечкенәдән татарча көрәш атмосферасына эләгәләр, матур табигатьле Ыксуарның яшел болыннарында әүмәкләшәләр, үзара көч сынашалар. Ир туганнарыннан Николай, Иван һәм Григорий да татарча көрәш белән ныклап шөгыльләнәләр.

Унсигез яшендә Виссарион Питрәч районының Иске Йорт авылында беренче тапкыр Сабантуй батыры булып кала. Көрәш мәйданындагы бу тәүге зур уңышы, беләкләрендә ташып торган көче аңа татарча көрәш белән ныклап шөгыльләнергә этәргеч була. 1970 нче елда армия хезмәтен тутырып кайтканнан соң, ул, һич икеләнмичә, Гайнетдин Мөхәммәдиев җитәкләгән татарча көрәш секциясенә барып керә. 1971—1978 нче елларда Татарстан һәм Россия беренчелекләрендә җиңелү белми. Питрәч, Арча, Совет, Киров һәм Идел буе районнары Сабантуйларында күп тапкырлар абсолют батыр була.

Виссарион беркемгә дә ташлама ясамый, үзеннән 2—3 потка авыррак танылган көрәшчеләрне бер-бер артлы җиңелүгә дучар итә. Аның өстенлеге беркемдә дә икеләнү калдырмый. Танылган көрәшче 1974—

1978 нче елларда Казан шәһәр Советы депутаты итеп тә сайлана. 1982 нче елда Казан дәүләт педагогия институтының физик тәрбия факультетын тәмамлап, спорттагы практик белемнәрен теоретик нигез белән ныгыта.

*Марсель Кадыйров*

## Үткер аның кылычы

Аның исеме матбугатта беренче тапкыр кайчан яңгырады икән? Казандагы 3 нче балалар-үсмерләр спорт мәктәбенә йөри башлагачтыр, мөгаен. 1966 нчы елда, әле уникe яшь тулар-тулмаста, Короленко урамындагы бу мәктәпкә аны әтисе Николай Князев җитәкләп алып килде һәм кызын тренерлык эшен әле үзе дә яңарак кына башлаган спорт мастеры Владимир Житлов кулына тапшырды.

Менә шул чакта Ольга үз өстенә ак төстәге махсус спорт киеме киде, кулына рапира алды һәм тренеры өйрәткән беренче алымнарны ясады. Ә бит аңа бирегә гомуми белем мәктәбеннән соң йөрергә туры килә иде. Әтисе: «Кызым, икесенә дә өлгерерсеңме соң? Әллә спорт мәктәбен ташлыйсыңмы?»-дисә дә, Ольга, үҗәтләнеп, йөрүен дәвам итте. Фехтование «җене» уникe яшьлек кызны үзенә әсир иткән иде инде.

Кыз спорт мәктәбеннән һәркөнне арып-талчыгып кайтты. Әмма шундук дәресләрен хәзерләргә утыра иде. Яраткан
шөгыль шулай инде ул: кешегә әчке рух өсти, аңа канат үстергәндәй итә. Ольга белән дә шундый хәл иде. Теләче районының Тәмте һәм Балык Бистәсе районының Шеморбаш авылларында гади крестьян гаиләсендә туып үскән эти-әнисе өчен элеккеге югары катлау кешеләре уены бик сәер иде, билгеле. Әмма кызлары яраткач, нишлисең соң?

Һәм тиздән Ольга Князева спорт мәктәбе чемпионы булды, Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова кебек талантлы дуслары белән Россия һәм СССР беренчелеге ярышларына йөри башлады. Озакламый аңа СССР спорт мастеры исеме бирелде. Ә 1974 нче елда исә халыкара класслы спорт мастеры дигән мактаулы исемгә лаек булды. Тагын бер елдан ул СССРның җыелма командасы составына кертелде. Шулай итеп, аңа халыкара ярышларга бик җаваплы бәйгеләргә юл ачылды.

— Алар өчесе дә аерылмас дуслар иде. Тырышлык ягыннан да бер-берсеннән калышмадылар һәм спорт үрләрен бик җиңел яуладылар,— дип искә ала бүген әлеге кызлар турында аларның остазы, СССРның һәм РСФСРның атказанган тренеры, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Владимир Васильевич Житлов.

Бу кызлар исеме илебез спорты тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Аларның өчесе дә СССРның атказанган спорт мастерлары, күп тапкырлар Россия, СССР һәм дөнья чемпионнары. Өчесе дә Европа һәм Дөнья Кубогына ия булды. 1976 нчы елда Монреальдә XXI җәйге Олимпия уеннарында катнашып, өчесе дә команда исәбендә чемпион исемен яулап алды. Болардан тыш, Ольга Князева 1975 нче елда дөньяның иң көчле рапиристкасы дип тә танылды әле.

Бу данлы кызлар бүген ничек яши соң? «Без үзара һәрвакыт аралашып, бер-беребезнең хәлен белешеп торабыз. Хәзер барыбыз да тренерлар булып эшлибез»,— ди Ольга Князева. Казан финанс-икътисад институтының физик тәрбия кафедрасында өлкән укытучы булып эшли ул. Бик матур гаиләсе дә бар. Әйбәт ана буларак, Ольга Николаевна иренә дә, балаларына да ныклы терәк булып тора.

...Казанда «Теләче йолдызлыгы» дигән исемдә якташлык җәмгыяте оешкач, танылган спортчы Ольга Князева аның кичәләренә бик теләп йөри башлаган иде. Теләче ягын якын итүен һәрвакыт сиздереп торды. Үзе Казанда туып үссә дә, әтисенең туган авылы Тәмтедә үтә аның бөтен бала чагы, һәр җәйдә шунда кайта, янәшәдәге инештә су коена, урманга җиләккә йөри, каз бәбкәләре саклаша. Әлбәттә, моңлы керәшен җырларын тыңлап, үз халкының үзенчәлекле гореф-гадәтләрен күреп үсә. Менә шуңа күрә дә ул, бүген һич икеләнеп тормыйча: «Мин бит Теләче ягыннан, керәшен кызы!» — дип авыз тутырып әйтә.

*Нургали Булатов*

## Кичер

*Никифор Тукмачев* сүзләре

Хыялымда сиңа көн дә киләм,
Төшләремдә сине көн дә күрәм.
Яшим хыялларым белән,
Сөеклем, бер генәм.

Кушымта:

Кичер, тәүге мәхәббәтем,

Кичер...
Язмышлардан узмыш булмас.
Ялгышларны мәңге
аңлап булмас,
Йөрәкләрне мәңге алдап булмас.

Хисләремне җырга салыйм әле,
Җыр-моң булып сиңа
барыйм әле.
Яннарыңда калыйм әле,
Дөрләп яныйм әле.
Мин дип уйла, җилләр сөеп узса,
Керфегеңә энҗе карлар кунса.
Галәмнәрдә йолдыз очса,
Ак бураннар кочса.

Гомеребез тик бер мизгел генә,
Яшьлек — чәчәк аткан
бер гөл генә.
Шул гөлләрне салмыйк утка,
Үпкәләшмик юкка.

Кычкырам ла җиһанга, дөньяга,
Мин яратам,
мин бер бәхетле бала.
Күңелем, канат кага-кага,
Сиңа алып бара.

## Батырларның батыры

Аның белән бер сөйләшеп утыру да күңелгә рәхәтлек бирә. Уртача буйлы, нык гәүдәле, көлемсерәп торган ачык йөзле, энергиясе ташып торган бу ир-атка сокланып карыйсың. Инде илле яшен тутырса да, һаман шулай егетләрчә булуының серен сораша башлыйсы килә. Ә Сергей Тимофеев кебек танылган спортчы өчен моның бернинди дә сере юк. Спорт залында көн саен физик күнегүләр белән шөгыльләнү, спиртлы эчемлекләрне бөтенләй кулланмау, тәмәке тартмау, көндәлек режимны бозмау һ. б. лардан тора ул.

Сүз ирекле көрәш буенча күп тапкырлар Россия чемпионы, Россия Федерациясе халыклары спартакиадасы җиңүчесе, СССР Кубогы иясе, күп халыкара бәйгеләр батыры, 1976 нчы елда Монреальдә узган җәйге Олимпия уеннары призеры, халыкара класслы спорт мастеры Сергей Федорович Тимофеев турында бара. Ул инде биш ел Казанның Дербышки бистәсендәге «Ракета» спорт-сәламәтлек комплексы генераль директоры булып эшли. Соңгы елларда, бик яхшылап реконструкция ясагач һәм яңа корылмалар төзегәч, әлеге комплекста Россия күләмендәге ярышлар уздыру мөмкинлеге дә ачылды. Бу эшләрнең барысы өчен дә, әлбәттә, Сергей Федорович бетмәс-төкәнмәс энергиясе белән үзе башлап кайгыртып йөрде. Бүген андагы секцияләргә Дербышки бистәсеннән, Казанның төрле почмакларыннан һәм янәшәдәге Биектау районыннан 1300 ләп малай һәм кыз йөри икән.

— Шулай итеп, безнең комплексны хәзер чын мәгънәсендә спорт-сәламәтләндерү үзәге дип әйтергә була. «Ракета»ның ясалма бозында алкалы хоккей бәйгеләре генә түгел, көрәш, бокс, баскетбол, фигуралы шуу, туплы хоккей, җиңел атлетика буенча да ярышлар даими узып тора. Моннан тыш бик әйбәт чаңгы базабыз бар. Кыш көне анда күп гаиләләр җыелышып килә,— ди Сергей Федорович.

Ул бик хаклы рәвештә, спорт, барыннан да элек, кешеләр сәламәтлеген ныгытуга хезмәт итәргә тиеш, ди. Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре һәм гомумбелем урта мәктәпләрендәге секцияләр эшен нык җанландырырга кирәк дип саный. Шунсыз без яшьләребез арасындагы булачак спорт йолдызларын да югалтырбыз, егет-кызларыбызны физик яктан чыныккан итеп тә тәрбияли алмабыз. Танылган спортчы әлеге фикерләрен, җае чыккан саен, җитәкчеләргә җиткереп тора.

...РСФСРның атказанган тренеры Җаббар Гафиятуллин уртача гына буйлы бу үсмергә 1966 нчы елда беренче тапкыр ничек игътибар иткәнен хәзер дә әйбәт хәтерли. «Ул һәр өйрәткән яңа алымны бик тиз

отып ала һәм, көндәше белән көрәшкәндә, шунда ук куллана да иде. Җиңүгә нык омтылышы, тырышлыгы белән дә ошады миңа Сергей»,— дип искә ала Җаббар Барый улы.

Тәҗрибәле тренер малайның әти-әнисе белән дә таныша. I группа Бөек Ватан сугышы инвалиды Федор Тихонович һәм «Герой-ана» исемен йөртүче Агафья Николаевнаның алтынчы баласы икән ул. Ә гаиләдә барлыгы 11 бала. Теләче районындагы Тәмте дигән бик борынгы тарихлы керәшен авылыннан күчеп килгәннәр Тимофеевлар. Авылда өйрәнгән хезмәт ярату, бер-берсе өчен ныклы терәк булырга тырышу, өлкәннәрне хөрмәт итү һ. б. шуның кебек матур сыйфатлар аларның һәрберсенә хас. Әлеге гаилә белән танышкач, Җаббар Барыевичта үзенең шәкертенә ихтирам тагын да арта. Һәм тренер аның белән бик ныклап шөгыльләнә башлый.

Сергей дә сынатмады, җиңү арты җиңү яулый. Башта шәһәр, аннары Татарстан чемпионы була. Тиздән аның даны еракларга тарала. Аны «җиңелү белмәс Тимофеев» дип йөртәләр. 1975 нче елда СССР җыелма командасына алынгач, Сергей Тимофеевка илебез данын Европа чемпионатында якларга туры килә. Һәм якташыбыз, финал ярышларында Румыния көрәшчесе Петре Комайны зур өстенлек белән җиңеп, чемпион исемен яулап ала. Аның әлеге тәҗрибәле көрәшчене җиңә алуы күпләрне сокландыра. «Безгә Сергей Тимофеев кебек талантлы яшьләрне җаваплы бәйгеләргә һич курыкмыйча тартырга кирәк. Ничек акыллы һәм оста көрәшә ул! Аның мөмкинлекләре искиткеч зур! Сергейның киләчәктә Олимпия биеклекләрен яулый алачагына да ышанам мин»,— диде Европа чемпионатында аның көрәшен карагач, өч тапкыр Олимпия чемпионы, СССРның атказанган спорт мастеры Александр Медведь.

Һәм менә якташыбыз 1976 нчы елда Монреальдә, җәйге Олимпия уеннарында. Ул беренче өч очрашуында көндәшләрен зур өстенлек белән җиңде. Тагын ике алыштан соң Сергей Тимофеев җиңү пьедесталында булыр кебек иде инде. Моңа беркем дә шикләнмәде. Әмма соңгы минутларда арбитрлар аның күп кенә уңышлы алымнарын нигәдер «күрмәделәр» һәм очко исәпләмәделәр. Нәтиҗәдә Сергей Тимофеевка призлы алтынчы урын белән канәгатьләнергә туры килде...

Монреальдән медаль белән кайта алмау кыю рухлы якташыбызның канатын сындыра алмады: Сергей Тимофеев әле күп җиңүләр яулады. Соңрак, остазы Җаббар Гафиятуллин белән бергәләп, тренерлык эшенә кереште. Аның күп шәкертләре хәзер спорт мастерлары инде.

— Гадәттә, танылган спорт осталары гаилә традициясе буенча үзләренә алмашка улларын тәрбиялиләр. Бу яктан Сезнең мактанырлыгыгыз юкмы? — дип сорадым очрашу вакытында Сергей Федоровичтан.

— Безнең гаиләдә кыз бала туды шул,— диде ул гаепле кеше сыман.— Әмма моңа карап күңелне төшергән юк. Мин хәзер бертуганымның улы Федорны көрәшкә әзерлим. Ул инде спорт мастеры, Татарстан җыелма командасы әгъзасы. Исән-сау булсам, энекәшне алдагы җәйге Олимпия уеннарына әзерләргә исәплим. Тимофеевлар турында киләчәктә ишетерләр әле!

Менә шундый матур планнар, көндәлек ыгы-зыгы белән яши ул халыкара класслы спорт мастеры Сергей Тимофеев.

*Нургали Булатов*

### Аккош күлләрдә генә

Аккош күлләрдә генә,
Чәчәк гөлләрдә генә.
Хатларың юк, сәламеңне
Көтәм җилләрдән генә.
Язмышка күнәр дисеңме,
Хисләр сүнәр дисеңме?
Кыз бала язмышы шундый,
Әле түзәр дисеңме?
Бозлар кузгала бер,
Җаннар сызлана бер.
Дөньяның янарга килгән
Азмы кыз баласы бар.

Әйтерсең ялгыз каен яши,
Мәңге ялгыз башкаем.
Аккош булсаң, кайтыр идең,

Аккош кайта ел саен.
Кулъяулыгы тузамы,
Чәчәкләре уңамы?
Яшь гомерең миннән башка
Риза булып узамы?

*Никифор Тукмачев*

## Исемнәр казанмаса да

Альбом. Кеше гомеренең иң истәлекле мизгелләрен үзенә сыйдырган альбом. Бер кеше гомеренең мизгелләрен генә дию дөрес булмас. Әнә бит патша армиясе гаскәрие киеменнән япь-яшь бер егет карап тора. Якыннары, Василий Афанасьевич Прасовның, Николай II нең тән сакчысы булуы һәм 23 яшендә, 1917 елда Николай патшаны саклап булса кирәк, үлгәнлеге хакында сөйлиләр. Гаиләдә өченче бала булып дөньяга килгән Василий Афанас кебек үк озын буйлы иде.

Мария — бу гаиләдәге ун баланың төпчеге. Авыр сынаулар тигән аның язмышына. Ире Кузьма кавалерист була. Альбомдагы сурәттә дә ул кавалеристлар киеменнән, күн итекләре шпорлы, кулында нагайка. Кыю үткен карашы еллар аша үтеп, бүгенгәчә килеп җитә кебек. Гражданнар сугышы вакытында Буденныйда атлы армиядә хезмәт иткән Кузьма фин сугышында һәлак була.

Сарман ягының Ләке авылында дөньяга килгән улы Эрнстны кочаклап, хатыны Мария ялгызы кала. Хәер, шул ук Сарманның Дүсем ятим балалар йорты директорының ялгызлыкны тояр вакыты, ай-һай, булдымы икән?!

Әнә бер яшь тә дүрт айлык Эрнст Федотовның зур агач урындыкка утырып төшкән фотосы. Йөзендә сабыйларга хас булмаган җитдилек, олысыманлык. Әйтерсең шул чакта ук ул үзенең әнисе кочагыннан да бик иртә аерыласын тойган. Дүсемдәге балалар йортында тәрбияләнүче малайларның чәчен пәке белән кырып алганда, күбесенә, шул исәптән Эрнстка да, тимрәү йога. Капчыкка сохари тутырып, бер төркем авыру баланы Казанга дәваланырга җибәрәләр. Директор булып эшләүче әнисе Мария аларны туклану исемлегеннән сызмый. Болай да ачлы-туклы яшәүче балаларның башкаларына күбрәк тимәсме, дип уйлый.

Кем җиткергәндер, билгесез, әмма моның өчен аны ун елга төрмәгә утырталар. Шулай итеп, алты яшьлек Эрнст әнисез дә кала. Тоткын булып Урал якларында урман кисүче әнисен бары тик җиде елдан соң гына азат итәләр (сиксән өч яшьлек Мария Афанасьевна хәзерге вакытта Чаллыда яши. Сүз уңаеннан, Мариянең бертуганының оныгы Раиса Дмитриевна Ипеева икәнен әйтеп үтик. Ә аны Чаллыда гына түгел, ә республикада да белмәгән керәшен сирәктер).

Альбомдагы икенче бер фотога уелган сүзләр дә ап-ачык шәйләнә: «Отличник детдома, 1949 г.» Бу Эрнстның үзе булган Карамалы, Борды, Бәйрәкә ятимнәр йортларының кайсысында төшкән фотосы булды икән?!

Еллар узу белән саргайган рәсемнән бер төркем егетләр, кызлар карап тора. Алар — Чаллы мәктәбенең унынчы класс укучылары. Араларында иң озыны Эрнст. Мәктәптән соң ул Чистай техникумында авыл хуҗалыгы механигы белгечлегенә укый. Нәкъ шул чагында чынлап торып спорт белән шөгыльләнә башлый. Алай дип әйтү дөрес үк булып бетмәс, чөнки сигезенче сыйныфта укыганда ук ике потлы герне кырык бишәр мәртәбә күтәрә ул. Акча җитмәгәч, сигезне бетергән елны, ирләр белән беррәттән, баржадан капчыклап күмер бушатырга йөри.

Техникумда укыган елларда спортның биш төре буенча Россия чемпионы исемен яулый. Чемпионның спортта тренеры авыр физик хезмәт була. Көндезләрен укый, төннәрен капчык белән йөк ташый.

Нәкъ шул елларда төшкән бер фотосы — дөресрәге, газетадан кисеп алган сурәте — саклана аның альбомында:

Эрнстка бүләк тапшыру мизгелләре. Республика газетасында басылган ул рәсем астында язуы да бар: «Гер күтәрү буенча Э. Федотов Татарстанның яңа рекордын куйды. Ул 32 килограммлы герне 96 тапкыр күтәрде...» Техникумда укыганда ук ул чаңгы буенча да беренче разряд нормасын үти.

Армиядә хезмәт иткәндә, җыелма команда составында волейбол, җиңел атлетика, көрәш буенча хәрби частьларының данын яклый. Соңыннан, Чаллыдагы 8 нче училищеда производствога өйрәтү мастеры булып эшләгәндә дә, республика күләмендәге ярышларда катнаша.

Ә инде Казан педагогия институтының физик тәрбия факультетында укыганда, ул спортта биеклек, арты биеклек яулый. Ядрә ыргыту буенча институт рекордын яңарта, гер күтәрү буенча республика чемпионы була. Студент егет Багражда Сабан туенда көрәшеп батыр кала. Көч дигәне булса да, татарча

бер мәртәбә дә көрәшеп карамаган егетне туганы Иван Тазов (Түбән Кама көрәшчесе Яковның дәдәсе) үгетләп, мәйдан уртасына чыгара. Егетнең өстенлеген элекке батыр да танырга мәҗбүр була: «Трактор көче бар синдә, тик хәйлә юк».

Икенче елны Сарман Сабан туенда батыр кала. Үткән Сабан туе батырын да бөтереп кенә салган егеткә «ФЭД-3» фотоаппараты һәм тәкә, ә үз көрәшчеләренә алтын сәгать бүләк итә сарманлылар. Уңышлардан канатланган егет Казан Сабан туйларында да бил алыша башлый. Көрәш мәйданында өч ел рәттән атаклы Сергеев белән туры килә. Соңгы икесе Эрнстның җиңүе белән тәмамлана. Шуннан соң, Самбо буенча ун мәртәбә Татарстан чемпионы Сергеев көрәш мәйданында башка күренми.

1967 нче елда Совет-Япония дуслыгы көннәрендә Казанның үзәк стадионында студент егет көрәшче Раббани Гайфуллин белән татарча көрәш буенча японнар алдында күрсәтмә чыгыш ясыйлар. Шул елны ул «Волга» яшьләр лагерында космонавт Юрий Гагаринны күрү бәхетенә ирешә. Ә менә икенче бер истәлекле мизгел сурәтләнгән фоторәсем аның альбомында да урын алган. Анда — атаклы биюче Мәхмүт Эсамбаев, янәшәсендә — шундый ук озын буйлы Эрнст. Егетнең эчке горурлыгы йөзенә үк чыккан. Краснодарга ярышларга баргач, аэропортка килеп төшүгә үк, дөньяга танылган биючене күреп алган була спортчы егетләр.

Ике елдан соң аның язмышы Түбән Кама белән бөтенләйгә бәйләнә. Институтны тәмамлаган егетне 6 нчы мәктәп директоры Н. Максимов үзләренә физкультура укытырга чакыра. Шул елны Сүбәләк янындагы Сабан туенда бу якның көрәшчеләре М. Чернов, Н. Камалов, П. Марковлар белән мәйданда очраша һәм батыр кала. 1973 нче елда Муса Җәлил исемендәге зур призга булган ярышларда Түбән Камадан катнашкан биш көрәшче арасында Эрнст Федотов та була. Сүз тыңлаучан егет, үз араларындагы атаклы көрәшчегә каршы килә алмыйча, үз авырлыгыннан күпкә зуррак үлчәүдә көрәшергә риза була. Һәм, шулай итеп, икенче урынга гына кала.

Әлеге ярышта һәм шулай ук үткән Сабан туйларында үзенә карата гадел булмауларына күңелендә рәнҗү йөртеп, шул хис тимердәй егетнең көчен тагын да арттыргангамы, ул, шул елгы шәһәр Сабан туенда бернинди хәрәмләшүгә урын калдырмаслык итеп, көндәшен чиста җиңүгә ирешә.

Бик яшьли, әле буыннары ныгымас борын авыр эшкә җигелү еллар үтү белән үзен сиздерә. Шуңа күрә Эрнстның көченә сокланучылар Сабан туеның көрәш мәйданында башкача аны күрмиләр. Әмма шулай да ул спортны ташламый, ветераннар арасында булган ярышларда көчен сынауны дәвам итә: 1986 нчы елда Россиядә җиңел атлетика буенча чемпионатта ике алтын, бер көмеш медальгә лаек була, Швециядә уздырылган Европа чемпионатында ветераннар арасында уңышлы чыгыш ясый.

Спортның унике төре буенча беренче разряд нормасын үтәгән, гер буенча сигез мәртәбә Татарстан чемпионы булып калган, ничәмә-ничә Сабан туйларында мәйдан тоткан, шул исәптән 1969, 1970, 1973 нче елгы Түбән Кама Сабан туйларында баш батыр булып калган Эрнст Федотовның спорт мастеры, атказанган спортчы кебек мактаулы исемнәренең берсе дә юк. Аның каравы тормыш юлы спорттан аерылмаган Эрнст Федотовның уңышлары спорт сөючеләр хәтерендә. Шулай ук мондый истәлекләр төрле елларда шәһәребез мәктәпләрендә, техникумнарында аның дәресләрендә физик чыныгу алган егетләр, кызлар күңелендә сакланадыр. Спорттагы биеклекләренә сөенеп, уңышсызлыкларына үзеннән дә ныграк көенеп яшәгән хатыны укытучы Гөлсинә ханым да — тормышта һәрчак аның терәге. Уллары — «Нефтехим»да электромеханик булып эшләүче Эдуард һәм ГИБДД инспекторы Робертка гына, нишләптер, әтиләреннән зур спортка булган тартылу күчмәгән. Кем белә, бәлки, оныклары бабасы юлын сайлар.

Альбомдагы фотодан, чәчләре чалара башласа да, егетләрдәй төз, нык гәүдәле Эрнст Федотов карап тора. Әгәр дә үзе әйтмәсә, аңа икенче елга алтмыш яшь тула, дип һич тә уйламассың. Хәзерге вакытта 21 нче мәктәптә хезмәт укытучы Эрнст Кузьмич Федотов шул юбилее елында көрәш мәйданына чыгарга, яшьлек куәтен искә төшереп алырга җыена. Уңышлар аңа! Һәм тагын бер теләк: тормышның күбрәк спорт белән бәйле мизгелләрен үз эченә алган альбомында буш битләр күп булсын һәм аларда әле дистә еллар дәвамында гомеренең иң истәлекле мизгелләрен чагылдырган фотолар урын алсын.

*Фирая Моратова*

* * *

Кодрәтеңне салчы, берүк,<br>
Һәр эшемә дип, тотынган —<br>
Үтенәм Илаһи Тыннан...<br>
Теләк итеп, әйтеп иман,<br>
Уң ит дип, эшемне кылган —<br>
Сорыймын Атадан-Улдан...

Игелекле һәр эшемә
Куәт бир, диеп ялварам
Инәлеп Изге Анадан...
Алдына килеп баш иеп,
Уң булмаса эшем кылган —
Кичерү сорыйм халкымнан…

*Ямаш Игәнәй*

## Кеше китте, эзе калды

Зәй халкы бөек улын югалтты. Олимпия, 2 мәртәбә дөнья, 12 мәртәбә СССР чемпионы Федор Симашев мәңгелеккә арабыздан китте. Ашыгып, үтә вакытсыз тартып алды аны үлем. Югары Багражның гап-гади егете, тырышлыгы һәм талантын эшкә җигеп, 1968 елда илнең иң көчле 10 спортчысы исемлегенә керә, чемпион була, исемен илгә һәм дөньяга таныта.

Без аның белән иң беренче «Чаңгы юллары» исемле китабы аша таныштык һәм укучыларыбызны да таныштырдык.

Аннан соң «Зәй һәм зәйлеләр» дигән Татарстан телевидениесе тапшыруында аның әнисе Федора түтине күрдек.

1991 ел иде. Көтмәгәндә «Зәй офыклары»на «Шәһри Казан» газетасы мөхәррире Илдус Илдарханов, «Ялта-Зәй» спорт комплексы директоры Эдуард Галиев һәм мөлаем йөзле ир уртасы бер кеше килеп керделәр. Ул Федор Симашев булып чыкты. Озак сөйләштек без ул чакта. Дусты турында күбрәк Илдус сөйләде. Федор Петрович безнең сорауларга бәйнә-бәйнә җавап бирде. Ул да, без дә бераз дулкынланган, әсәрләнгән идек. Безне ул гадилеге, кешелеклелеге, тыйнаклыгы белән таң калдырды. Ниндидер эчкерсезлек, самимилек ярылып ята иде анда. Әнә шул эчкерсез самимилек, ул ирешкәннәр белән бергә үрелеп, гаҗәеп күркәм холык тәшкил итә иде. Алты ел дәвамында без бу тыйнак, сабыр кеше белән тыгыз элемтәдә яшәдек: очрашып, хәбәрләшеп тордык, аның турында язмалар бирдек. Безнең барлык хатын-кызлар аңа бераз гашыйк иде. Яратмаслык түгел иде шул Федор Петровичны. Дан-шөһрәт аз гына да бозмаган иде аны. Масаю, эрелекнең әсәре дә юк, йөзендә һәрвакыт тыйнак елмаю балкыр, әйткән сүзен үтәмичә калмас, сөйләшенгән вакытка минуты-секунды белән килеп җитәр. Ул Зәйгә зур өметләр баглап, якташлары, аеруча балалар арасында спортны үстерәм, дип кайтты. Кайту белән җиң сызганып эшкә кереште. «КамАЗ-Автоагрегат» җитәкчелеге аңа бу эшчәнлеге өчен бөтен мөмкинлекләрне тудырырга тырышты. Чаңгы спортының сүнеп баруы, балалар һәм яшьләр сәламәтлеге начарлануга борчылып яшәде.

Ул соңгы елларда чаңгычыларның һөнәри авыруы — бронхиаль астмадан җәфа чикте. Әмма авыру ул һәм без уйлаганга караганга да аяусызрак булып чыкты. Әҗәл аны чаңгы ярышларына барган җирдә — Бөгелмәдә эзләп тапкан.

Без Федор Петровичны соңгы юлга озата да, каберенә бер уч туфрак та сала алмадык, мөгаен, каберен дә күрә алмабыз —гаиләсе аны Мәскәүдә җирләүне кирәк тапты.

*В. Гаврилова*

## Ак сиреньнәр

*Никифор Тукмачев* сүзләре

Ак сиреньнәр бүген
шау чәчәктә,
Тирә-якка хуш ис тарата.
Сандугачлар әле уянмаган,
Сызылып кына таң ата.

Кушымта:

Алсу таңнар күчкәнме,
Йөзләреңдә таң төсе.
Бар җиһанда сирень исе,
Йөрәктә сөю хисе.
Мәхәббәттер бу кичереш,
Үзе татлы, үзе ачы,
Тынычрак типче, йөрәк,
Уятма сандугачны.
Ак сиреньнәр безгә
пышылдыйлар:

Сез бәхетле, бәхет шушы ул.
Иреннәрнең татлы табышуы,
Йөрәк тибешләре кушылу.

Кушымта.

Ак сиреньнәр,
безгә ак сиреньнәр
Хәер-фатихасын бирделәр.
Киләчәктә ак бәхетләр теләп,
Ак чәчәкләргә күмделәр.

Кушымта.

**КЕРӘШЕННӘР АРАСЫННАН ЧЫККАН АТКАЗАНГАН УКЫТУЧЫЛАР**

*Климов А. С.* (Менделеевск районының Иске Гришкино авылы), *Любов С. Н.* (Питрәч районының Талкыш авылы), *Максимов Б. Г.* (Балык Бистәсе районының Үри Чаллысы авылы), *Максимов Н. М.* (Мамадыш районының Керәшен Ерыксасы авылы), *Моисеев Е. В., Мурин К. Д.* (Менделеевск районының Яңа Гришкино авылы), *Сабанаев И. А.* (Чаллы шәһәре), *Сабатеева Н. П.* (Зәй районының Якты Күл авылы), *Сергеев Н. С.* (Кайбыч районының Соравыл авылы), *Токранов И. З.* (Балык Бистәсе районының Иванай авылы), *Читров А. Д.* (Питрәч районының Кибәч авылы).

**АТКАЗАНГАН ТАБИБЛАР**

*Кормачев М. В.* (Лаеш районының Ташкирмән авылы), *Макарова Л. Г.* (Балтач районының Чепья авылы), *Михайлова З. М.* (Казан шәһәре).

**АТКАЗАНГАН АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ**

*Козлов Г. П.* (Менделеевск районының Бөрешле авылы), *Колпаков Б. И.* (Удмуртиянең Грахов районы), *Степанов А. В.* (Балык Бистәсе районының Казак Чаллысы авылы), *Тарасова З. С.* (Менделеевск районының Сәйтәк авылы)

**АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ**

*Кириллов К. К.* (Мамадыш районының Урманче авылы), *Кузнецов Н. Е.* (Мамадыш районының Керәшен Ерыксасы авылы), *Муханов Г. С.* (Чистай шәһәре), *Петров Р. А.* (Кукмара районының Кукмара бистәсе), *Тимофеева Р. С.* (Башкортстандагы Бакалы районының Бакалы авылы)

## Гурий Тавлин

Милләтебезнең асыл затларыннан берсе Гурий Иванович Тавлин 1925 нче елның 25 нче декабрендә Татарстанның Зәй районы, Урта Баграж авылында туган. Күрше авылларындагы урта мәктәпне тәмамлагач, 1942 нче елда хезмәт юлын Түбән Биш җидееллык мәктәбендә укытучы булып башлаган. Мәктәптә укыган елларында «Яшь ленинчы» газетасының актив хәбәрчесе булган. Аның шигырьләре башта шул газетада дөнья күргән...

1943 нче ел башында Кызыл Армия сафларына чакырылып, сугышчан юлын танкист буларак, Курск дугасында башлаган. Аннан соң Днепрны кичү дәһшәтендә катнашкан. Украинаны, Белоруссияне, Польшаны юлбасарлардан азат итү өчен аяусыз бәрелешләрдә күрсәткән фидакарьлекләре өчен өч орден һәм төрле медальләр белән бүләкләнгән.

1946 нчы елда армиядән демобилизацияләнгәч, Г. Тавлин Казан дәүләт педагогия институтына укырга кергән. Студентлык елларында «Кызыл Татарстан» һәм «Яшь ленинчы» газеталарында берничә шигырен, Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», В. Ажаевның «Мәскәүдән еракта», Б. Бхаттачаривның «Ачлык» романнарына караган рецензияләрен бастырган. 1950 нче елның 23 нче январенда нахак яла нигезендә кулга алынып, совет строена каршы милләтчелек рухында контрреволюцион агитация алып баруда гаепләнгән һәм Татарстан Югары суды тарафыннан җиде елга ирегеннән мәхрүм ителеп, Себергә озатылган.

1954 нче елның 10 нчы апрелендә СССР Югары суды, Татарстан Югары судының Тавлинга карата хөкем карарын юкка чыгарып, Татарстан дәүләт иминлеге комитетыннан аның эшен яңабаштан тикшерүне

таләп иткән. Яңадан тикшерү Г. Тавлинның бернинди җинаять тә эшләмәгәнлеген ачыклаган, һәм ул, 1954 нче елның 22 нче сентябрендә реабилитацияләнеп, тоткынлыктан азат ителгән.

Ирек яулагач, партиядә торгызылып, педагогия институтын тәмамлаган. Әмма элекке «халык дошманы»на, утсыз төтен булмый, аны юкка гына биш елга якын сак астында тотмаганнардыр, дип, яшь буынга белем, тәрбия бирүне ышанып тапшыруны кулай күрмиләр. Башта Тавлин Казанны судан саклау буенча инженерлык корылмалары төзелешендә, Казан елгасы аша дамба төзүдә эшли. 1972 нче елда, педагогия институтын тәмамлаганнан соң, унҗиде ел гомере узгач кына, мәктәптә эшли башлый.

Гурий Тавлин — «Сары яфраклар коела», «Йолдызлар безгә янәшә», «Тәвәккәл таш яра», «Алгы сызыкта» һәм башка исемнәрдәге китаплар авторы. Аның беренче зур әсәре булган «Дунай дулкыннары» романы кульъязма килеш Татарстан дәүләт иминлеге комитетында юк ителә. Үзе кичергән вакыйгаларга нигезләп язылган «Афәт» романының беренче һәм икенче кисәкләре 1990 нчы һәм 1991 нче елларда «Казан утлары» журналында басылды.

*Иван Глухов*

## «Арумысез, карендәшләр?!» яки фарсы материалының керәшен сөйләшендә чагылышы

Түбәндәге язманың авторы, педагогия фәннәре кандидаты Әнисә Шәрәфетдинова күп еллар буена тел белеменең бер тармагы булган лексикологияне өйрәнү өлкәсендә эшли. Керәшеннәр сөйләшенең лексик үзенчәлекләре турында да аның үз фикерләре бар.

* * *

Минем уйлавымча, «Арумы, карендәш?» дип исәнләшүдә татар халкының бик борынгы, кайбер тел һәм этник үзенчәлекләре саклана. Моңа инану өчен, һәр ике сүзнең нинди чыганаклардан булуына һәм эволюциясенә күз салыйк.

Ару «яхшы», «әйбәт», «ярый (ару)», «ярыйсы (арусы)», арумы «яхшымы», «әйбәтме», «ярыймы (арумы)», «ярыйсымы (арусымы)» сүзләре чыгышлары буенча, һичшиксез, фарсыдан, һәм түбәндәге архисемаларны (борынгы мәгънә берәмлекләрен), архиформаларны (борынгы формантларны, грамматик чараларны) безгә китереп җиткерәләр:

1. перс. **ором** *«спокойный, тихий, мирный; спокойно, тихо, мирно»;*

*2.* перс. **ороми** «*спокойствие, тишина, тишь; невозмутимость»;*

3. перс. **ором?!** *«покой?!», «покой ли?!», «плохо ли?!», «мирно ли?!»;*

4. перс **ором+ми?!** *«спокойствие ли?!», «тишина ли?!», «покой ли?!», «мирно ли?!»,* перен. *«не волнует ли, не возмущает ли, не беспокоит ли кто, что?!»*

Күренә ки, фарсыларда *-и* форманты (*ороми* сүзендә сузыклардан соң *-ги,-ви)* хәзер дә исемнәрдән сыйфат, сыйфатлардан исем ясый, этносны, нәсел-нәсәпне, яшәү урынына мөнәсәбәт күрсәтүче бик продуктив чара.

Фарсының сорауны белдерүче *-ми* кисәкчәсе дә *(оромми* сүзен кара) безгә шул ук мәгънәләре белән *-мы, -ме* суффикслары булып килеп җиткән; *ярый, ярыйсы, ярыймы, ярыйсымы* лексемалары турыдан-туры «ором» сүзеннән. Китерелгән мисаллар моны яхшы аңлата, бу мәкаләдә аларга киң тукталуның кирәге юк.

«Карендәшләр» сүзенең дә фарсының **карин —** *«якын», «сверстник», «замандаш», «кордаш»* сүзеннән икәнлеге, **карин доштан** *«иметь очень близкие, кровно близкие отношения»,* ниһаять, **карин доштан** *карындаш, кардәш, кордаш,* диалектларда *хәрендәш «кровно близкий человек, родня»* сүзләреннән булуы минем өчен аксиома. Сүз уңаеннан шуңа да игътибарыгызны юнәлтәм: карап үтелгән мисал *-даш, -дәш, -таш, -тәш* (*авылдаш, килендәш, якташ, иптәш* һ. б. лар) кебек сүз ясагыч чараларыбызның да чыгышлары белән фарсыдан икәнен ассызыклый.

Кыскасы, арумысез, карендәшләр?! — Ару, бик ару, шөкер!

Нихәтле мәгънә тирәнлеге һәм итагатьчеллек күзәтелә бу борынгы сүзләрдә! Аларның тел материалы буларак кына түгел, гамәлдәге сөйләмдә нәкъ керәшеннәрдә хәзерге көнгә кадәр сакланып калганын да искә алсак, тагын да җитдирәк уйларга чумачакбыз…

Сәлам бирү, исәнләшү сүзләре аралашу вакытында дуслык, бер-береңә игътибарлылык хисләрен яңартып торучы, мәгънәләре ягыннан синонимик яисә антонимик мөнәсәбәтле, билгеле бер сандагы сүзләрне эченә алган төркемнәрне тәшкил итәләр. Һәр халыкта да алар бар, һәм халыкның үзенә ничә яшь булса, бу сүзләргә дә, мөгаен, шул хәтле яшьтер.

Бу сүзләр халыкның үзе кебек үк бик борынгылар. Аларның эчтәлегенә күз салсак, халыкның иҗтимагый, сәяси тормышында, аңында, психикасында нәрсәгә нык өстенлек бирелүен, бу халыкта яшәешнең төп шарты итеп нәрсә кабул ителгәнлеген аңларга була. Ә менә керәшеннәрдә ул әһәмияткә, ан-

дый кыйммәткә ия булган нәрсә — тынычлык, җан тынычлыгы икән... Бер-береңә шуны теләүдән мөһимрәк, гүзәлрәк тагын нәрсә бар икән бу дөньяда?!

Димәк, «татарның иң борынгы катламнары» дигән карашка керәшеннәр үзләренең җыр-моңнары белән генә түгел, ә тел үзенчәлекләре белән дә бик якын тора, туры килә. Алар рус исемнәрен йөртергә беркайчан да, бер яктан да (менталитетлары белән дә, тел-сөйләм әгъзалары белән дә) әзер булмаган. Шунлыктан алар рус атамаларын һәм апеллятивларын нәкъ үзләренә генә хас самимилек белән, рәхәтләнеп бозалар, ә ата-бабадан калган тел мирасын зур тырышлык белән саклыйлар. Ә ни өчен ул мирас күпчелек очракта фарсыдан? Монысы инде башка, зур, фәнни проблема...

Шуларга нигезләнеп, әйтәсе килә: татар теленең һәм халкының тарихын язуда керәшен темасы зур роль уйнаячак!

Без татар телендә сөйләшүче кабиләләрнең күп санлы, таркау чорларын гына беләбез, кызганычка каршы. Тел белемендәге статистикага таянганда, андый кабиләләр 240 тан артык. Ә менә фәнни хезмәтләре белән планетага билгеле галим Николай Александрович Баскаков уйлавынча (аны да керәшен булган икән диләр), күптөрле татарларның бербөтен агач кәүсәсен хәтерләткән чорлары да булган.

Милләт язмышында төп әһәмияткә ия булырдай мондый ачышларга бары түгелми-чәчелми безгә килеп җиткән телләр мирасына таянып кына, бу мирасны ныклап өйрәнеп кенә ирешергә мөмкин. Тел — мәңгелек байлык, сүнмәс ут, уникаль мирас. Аны өйрәнү, фәнни яктан белү зарур. Керәшеннәрнең үз араларыннан чыккан, катлаулы эзләнүләр алып барырга, тарихи анализлар ясарга сәләтле, күптелле тел галимнәре кирәк, газиз кардәшләр!

*Әнисә Шәрәфетдинова,*
педагогия фәннәре кандидаты

ЭЧТӘЛЕК

Кереш ................................................
*Ф. Баязитова.* Керәшен татарлары турында кыскача белешмә

**Башлангыч сыйныфлар өчен**

*М. Глухов*. Җырчы Җәкәү ..............................
*Яков Емельянов*. Әләк. Улым ...........................
*Г. Рәхим.* Көзгедәге күзләр ..............................
*П. Апушев*. Ике песи баласы. Ике көянтә. Тыңлаусыз чүкеч.
Күк тавыкның шатлыгы .............................
*К. Булатова.* Син исәнме, Санук түти? ....................
Ананий Нестерович Малов (Ямаш Игәнәй) ................
*Маловлар* (Александра, Лидия, Василий). Без биш бала үстек…
*Я. Игәнәй*. Әтәч. Чебиләр ...............................
*А. Филиппов*. Беренче Спас. Урта Спас. Өченче Спас ........
*Я. Игәнәй.* Авыл иртәсе ................................
*И. Минеева*. Булсын гына файдасы. Куяннарның туннары ..
*Л. Степанова*. Җиләкле як. Елмаюда бары яктылык ........
*Г. Рәхим.* Бөре тышчасы ................................
*Ф. Баязитова.* Йолалар һәм йолаларга караган сүзләр ......
*А. Филиппов*. Песиле тал ботагы .........................
*Г. Рәхим*. Димәк .......................................
*М. Макаров.* Карендәшләр җыры ........................
*А. Филиппов*. Элҗен. Җәйге Микулы. Август .............
*Н. Александров*. Көзге көндә җәйге моң. Гүзәллек ..........
*Н. Тукмачев*. Әй торналар, торналарым ..................
*А. Филиппов*. Сентябрь .................................
Борынгы китаптан (Библиядән) ..........................
*А. Филиппов.* Покрау ..................................
*Ф. Баязитова.* Ел фасыллары белән бәйле йолалар, бәйрәмнәр,
борынгы ышанулар ..................................
*Р. Шәйдуллина*. Милли аң уяныр килә ...................

*П. Ибаев*. Сыргаларың сырлы-сырлы .....................
*А. Филиппов*. Октябрь ..................................

**5—9 нчы сыйныфлар өчен**

*М. Глухов***.** Аллабыз бергә яраткан ........................
*Г. Рәхим*. Шигъри телебез ...............................
*А. Филиппов*. Олы көн истәлекләре .......................
*Л. Гумилев.* Татарлар кемнәр алар? .......................
*А. Филиппов*. Түгәрәк уен ...............................
*Д. Исхаков*. Керәшеннәр ................................
*Р. Әхмәтьянов*. Керәшеннәр каян килеп чыккан?
Кәвәл авылы көе. Безнең ил ..........................
*Н. Тукмачев.* Баграж сулары ла борма-борма.
Әйдә, әйдә. Чибәр кызга. Кәтүк түти ...................
*С. Хәким*. Ул — чәчәкле капкадан .......................
*А. Гыйләҗев.* Чор белән бергә ............................
*Гәрәй Рәхим* шигырьләре ...............................
*Ф. Баязитова*. Им-томнар, ырымнар .....................
*Я. Игәнәй.* Бакалы керәшеннәре .........................
*А. Филиппов*. Кышкы Микулы. Балдак салу ..............
*М. Макаров*. Көмеш тояк тулпар атым ...................
*А. Филиппов.* Декабрь-январь ............................
*Н. Максимов*. Ир уртасы булдым. Кайт әйләнеп ...........
*А. Филиппов.* Раштуаның өч көне ........................
*Г. Родионов.* Икона турында .............................
*Г. Макаров*. Нәсел тамгаларыбызны онытмыйк ............
*А. Филиппов.* Февраль ..................................
*Дьякон Василий*. Уразага керү ..........................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан геройлар** .................
*Ш. Рәкыйпов.* Кызлар-йолдызлар ........................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан генераллар** ..............
*Н. Булатов.* Илне саклау — егет бурычы ..................
*К. Булатова* шигырьләре ................................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан язучылар** ................
*Р. Фәйзуллин*. Шагыйрь, поп һәм якташ ..................
*Е. Уткин* шигырьләре ..................................
*И. Глухов.* Гурий Тавлин ................................
*Г. Тавлин.* Диңгез кабырчыгы ...........................
*Г. Рәхим*. Сугышта югалган солдатлар ....................
*П. Апушев* шигырьләре ..................................
*А. Филиппов*. Май чабу .................................
*Г. Рәхим*. Песнәк .......................................
*Р. Гаташ*. Ике яздан — матур китап .....................
*Л. Янсуар* шигырьләре .................................
*А. Филиппов*. Март ....................................
*П. Апушев.* Мишә буйлап — Иделгә .......................
*А. Филиппов*. Апрель. Бәрмәнчек ........................
*Н. Булатов*. Икенче Җәлил бит бу! .......................
*Я. Игәнәй.* Керәшен туе .................................
*Н. Булатов.* Теләче суы тәме ............................
*Г. Макаров*. Фонографлы гыйлем иясе ...................

**10—11 нче сыйныфлар өчен**

*Ф. Баязитова*. Керәшеннәр кайларда яши? .................
*М. Логинова.* Әти җаны .................................
*Г. Родионов*. Безнең як керәшеннәре болай сөйләшә ........
*А. Филиппов*. Май ......................................
*Г. Рәхим*. Каргышлар. Әниләр зары ......................
Керәшен мәгарифе тарихыннан ..........................
*Н. Максимов.* Телен югалтмаганны тарих югалтмый ........
Керәшен укытучылары мәктәбе ..........................

**Керәшеннәр арасыннан чыккан укытучылар** .............
*А. Филиппов*. Олы көн. Симек. Июнь-июль ................
*К. Булатова*. Торойсын — җапрак бәйрәме ................
*А. Филиппов*. Питрау ...................................
*А. Филиппов*. Г. Казанцева ..............................
*М. Разов*. Керәшен сылуына .............................
*А. Филиппов*. Тау ягы сандугачы .........................
Керәшен матбугаты тарихыннан .........................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан галимнәр** .................
*Н. Каштанов*. Марс Константинович Михайлов ...........
М. Глухов ............................................
*Н. Булатов*. «Татарика. Энциклопедия» китабы белән танышкач ..........................................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан артистлар** ...............
Р. Тимофеева ..........................................
Вера Минкина .........................................
Н. Дунаев ............................................
*Г. Низам*. Керәшеннәргә мәхәббәт турында ................
*Н. Асанбаев*. Рух ныклыгы — бердәмлектә ................
*Я. Игнәй*. «Гел изгелек булсын» ........................
*Г. Мөбарәкова*. Һәрчак заманча яңгырар .................
*Н. Максимов*. Георгий Ибушев ..........................
*М. Әгъләм*. Георгий Ибушев .............................
*Г. Ибушев*. Әни янына. Музыка. Дустыма .................
*Е. Антонова*. Җырларында киек казлар моңы .............
Киек казлар ..........................................
*Н. Максимов.* Лидия Әхмәтова ...........................
Ай Биби ............................................
Авылга кайтып киләм ................................
Каратай буе .........................................
*Н. Максимов.* Зоя Борисова ..............................
*Н. Әхмәдиев*. Безнең Валя-Валентина.
Кәләй авылы җыры ..................................
*Н. Максимов.* Аграфена Васильева .......................
Керәшеннәр арасыннан чыккан композиторлар ............
*К. Таҗиева*. Марс Макаров ..............................
*Н. Максимов*. Геннадий Максимов .......................
*Г. Максимов*. Кемең бар? ................................
*Г. Зәйнашева.* Керәшен такмаклары ......................
*Н. Максимов.* Роберт Андреев ..........................
*Р. Андреев*. Мин яратам сине, Татарстан ..................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан рәссамнар** ................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан танылган спортчылар** ......
**Керәшеннәрдә көрәшчеләр дә күп** .......................
*М. Кадыйров*. Җиңелү белмәс Виссарион ..................
*Н. Булатов*. Үткер аның кылычы .......................
*Н. Тукмачев*. Кичер ...................................
*Н. Булатов.* Батырларның батыры .......................
*Н. Тукмачев.* Аккош күлләрдә генә .......................
*Ф. Моратова*. Исемнәр казанмаса да .....................
*Я. Игнәй.* «Кодрәтеңне салчы...» ........................
*В. Гаврилова*. Кеше китте, эзе калды ......................
*Н. Тукмачев*. Ак сиреньнәр ..............................
**Керәшеннәр арасыннан чыккан атказанган укытучылар** ...
**Атказанган табиблар** ...................................
**Атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре** ..............
**Атказанган мәдәният хезмәткәрләре** .....................
*И. Глухов.* Гурий Тавлин ...............................
*Ә. Шәрәфетдинова.* Арумысез, карендәшләр?! .............

Учебное издание

Составитель

**Максимов Николай Валентинович**

**МЫ ИЗ ОДНОГО КОРНЯ**

Учебное пособие по изучению
этногенеза и этнографии татар-кряшен
средних общеобразовательных школ

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Р. И. Раскулова*
Редакторы *Е. Г. Әбделмәнова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Корректоры *Р. Ә. Фәйзуллина*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкжанова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия 1997 елның 7 апрелендә
бирелгән. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.09.2002.
Форматы 60ә90 1/16. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 14,0. Нәшер-хисап табагы 10,92.
Тиражы 6 500 д. Заказ Б-152.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф». 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
Http://magarif.kazan.ru/
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.